ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕН МОДЕЛЬЛӘШТЕРҮДӘ ЗАМАНЧА ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР (ЭШ ТӘҖРИБӘСЕННӘН)

Казан
2015

**ББК 74.268.1 Тат + 74.268.3 (2Рос=Тат)**
**Т 23**

**Проект җитәкчеләре:**
**Р.Г. Хәмитов,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты ректоры, педагогика фәннәре кандидаты, доцент
**Л.Ф. Салихова,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты укыту-методик эшләр буенча проректоры, педагогика фәннәре кандидаты
**Фәнни мөхәррир: Г.Ф. Даутов,** Казан федераль (идел буе) университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты

**Төзүчеләр:**
**А.Х. Мөхәммәтҗанова,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты милли мәгариф лабораториясе мөдире, КФУ АФ доценты, филология фәннәре кандидаты,
**Р.Б. Камаева,** Казан федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты

**Татар теле һәм әдәбияты дәресләрен модельләштерүдә заманча педагогик технологияләр** (эш тәҗрибәсеннән) / төз. Мөхәммәтҗанова А.Х., Камаева Р.Б.. – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 216 б.

Бу уку-укыту ярдәмлеге заманча технологияләр, яңа педагогик алымнар кулланып төзелгән дәрес эшкәртмәләрен үз эченә ала. Дәресләр Татарстан мәктәпләре укытучылары тарафыннан укучыларда яңа федераль дәүләт стандартларының мөһим юнәлеше булган универсаль уку гамәлләре формалаштыруны күздә тотып төзелгән.

Бу хезмәт белем бирү оешмаларында эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларына, педагогик уку йортлары студентларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

©ТРМҮИ, 2015

## ЭЧТӘЛЕК

**I БҮЛЕК.**
**ТАТАР МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУ ....... 5**
Тема: Галимҗан Гыйльмановның «Гөлләр дә елый» әсәре буенча класстан тыш уку дәресе. Ф.К. Гәрәева ....... 7
Тема. Язмышлар язылганда. И. Салаховның «Колыма хикәяләре», Г.Тавлинның «Афәт» әсәрләрендә шәхес культы фаҗигасе (11 нче сыйныф). И.Х. Хәсәнов ....... 19
Тема: Дәрдмәнднең тормыш юлы һәм эшчәнлеге (10 нчы сыйныф). Р.Ф. Хәйруллина ....... 27
Тема: Ә.Еникинең «Матурлык» әсәрен өйрәнү (9 нчы сыйныф). Р.К. Билалова ....... 34
Тема: Исемнәрнең тартым белән төрләнеше (3 нче сыйныф). Р.Д.Маннапова ....... 43
**II БҮЛЕК.**
**РУС МӘКТӘБЕНДӘГЕ ТАТАР БАЛАЛАРЫНА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУ ....... 55**
Тема: Берлек һәм күплек сандагы исемнәр (3нче сыйныф). К.К. Ахметшина ....... 57
Тема. Р.Валиеваның «Туган көндә» хикәясен өйрәнү (3 нче сыйныф). Э.Җ. Газизова ....... 63
Тема: Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр,алар янында тыныш билгеләре (8 нче сыйныф). М.Г. Талипов ....... 67
Тема: Кисәкчәләрнең төркемчәләре (6 нчы сыйныф). Г.З. Шәйхетдинова ....... 74
Тема: Хәл турында төшенчә (8 нче сыйныф). Ф.Ф. Әхәтова ....... 84
Тема: Тиңдәш һәм тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләләрне кабатлау (8 нче сыйныф). Р.С. Ганиева ....... 92
Тема: Сүз төркемнәрен кабатлау (2 нче сыйныф). Ә. Б. Җиһаншина ....... 97
Тема: Е хәрефе һәм [е] авазы (1 нче сыйныф). Г.Р. Әхмәтшина ....... 102

Тема: О, ө, ы, э(е) хәрефләренең дөрес язылышы (5 нче сыйныф). В.Ә. Гаделшина ........ 108
Тема: Алмашлык (6 нчы сыйныф). Ф.Г. Абдуллина ........ 120
Тема: Татар теленең кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан сүзлек составы. Искергән сүзләр (5 нче сыйныф). Л.Ә. Хәертдинова ........ 128
Тема: Аныклагыч янында тыныш билгеләре (7 нче сыйныф). Л.Н.Муллагилова ........ 133
Тема: Сүзләрне кушу ысулы. Кушма, парлы, тезмә сүзләр (5 нче сыйныф). А.Ә. Хайбрахманова ........ 137
Тема: Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрен өйрәнү (11 нче сыйныф). А.Г. Ризванова ........ 145
Тема: Легендага әйләнгән татар шагыйре (9 нчы сыйныф). М.Г. Талипов ........ 153
Тема: «Кошларым, дусларым». Гали Хуҗи «Кошлар кайта» шигыре. (4 нче сыйныф). З.Сафина ........ 162

**III БҮЛЕК.**

**РУС БАЛАЛАРЫНА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУ ........ 169**

Тема: «Табын янында» хикәясендә тәрбия проблемасының куелышы (5 нче сыйныф). С.Г. Юнысова ........ 171
Тема: Буш вакыт һәм яраткан шөгыльләр (татар теле-инглиз теле, интеграль дәрес (6 нчы сыйныф). Р.Б. Камаева, Р.Р. Камаева ........ 176
Тема: «Кошлар безнең дусларыбыз» темасын ныгыту (4 нче сыйныф). Л.М. Сибаева ........ 182
Тема: «Базарда» текстын уку (2нче сыйныф). Р.Ә. Юнысова ........ 187
Тема: «Яз килә» темасы буенча сүзлек диктанты. Парлы сүзләр, кушма сүзләр (4 сыйныф). Л.Х.Канашова ........ 190
Тема: Хикәя фигыльне кабатлау (6 нчы сыйныф). Э.Д. Сафиуллина ........ 195

**IV БҮЛЕК.**

**ФДББС ТАЛӘПЛӘРЕ НИГЕЗЕНДӘ ЗАМАНЧА ДӘРЕС ........ 203**

ФДББС буенча якынча дәрес структуралары ........ 205

# I БҮЛЕК.

# ТАТАР МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ
# ТАТАР ТЕЛЕ
# ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУ

# ТЕМА: ГАЛИМҖАН ГЫЙЛЬМАНОВНЫҢ «ГӨЛЛӘР ДӘ ЕЛЫЙ» ӘСӘРЕ БУЕНЧА КЛАССТАН ТЫШ УКУ ДӘРЕСЕ

**Ф.К. Гәрәева, Казан**

**Тема:** Ялгызлык һәм аның сәбәпләре.

**Максат:** Ялгызлык төшенчәсен әдәби әсәр эчтәлеге аша ачу.

**Дәреснең бурычы:** Әдәби әсәрнең темасын, идеясен ачыклау максаты белән текстны анализлау күнекмәләрен формалаштыру; текстны анализлау барышында критик фикерләү сәләтен үстерү; кеше хәленә керә белү, кызгану, өлкәннәргә хөрмәт хисләрен тәрбияләү.

**Дәрес тибы:** Әдәби текст белән эшләү.

**Технология:** Уку аркылы критик фикерләү сәләтен үстерү.

## Дәрес барышы

**1. Ориентлашу этабы.**

Хәерле көн балалар! Без сезнең белән бүген Галимҗан Гыйльмановның «Гөлләр дә елый» хикәясен укырбыз. Галимҗан Гыйльманов – татар язучысы, шагыйре, драматургы һәм әдәбият белгече. Фантастик-хыялый һәм маҗаралы әсәрләр авторы.

Без укыячак әсәрнең исеме буенча әйтеп карагыз: нәрсә турында сүз барыр икән?

(Җаваплар тыңлана).

Аның җавабын кыска шигырьләрдән дә табарбыз.

Түбәндәге кыска шигырьләрдә беренче юлда нинди сүз язылмаган. (Һәр группага бер шигырь бирелә)

......
Кирәксез һәм артык.
Хәбәр килми.
Телефон да ватык.
Кайнар кофе.Җаным салкын.
Үзем генә тагын.
...
Пар чынаяк.
Тик берсе буш.
Йомышыңны көзгегә куш.
Һәм җавапсыз сорау.
Сукты кырау.
...
Ай һәм кояш.
Бер-берләрен күрми.
Үзем генә бер сукмакта.
Кешеләрсез.
...
Һәм мин.
Аның белән икәү.
Бергә сез диләр.
Ә бергә ничәү?
Берәү?
...
Бүтән төрле. Ят.
Сәер эшләр беләм.
Кабул итми галәм.
Үзем генә.

Димәк, без ялгызлык турында сөйләшәчәкбез.

Ничек уйлыйсыз, бу тема бүген актуальме? Нигә?

Дәфтәрләрегезгә ялгызлык сүзе нәрсәне аңлата, аның сәбәпләре нәрсәдә шуны языгыз.

Көтелгән җавап. Якын кешең үлсә. Дусларың булмаса. Сугышлар аркасында. Сине аңламасалар...

Әйтегез әле, һәрвакытта да ялгызлык, ялгыз калу начар күренешме?

Көтелгән җавап. Кайчакта кешегә ялгыз калып, уйларын тәртипкә китерергә, дөрес юлны табарга кирәк.

Ялгызлык уңышларга этәрә аламы?

Көтелгән җавап. Әлбәттә, кайбер рәссамнар, галимнәр иҗат иткәндә ялгызлыкка омтылалар. Мондый минутларда аларга беркем кирәкми. Алар бәхетле.

Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшәчәкбез?

Көтелгән җаваплар. Ялгызлык, аңлашылмаучанлык һәм аның сәбәпләре.

**Без әсәрне өзекләргә бүлеп укыячакбыз. (Текст һәр укучыда була)**

**Беренче өзек.**

Мин ул әбекәйне күптәннән беләм. Безнең ишегалдында мин белә-белгәннән бирле яши ул. Аның белән беркем дә аралашмый. Моның бик мөһим сәбәбе бар. Ул һәр көнне урамга бер гөл күтәреп чыга. Подъезд ишегендә ялтыравыклы чәй кәгазенә төрелгән гөл савыты күренү белән, ишегалдында булган кешеләр бер-берләренә карашып алалар, аннары, кем – кибеткә, кем – үз өенә, кем кая таралыша башлый. Хәтта такталар белән бүлеп алынган комлыкта уйнап утыручы бала-чага да бермәлгә тынып калгандай була. Бөтен ишегалдын сәер тынлык биләп ала. Ниндидер шомлы тынлык...

Кыяфәте-йөзе белән әллә ни куркыныч түгел ул. Юк-юк, бөтенләй дә куркыныч түгел! Хәтта... ниндидер мөлаемлык та бар бу әбидә. Киемнәре искедән булса да, ул бик пөхтә, чиста киенеп йөри. Ак яулыктан, яшел чәчәкләр кунган ак, озын күлмәктән. Димәк, татар әбие бу. Татар әбиләре генә шулай пөхтә, матур итеп, иң мөһиме, актан киенеп йөриләр.

Алайса кайсы ягы белән сәер соң бу әбекәй? Әлбәттә инде урамга алып чыгып йөрткән гөле белән. Шул гөле аркасында аның белән аралашмыйлар, хәтта аннан шикләнәләр, ятсыналар... Иң кызыгы, андый гөл беркемдә дә юк. Ниндидер чит-ят гөл ул, бернинди китапта да тапмассың аны. Менә шул гөлен күтәрә дә чыга, күтәрә дә чыга әбекәй. Бәй, уйлап карагыз: кем инде өендәге гөлен тышка, көн-кояш яктысына алып чыгып йөри? Этләрне алып чыгалар – монысы һәркемгә мәгълүм. Мәчеләрне дә урамга җибәрәләр... Ә менә гөлләрен урамга алып чыгып йөргән кешеләрне күргәнем дә, алар хакында ишеткәнем дә юк... Сәер, бик сәер бит бу. Әллә чынлап та акылга җиңелрәкме бу карчык?

Сорауларга җавап бирү. (Сораулар төркемнәрдә тикшерелә, бер укучы җавап бирә).

Әбине автор ничек сурәтли? Тышкы кыяфәте аша әбинең характеры турында нәрсә әйтеп була?

Ни өчен әби белән беркем белән аралашмый?

Сәер сүзе нәрсәне аңлата?

Әби турында без нәрсәләр белдек?

***Көтелгән җаваплар.*** *Беркем белән аралашмый, димәк, ялгыз. Мөлаем. Пөхтә. Ак киемле. Сәер.*

Әби турында кластер төзергә. (Кластер һәр төркемдә бар, дәрес барышында җаваплардан соң тутырыла).

Ничек уйлыйсыз, алга таба нинди вакыйгалар булыр? (Фаразлар тыңлана)

**Икенче өзек.**

Язмыш сукмагы безне үзе очраштырды. Язмыш сукмагы да түгел, язгы, бозлы, тайгак бер сукмак иде ул. Беркөнне менә шул сукмакта таеп егылды теге әбекәй. Әмма беркем дә ярдәмгә килмәде аңа. Якында уйнап йөргән балалар гына пырхылдап көлеп җибәрделәр... Мин түзмәдем, бөтен шик-шөбһәләрне читкә атып, тайгак сукмакта торырга азапланган әбекәй янына ашыктым. Мин иң элек аның алга сузылып торган кулларыннан гөлне алдым. Аны җылы кояш нурлары астында кибә башлаган асфальт өстенә куйдым. Аннары, бер кулын җилкәмә салып, иплэп кенә аягына бастырдым. Шуны чамаладым: җиңел, бик җиңел иде ул! Мамык кебек, канат кебек, уй кебек... Без эскәмиягә утырдык. Бер дә тиле яисә дивана карчыкка охшамаган иде бу әбекәй. Ачык зиһенле һәр кеше кебек, озаклап рәхмәт әйтте, матур тавышы белән дога укыды, теләкләр теләде... Чыпчын татар әбиләре кебек! Ахырдан:

Исем-атың кем соң синең? – дип сорап куйды. Исемемне әйттем.

Беләм-беләм, Сәлмәннең олы малае бит син... Ә мин Җиһан әбиең булырмын...

Бу сүзләр мине нык гаҗәпләндерде. Каян белә ул мине? Әллә чынлап та берәр сихер бармы бу карчыкта?

Нигә сез кешеләр белән сөйләшмисез, аралашмыйсыз?

Нишләп алай дисең, балам? Аралашу ул – сөйләшү, серләшү генә түгел бит әле. Көне буе сөйләшеп йөргән кеше белән дә аңышмый, аңлашмый аерылышырга мөмкин. Бер сүз кайтмыйча да рәхәтләнеп сөйләшеп, аңлашып була...

Шулаен шулай да... Кешеләр барыбер сөйләшеп аңлашалар бит...

Анысын дөрес әйтәсең, балам. Күңелләре, җаннары белән аралаша алмаганнар телләре белән аралашалар. Анысы дөрес... Тик... Иң элек җан... Аннары гына тел белән сүз...

Сорауларга җавап бирү.

Әби белән лирик герой нинди шартларда тагын очрашалар? Әби өчен аралашу нәрсә ул?

Көне буе сөйләшеп йөргән кеше белән дә аңлашмый аерылырга мөмкин. Бу  сүзләрне ничек аңлыйсыз?

Бер сүз әйтмичә дә рәхәтләнеп аңлашып була. Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз?

Күңел, җан белән аралашуны ничек аңлыйсыз?

«Мамык кебек, канат кебек, уй кебек...» сүзләрен ничек аңлыйсыз?

Әбинең исеме нинди мәгънәне аңлата?

Без бу өзектән әбинең тагын нинди сыйфатлары турында белдек?

***Көтелгән җаваплар.*** *Ачык зиһенле. Дога укый, димәк, дини. Матур тавышлы. Ишегалдында яшәүче бөтен кешене белә, димәк, игътибарлы. Исеме бик мәгънәле. Җиңел,ягъни аралашыр өчен тиз уртак тел таба. Фикерләре бик кызыклы.*

Кластер төзергә.(Җаваплар өстәлә)

**Өченче өзек.**

Гөл күтәреп килеп чыккан Җиһан әбине мин күтәренке күңел белән, шатланып көтеп алдым. Ул да мине күрде, тыйнак кына елмаеп, ерактан ук башын кагып куйды. Тагын таеп егылмасын дип, аны подъезд төбенә кадәр барып алдым.

Менә шулай көн саен чыгып йөрибез... Мин торган якка кояш карамый бит, көн яктысы төшми. Йортыбыз каршына аракы кибете төзеп куйдылар. Шул хәерсез нәрсә хәзер тәрәзәмне бөтенләй томалап тора...

Юк, зарланмый иде Җиһан әби. Гомумән, зарлана белми, ахры, бу карчык. Аның һәр сүзе дога кебек ягымлы чыга. Хәтта зары да...

Ниндидер чиста, ягымлы, иманлы карчык бу. Нигә элегрәк белмәдем икән мин аны? Бик кызык, гаҗәеп матур дөньяда яши бугай ул. Ниндидер якты, илаһи бер халәттә...

Сез миңа шушы гөлегез хакында сөйләргә булган идегез... Аны тере дип тә әйттегез әле...

Әйе шул. Әллә ни зур сере юк аның. Ә менә җаны хакында дөрес әйттем. Тере гөл бу. Кешеләрдәге кебек аның да җаны бар, күңеле бар, кайгысы-зары, шатлыгы бар...

Каян беләсез соң аны, Җиһан әби?

Күзләренә карап...

Ничек инде? Гөлләрнең күзләре буламыни?

Була шул. Их, сез, яшьләр... Якыннарыгызның күзенә тутырып карарга да вакытыгыз юк бит сезнең. Ә һәр үләннең, һәр үсемлекнең, гөлнең, чишмәнең, елганың, тауның, кояш-йолдызларның җаны бар...

Бик кызык икән бу... Җиһан әби, әйтегез әле, каян килеп эләкте соң сезгә бу гөл?

Ай-һай озын тарихка алып керәсең син мине, балам. Ярар, алайса, тыңла. Тик... Әйдә, бераз аяк язып алыйк. Зиннәтне дә кояшлырак урынга алып барыйк...

Кемне-кемне?..

Зиннәтне, дим. Бу гөлнең исеме «Зиннәт» бит. Сугышта үлеп калган хәләл иремнең исеме ул. Син сораган тарих та Зиннәтемне йолып калган каһәр сугышка барып ялгана... Зиннәтемнән өч хат килеп калды. Берсендә: «Чәчәкләрем исән-саумы?!» – дип сораган. Икенчесендә «Монда – Украинада – шундый матур чәчәкләр үсә, сугыштан соң кабат кайтып алып киләм әле», – дигән. Ә өченче хатында: «Монда сугышлар хәтәр бара, өйгә кайтып булмас, минем

төсем итеп шушы гөлне үстер», – дип язган. Бу өчпочмаклы хатының бер почмагына берничә бөртек орлык кыстырган... Озакламый «кара кәгазе» килде. Шул Украина җирендә ятып калды Зиннәтем. Үзе җибәргән гөл үскән җирдә... Мин инде берничек тә түзеп тора алмый идем, Җиһан әбинең сүзен бүлеп, сорап куйдым:

Бу гөл шул орлыклардан үсеп киттеме?

Әйе, Зиннәтем җибәргән берничә бөртек орлыктан шытып чыкты. Шулай туры килүен әйт әле: гөл орлыгы салган көнне һәлак булган мәрхүмкәем... Күңелем белән тойдым: хәләлемнең җаны шушы гөл орлыгына күчеп кайтты, кайткач, матур гөл булып шытып чыкты... Һәм менә... Миңем янда бер кеше гомере кадәр гомер яшәде...

Сорауларга җаваплар.

Әби ни өчен гөлен көн саен урамга алып чыга икән?

«Аракы кибете тәрәзәмне томалады» сүзләрендә автор нинди проблеманы күтәрә?

Гөлнең исеме ничек?

Гөл тарихын сөйләгез?

Бу өлештә әбинең нинди сыйфатлары ачыла?

***Көтелгән җаваплар.****Зарлана белми. Сабыр.Чиста күңелле. Ягымлы.Иманлы. Күңеле якты. Табигатьне ярата,аңлый. Иренең әманәтен үти, ягъни сүзендә тора.*

Кластер төзергә.(Җаваплар өстәлә)

**Дүртенче өзек.**

Җиһан әбинең соңгы вакытта ни өчен урамга чыкмавы белән кызыксындым.

Авырып торам әле, балам. Йөрәгем турысында нидер кадап тора.

Гөлегезнең дә ничә көн инде урамга чыкканы юк...

Юк та соң... Зиннәтем көн дә иртән өзелеп карап тора... Ә мин алып чыга алмыйм. Шулай икебез дә күзләребезне бер-беребезгә мөлдерәтеп карап торабыз... Аның күзендә дә яшь, минем күздә дә яшь...

Кая, карыйм әле, Җиһан әби, минем гөлләр елаганын күргәнем юк бит...

Яшьләре кипте инде аның. Зиннәтем чын ир-егет иде. Шуңа күрә дә кешегә күрсәтеп еламый ул...

Җиһан әби, бир миңа аны, үзем йөртеп алып керәм...

Сак кына тотып, «Зиннәт»не урамга алып чыгып киттем. Шул чыгуымда мин ишегалды халкы арасында «танылып» та өлгердем. Бөтен халык, бердәй булып, миңа таба борылып карады. Җиһан әби белән аралашкан вакыт эчендә минем рухым ныгып өлгергән иде инде, каушап калмадым, нык адымнар белән эскәмияләрнең берсенә барып утырдым. Гөлне янәшәмә куеп, тирә-юньне күзәтә башладым.

Өлкәннәр минем янга килергә батырчылык итмәделәр. Ә менә бала-чага халкы шунда ук якынрак елыша башлады.

Абый, бабуля кайда? Бу цветок белән нишләп утырасың?

Бабуля үзенең өендә, – мин әйтәм, – ә мин бу цветок белән сөйләшеп утырам. Аның да җаны, душасы бар бит, ул да тере. Менә синең кебек, менә минем кебек!..

Ой, ничек интересно!

Бу гөлнең тарихын сезгә дә сөйлимме соң?

Сөйләгез, сөйлә!..

Хәзер сөйлим... Тик сез хәзер үк ишегалдында уйнап йөргән бөтен малайларны, кызларны монда җыеп алып килегез. Бөтенегез бергә җыелсагыз гына сөйлим.

Ун минуттан егермеләп пар күз миңа йотлыгып карап тора иде инде.

Бу чәчәкнең исеме «Зиннәт», – дип сөйли башладым. Гөл тарихын балалар тын да алмый тыңладылар. – Шул герой Зиннәтнең җаны була бу гөл, беләсегез килсә... Ә сез көлгән буласыз шул әбидән... «Бабуля» дисез... Ул бит сезгә Җиһан әби...

Без бүтән бервакытта да аңардан көлмәячәкбез...

Без бит белмәдек...

Геройлардан көләргә ярамаганын беләбез без...

Ветераннардан да көләргә ярамый...

Без бүтән көлмәбез... Без бит белмәдек...

Белгәч, шул. Җиһан әби авырткандa, сез аңа ярдәм итегез, эшләрендә булышыгыз, кибеттән ипи-сөт кертегез, менә шушы гөлен урамга, кояшка алып чыгыгыз. Килештекме?

Килештек!

Ой, ничек кызык!

Ой, как интересно!

Классно!

Сорауларга җавап бирергә.

Әби ни өчен соңгы көннәрдә урамга чыкмый?

Гөл белән әбинең бәйләнеше кайсы сүзләрдә чагылыш таба?

Лирик герой урамга гөлне алып чыккач, ишегалды кешеләре аңа ничек карыйлар?

Балалар гөл тарихын ничек кабул итәләр?

Бу өлештән әбинең нинди сыйфатларын белдек?

***Көтелгән җаваплар.*** *Әби авыру. Ирен – Зиннәтен – чын ир-егет иде, ди. Димәк, иренең рухына хыянәт итмәгән, яратып, хөрмәт итеп яшәгән.*

Кластер төзергә.(Җаваплар өстәлә)

Ничек уйлыйсыз, алга таба безне нинди вакыйгалар көтә?

**Бишенче өзек.**

Икенче көнне бөтен ишегалды бары тик Җиһан әби хакында гына сөйли иде. Балалар үз эшләрен эшләгәннәр: Зиннәт-солдат тарихын тирә-як йортларга таратып өлгергәннәр. Мин моңа, төшкә таба Җиһан әби фатирына барып кергәч, тәмам инанып җиттем. Аның бүлмәсендә миңа таныш түгел ике хатын утыра иде.

Әбекәйнең шундук «теле ачылды»:

И-и, балам, нишләттең бу халыкны? Бүген ачы таң белән керә башлаганнар иде, болары инде өченчеме, дүртенчеме пар. Әнә күчтәнәч белән тутырдылар өемне. Кызык бу кеше дигәнең, гөлне тотып-тотып карыйлар – тереме, янәсе... Зиһенгә җиңеләйгән дивана бәндәләр кебек кыланалар, билләһи!.. Балам, нишләттең син аларны, ә, сихерләдеңме әллә?

Җиһан әби тагын өч ай яшәде. Аның яныннан кеше өзелмәде. Соңлап килгән кадер-хөрмәт яшәткәндер дә аны, югыйсә бу дөньяны калдырырга ул күптән әзер иде инде. Тагын... гөле – Зиннәте яшәткәндер. Һич кенә дә аерыласы килмәде газизеннән...

Җиһан әби авырып түшәккә егылгач, бу гөлне күршеләре, якын-тирәдә яшәүчеләр, хәтта аны бөтенләй белмәгән кешеләр урамга алып чыгып йөртә башладылар. Безнең ишегалдында әнә шундый сәер, әмма үтә дә матур йола барлыкка килде.

Җәй ахырында Җиһан әби җан тәслим кылды. Васыяте буенча, әйберләрен күрше-күләнгә тараттылар, фатирын хөкүмәткә тапшырдылар. Ә менә гөлен... Зиннәтне... миңа атап әйткән. Аны күтәреп, Җиһан әбине соңгы юлына озата бардым, ә савытына каберенең җылы туфрагын өстәдем.

Шунда беренче мәртәбә мин гөлләрнең елаганын күрдем. Беренче мәртәбә гөлгә кушылып үзем дә еладым..

*Сорауларга җавап бирергә.*

Әбинең соңгы көннәрендә кешеләрнең аңа мөнәсәбәте ничек үзгәрә?

Ишегалдында нинди матур йола барлыкка килә?

Әйләнә-тирәдәге кешеләр әбинең үлемен ничек кабул итәләр?

Беренче һәм соңгы өлешләрне нәрсә берләштерә? Нинди синоним сүзләр кулланылган? Әбине кешеләр ни өчен сәер дип атыйлар? Соңгы өлештә әби хәлен белергә кергән кешеләрнең гамәлләренә нинди бәя бирә? Ничек уйлыйсыз, моның сәбәбе нәрсәдә? Безнең төп героебызны ялгыз дип атый алабызмы? Гөл нигә елый?

*Укучылар нәтиҗә ясыйлар.Фикерләр тыңлана.*

**Нәтиҗә ясыйбыз.** Кешеләр еш кына үзләренә охшамаган кешеләрне кабул итмиләр, аңламыйлар. Бу ялгызлыкка китерергә мөмкин. Ләкин безнең Җиһан әбине ялгыз дип булмый. Аның янында һәрвакыт иренең рухы – гөле була. Без тирә ягыбыздагы кешеләргә игътибарлырак булсак иде.

Дәресне йомгаклау. Билгеләр кую.

# ТЕМА: ЯЗМЫШЛАР ЯЗЫЛГАНДА. И. САЛАХОВНЫҢ «КОЛЫМА ХИКӘЯЛӘРЕ», Г. ТАВЛИННЫҢ «АФӘТ» ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ШӘХЕС КУЛЬТЫ ФАҖИГАСЕ (11 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**И.Х. Хәсәнова, Апас районы**

**Максат:** 1. Әсәрдәге вакыйгалар һәм геройлар аша шәхес культы фаҗигасен ачу; гаделсезлекләрне күрә, аңлый һәм дөрес бәяли белергә өйрәтү. 2. Балаларда сөйләм сәләтен үстерү, мөстәкыйль фикер йөртүләрен камилләштерү. 3. Халкыбызның үткәненә, тарихына аңлы караш булдыру, укучыларда шәфкатьлелек, миһербанлылык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Интерактив такта, проектор, ноутбук, презентация, китаплар күргәзмәсе, әдипләребез турында «Казан утлары» журналыннан публицистик материаллар А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г. Галиуллин. Әдәбият 11сыйныф, эш дәфтәре, И.Салаховның «Колыма хикәяләре», Г.Тавлинның «Афәт» әсәре.

**Дәрес тибы:** Яңа материалны аңлату.

**Методик алымнар:** Иҗади уку һәм эзләнүле ысуллар: укытучы сүзе, эзләнүчән әңгәмә, сәнгатьле уку, сөйләү, аерым өлешләргә анализ бирү, текст өстендә эшләү, әсәргә проблемалы анализ, проблемалы сорауларга җаваплар табу, биремнәр үтәү. Әңгәмә, чыгыш, сәнгатьле уку, анализ, проблемалы сорау.

**Планлаштырылган нәтиҗә:** Әсәрдәге геройларга гына хас үзенчәлекләрне билгели белергә, Сталин режимының авыр һәм гаделсез булуын, шәхес культы фаҗигасен аңлау.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру моменты.** Уңай психологик халәт тудыру.

***Укытучы***. Укучылар, сез елга ярына басып дулкыннарга карап торганыгыз бармы? Ярсу җилләр бу дулкыннарга килеп бәреләләр дә әле ярга китереп сылыйлар, әле елга эченә алып кереп китәләр, әле су тамчыларын зәңгәр күккә күтәрәләр. Без, кешеләр дә, тормыш диңгезенең дулкыннары бит. Язмыш җилләре безне дә әле бер, әле икенче ярга китереп сылый, әле күккә күтәрә, әле язмышның караңгы төпкеленә батыра. Була шундый кешеләр: язмыш богауларыннан ычкына алмыйча, тәгъдир хөкеменә буйсынучылар. Була шундый шәхесләр: үзенә язылган язмыш сынауларын җиңеп, сыгылмыйча, сынмыйча алга, биеккә күтәрелүчеләр. Мин язучыларыбыз Гури Тавлин белән Ибраһим Салаховны шундый шәхесләр дияр идем

**II. Актуальләштерү.**

***Укытучы***. Укучылар, инде хәзер әдипләребезнең тормыш юллары белән якыннан танышып китик. *(Сүз төркемнәргә бирелә. Алар әдипләрнең тормыш юллары белән таныштыралар. Презентация яклыйлар)*

**III. Яңа материалны аңлату.**

***Укытучы***. Сез бүген дәрескә Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре», Гури Тавлинның «Афәт» әсәрләрен өйрәнеп килдегез. Бу әсәрләр формасы белән дә, эчтәлеге

белән дә моңарчы без белгән, укыган, анализлаган әсәрләргә охшамаган. Ни өчен, нәрсәсе белән охшамаган?

***Укучы.*** *(Беренче төркемдәге укучылар җавабы)* Әсәрнең нигезендә Сталинның шәхес культы фаҗигасе ята.

***Укучы.*** *(Икенче төркемдәге укучылар җавабы)* Әдипләребез Г.Тавлин һәм И.Сәләхов – шәхес культы чорындагы гаделсезлеклрне үз җилкәсендә татыган шәхесләр. Шушы вәхшилекне халыкка, киләчәк буынга җиткерү максаты белән алар үзләренең «Колыма хикәяләре» (И.Сәләхов), «Афәт»(Гури Тавлин) әсәрләрен иҗат иттеләр.

***Укытучы***. Әйе, бик дөрес. Мин сезнең белән килешәм. Әсәрдә нинди проблема күтәрелә? Әсәрнең жанры, язылу тарихы белән киңерәк таныштырып китәргә кирәк.

***Укучы.*** Әсәрнең проблемасы – җәмгыйять белән шәхес арасындагы каршылык.

***Укучы.*** Гури Тавлинның «Афәт» әсәре жанры ягыннан роман – трелогия, өч кисәктән тора. Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре» фаҗига-хроника. Ә автор аны башта ук «Фаҗига» дип атый.

***Укытучы***. Ә эчтәлеген кыскача гына әйтеп бирергә уйласак, эчтәлеге нәрсә турында?

***Укучы*** Сталинның шәхес культы елларында, бер гаепсезгә төрмәгә утыртылган намуслы кешеләр турында дияр идек.

**IV. Ныгыту.**

***Укытучы***. Ә кемнәр соң алар гаепсез кешеләр? Ни өчен, нинди сәбәпләр белән алар Сталинның караңгы төрмәләрендә җафа чигәргә мәҗбүр булганнар?

***1 нче төркем.*** И.Салаховның «Колыма хикәяләре»ндә үзәк геройны тәшкил иткән образ – Ибраһим. Кулга алы-

нып, гаепләнүенең сәбәбе – күренекле әдип, җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимов белән аралашуы.

***2 нче төркем.*** Гури Тавлинның «Афәт»әсәрендә төп герой – Ирек Кадыйров.

Аның да кулга алынуының сәбәбе Г. Ибраһимов шәхесенә бәйле.

*(Төркемнәрдә укучылар үз фикерләре уртаклашалар. Әсәрдән өзекләр укыйлар.)*

***Укытучы***. Әйе, Сталин режимы милли интеллигенция арасында исеме күзгә ташланырдай, акыллы, белемле, алдынгы карашлы кешеләрне «Халык дошманы» дип кулга алган. Шушы кешеләрнең гомерен өч кешедән торган махсус «өчлекләр»хәл иткән.Ул елларда вәхшилекнең, җәбер золымның чиге булмый. Көне-төне сорау алулар, кыйнаулар, надзирательләрнең ерткычлыгы, концлагерьлардагы шартлар һ.б, һ.б.Ә безнең геройларыбыз өсләренә төшеән бу авырлыкны ничек күтәрәләр соң?

***Укучы.*** Авыр һәм газаплы була тоткыннарның тормышы. Ләкин тоткынлык тормышы нинди генә авыр булса да, безнең геройларыбыз башларын түбән имиләр, сатмыйлар, сатылмыйлар, хыянәткә бармыйлар, бер-берсенә ярдәм итеп, бер-берсен олылап, бер-берсенә рух биреп яшиләр.

***Укытучы***. Әсәрне укыганда күңелдә шундый сорау туа. Тикшерүчеләр, төрмә җитәкчеләре арасында, колония башлыклары арасында бер генә дә мәрхәмәтле, сәяси тоткыннарны аңлаучы кешеләр булмадымы икәнни соң?

*(Укучылар җавабы тыңлана)*

***Укытучы.*** Нинди генә авыр булса да, тән газабы онытыла, җан газабы авыр диләр. Безнең герйларыбыз өчен фаҗиганең иң зурысы, иң авыры нәрсә була?

***Укучы.*** Иң авыр фаҗига – ышанычны югалту. Сталинга, партиягә, ил сәясәтенә. Ышанычларын югалтсалар да,

аларның рухларын сындыра алмыйлар. Алар канлы куллы сорау алучылар белән горур сөйләшәләр.

***Укытучы.*** Сагыну. Кеше күңелендә туган сагыну хисе – гомер-гомердән килә торган иң татлы хисләрнең берсе. Туган җирләрне сагыну, йөргән сукмакларны, урамнарны, әти-әнине сагыну. Ерак Себер җирләрендә бер авыз татарча сүз ишетергә тилмергән татар кешеләре өчен каяндыр, сихри бер дулкын булып, татарча җыр ишетелүе тоткыннарның сагыну хисен тагын да арттыра. Әсәрдәге шушы урыннарны укыганда сездә нинди фикерләр уянды?

***1 нче төркем.*** И.Салаховның «Колыма хикәяләре»ндә Зифа Басыйрованың «Рамай» җыры тоткыннарны әсир итә. Сагыну хисе бөтен күңелләрен biлэп ала.

***1 нче төркем.*** Гури Тавлинның «Афәт»әсәрендә Гөлсем Сөләймpraneованың «Кәк-күк», Рәшит Ваһаповның «Фирдәвескәй» җырларын тыңлаганда тоткыннарның күзләрен яшь каплый, әсәрләнүдән сулышлары кысыла.

*(Әсәрдән өзекләр уку. «Афәт» 388-400 битләр, «Колыма хикәяләре» 106-108 битләр. Укучылар фикерләре белән уртаклашалар.)*

***Укучы***. Күзләрдән соң язлар килгән кебек, күп авырлыклар күргән геройларыбыз күгендә дә бәхет кояшы кабына. Аларның эшләре СССР югары судының хәрби коллегиясендә кабат карала һәм алар гаепсез дип табыла. Язмышларында язылган авырлыклырны җиңеп, гомерләренең көзендә алар,үзләре әйткәнчә, «кешечә» яши башлыйлар. Алар иректә. Бу ирек аларга тиз генә бәхет китерәме? Ирекkә чыккач та аларны кочак җәеп каршы алалармы? Әллә фаҗига дәвам итәме әле?

***Укучы.*** Фаҗига дәвам итә. Ике әсәрдә дә бу бик ачык күренә. Геройлар иреккә чыкач та үзләренә эш таба

алмыйлар. Бер кем дә аларны эшкә алырга теләми. Шикләнү дәвам итә.

***Укытучы.*** Ике әсәрдә бирелгән вакыйгалар арасында уртак яклар бар. Нинди уртаклык соң ул?

*(Укучылар җавабы тыңлана)*

***Укытучы.*** Ике әсәр дә уйландыра торган. Әсәрләрдәге вакыйгаларга карата күңелегездә төрле фикерләр тугандыр. Нәрсә беләндер ризалашмагансыздыр, нәрсәдер сезне борчыгандыр бәлки?

*(Узара парларда фикер алышу.)*

***Укытучы.*** Сталинизм – илебез халыклырының уртак фаҗигасе. Сталин репрессияләре бер генә төбәкне дә, бер генә халыкны да читләтеп үтми

Бу авырлыкларны безнең районадашларыбыз да, авылдашларыбыз да үз җилкәләрендә күтәрәләр. Политик репрессия корбаннары безнең районнан да булалар. Бу турыда безгә укучылар сөйләп үтәр

*(Сүз төркемнәргә бирелә. Беренче төркем районыбызның «Туган як» музееннан алган материаллар белән таныштыра)*

***Укучы.*** Репрессияләрнең башы 20 нче еллар азагында ук башлана. Бу вакытта колхозга кермәүчеләрне репрессиялиләр. Аларны иң элек өйләреннән куалар, аннары, кулаклар дип, себергә үк озату очраклары да була..

(Икенче группага сүзне бирәбез. Авылдан җыйган материаллар белән таныштыралар. Бариев Хәлим абыйның ведиоязмасы тыңлана)

**V. Дәрескә йомгак. Рефлексия.**

***Укытучы.*** Бүгенге дәрестән нәрсә аңладыгыз?

***1 нче төркем.*** Нинди зур, авыр, фаҗигале елларны үтә безнең халкыбыз. Кемнәрдер бу коточкыч хәлләрдән исән-

имин чыга алдылар, кемнәрдер мәңгегә күзләрен йомдылар. Алар арасында татарның асыл егетләре – шагыйрьләр, язучылар, галимнәр дә бар иде. Гөрләтеп иҗат итеп яткан, үз эшләрен намус белән башкарган бу шәхесләр юк кына сәбәп аркасында юк ителәләр яки 10,15 елга Себергә озатылалар. Менә аларның исемнәре. (*Экранда репрессияләнгән татар шагыйрьләре, язучылары рәсемнәре).* Шулай укбез бүген өйрәнгән әдәби геройларыбыз да нинди генә авырлыкларга юлыксалар да, Кеше дигән бөек исемгә тап төшермәделәр алар.

***2 нче төркем.*** Репрессия корбаннарын аклыйлар, аларның исемнәрен мәңгеләштерү өчен шактый гына эшләр башкарыла. Әмма үткәнне кайтарып булмый. Халык күңелендә тирән яралар кала. Әдәби геройларыбыз Ибраһим һәм Ирек Кадыйров та шәхес культы фаҗигасе корбаннары. Гделсезлекне үз җилкәләрендә күтәргән һәм җиңеп чыккан, Кеше дигән бөек исемгә тап төшермәгән татар егетләре.

***Укытучы.*** Шушы фаҗигане, ялгышны киләчәк буыннарга җиткерү максатыннан, соңгы елларда репрессия вакыйгалары турында бик күп кенә әсәрләр язылды. Шундый нинди әсәрләрне әйтә аласыз?

***Укучы.*** А.Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога», Р.Кәрәминең «Каргышлы этаплар», Ф.Бәйрәмованың «Кыңгырау». Мондый хаксызлык, кешелексезлекне киләчәк буын белергә тиеш. Экрандагы язучы-шагыйрьләрнең кайберләре белән таныш, аларның әсәрләрен укыганыбыз бар. Бу исемнәргә карагач, күңелгә шундый шигырь юллары килә. *(Укучы шигырь укый)*

***Укучы.***Тарих онытылырга тиеш түгел. Тарихны онытсак, ул яңадан кабатланырга мөмкин, дигәннәр борынгылар.

И. Сәләхов болай дип яза: «Мин киләсе буыннар без кичергәннәрдән сабак алсыннар өчен яздым. Сак булыгыз, бу явызлык бүтән кабатланмасын!» Әйтерсең лә, бу

сүзләр репрессия корбаннарының безгә мөрәҗәгате булып яңгырый. Әйе, тарих онытылырга тиеш түгел!

***Укытучы.*** Бик дөрес. Дәресне түбәндәге шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә:

*Беркемгә дә яшәү җиңел түгел,*
Хакыйкать ул бик тирәндә ята.
Яшәү мәгънәсенә төшеник без
Узганнарга кабат кайта-кайта,
Ялгышларны бәреп вата-вата.
(Укучыларга бәя кую)

**VI. Өйгә эш.1. Иҗади язма эш.**

Онытсак үткәнне, оныклар
Санламас бүгенге кадерен.

(М. Әгъләмов, шушы шигырь юлларыннан чыгып сочинение, нәсер яки хикәя язарга)

Шәхес культы фаҗигасен яктыртып язган шагыйрьләребезне барларга, таблица төзергә, шигырьләрен укырга.

# ТЕМА: ДӘРДМӘНДНЕҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ ҺӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕ (10 НЧЫ СЫЙНЫФ)

**Р.Ф. Хәйруллина, Буа районы**

**Максат:**

1. Шагыйрьнең тормышы турында тирән мәгълүмат бирү; авылдашларыбыз бертуган Шәрәфләр белән бәйләнешләрен, бер максатка, бер юнәлештә хезмәт итүләрен ачыклау. Шәҗәрә белән танышу.

2. Тарихыбыз белән кызыксынуларын үстерү өстендә эшләү.

3.Укучыларда язма мираска хөрмәт һәм сакчыл караш, кешелеклелек һәм милли горурлык хисләре тәрбияләү өчен җирлек тудыру. Милли төбәк компонентын кулланып эшләү.

**Дәрес тибы:** Яңа теманы аңлату дәресе. Дәрес-конференция.

**Метод һәм алымнар:** әңгәмә, укытучы лекциясе, сәнгатьле уку, сорауларга җавап.

**Җиһазлау:** 1. Дәрдмәнднең портреты; С.Хәким сүзләре язылган плакат. 2. Компьютер презентациясе. 3. Рәмиевләр шәҗәрәсе ясалган плакат. 4. Магнитофон. 5.Укучыларның шәҗәрәләре күргәзмәсе. 6.Ф.Кәрими, Р. Фәхретдинов, И. Нуруллин, Г. Нигъмәти портретлары. 7. Сораулар язылган плакат. 8. Аудиокассеталар, газета кисемнәре.

**Кулланылган белем чыганаклары:** 1. Дәрдмәнднең «Исә җилләр» җыентыгы. 2. М. Гайнуллин. «Татар әдипләре» китабы. 3. «Казан утлары» журналлары.

## Дәрес барышы

**I. Ориентлашу, мотивлаштыру этабы.**

**1. Психологик уңай халәт тудыру.**

1. Салават башкаруында «Аллага шөкер!» җырын тыңлау.

Укытучының кереш сүзе.

– Әйе, без исән, аллага шөкер! Ә без, исәннәр, үзебезнең дә, үлгәннәрнең дә кадерен һәм каберен белергә тиешбез. Дөнья тарихында һәм әдәбиятында тирән эз, бәрәкәтле мирас калдырган күренекле шәхесләр, даһи каләм ияләре байтак.

XX йөз башы татар әдәбиятында Дәрдмәнд (Закир Рәмиев) үзенә аерым урын алып тора. (портреты күрсәтелә; дәреснең эпиграфы укыла – С Хәким шигыре). Аны бер генә татар шагыйре белән дә бутарга мөмкин түгел. Дәрдмәнд-бер үк вакытта зур мал-мөлкәт иясе һәм чып-чын шагыйрь. Шунысы кыйммәт: З. Рәмиев байлыгының шактый өлешен милләтебезне аң-белемле, мәдәниятле итүгә тота. Татар халкына күрсәткән игелекләре өчен генә дә Закир һәм Шакир Рәмиевләр зур хөрмәткә лаек. Бүгенге дәрестә без шагыйрьнең тормыш юлына күзәтү ясарбыз. Авылдашларыбыз бертуган Шәрәфләр тормышыннан мәгълүматлар алырбыз.

**2. Белемнәрне актуальләштерү**

1. Сүзлек эше. Дәрдмәнд-моңлы, кайгылы кеше. (Дәрес ахырында З. Рәмиевнең ни өчен шушы кушаматны алуын ачыклау).

2. Укучыларның Дәрдмәнд турынданиләр белүен ачыклау. (7 нче сыйныф буенча).

– Дәрдмәнднең берничә шигырен яттан әйтү.
– Кыскача биографиясен сөйләү.
– Алтын хуҗасы буларак, аның приискалары турында кемнәрнең нинди әсәрләрендә языла?

(Г. Ибраһимов «Кызыл чәчәкләр», М. Гафури «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Восьмой приискаларында»)

– «Кораб» шигыренә көй язган якташыбыз химик-галим Фоат Гарифуллин турында әйтү, китапларын күрсәтү.

**Үзбәя.**

**II. Уку мәсьәләсен кую ситуациясе.**

Укучыларга түбәндәге план тәкъдим ителә.

1. Рәмиевләр нәселе һәм татар халкы язмышы.
2. Юлык авылы һәм Рәмиевләр.
3. Мәгърифәт тарату эшенә бу гаилә керткән өлеш.
4. Закир Рәмиевне сез, шәхес буларак, нинди кеше итеп күз алдына китерәсез?
5. Октябрь вакыйгалары һәм Дәрдмәнднең язмышы.

Шул план нигезендә чыгышлар оештырыла; Шәрәфләр эшчәнлегеннән мисаллар белән тулыландырыла.

**III. Уку мәсьәләсен адымлап чишү этабы.**

*Югарыдагы план буенча укучылар чыгышы һәм укытучының өстәмә мәгълүматлары.*

1. Бүгенге көндә шагыйрь иҗатын өйрәнү белән шөгыльләнүче галимнәр И. Нуруллин, Г. Нигъмәти, М. Гайнуллин, Хатип Госман һ.б. рәсемнәре слайдларда күрсәтелә.

2. Сүзлек эше. Шәҗәрә-нәсел-ыруның кемнән башланып, ничек тармакланып китүен күрсәткән схема, нәсел агачы.

Рәмиевләрнең нәсел шәҗәрәсе карала, кыскача таныштырылып үтелә. Рәмиев фамилиясе каян килүе күрсәтелә. Бертуган Рәмиевләр Юлык авылында мәчет, мәдрәсә, китапханә, русча укыта торган мәктәп салдыралар.

Шакирның хатыны Гәүһәр-заманында мәктәп-мәдрәсәләр ачучы, аларны җиһазлау, кызлар өчен чигү, тегү ише һөнәргә өйрәтүче курслар ачкан шәхес.

Закир Орск сәүдәгәре Борнаевның Мәһүбә исемле кызына өйләнә. Өйләнгәч Оренбургка күчеп киләләр. Мәһүбә Оренбург төбәгендә кызлар өчен берничә мәктәп ачып тоткан. (рәсемнәре слайдларда күрсәтелә).

*Бертуган Рәмиевләр шикелле милләт өчен хезмәт куйган Шәрәфләр турында мәгълүмат бирелә.*

Гыйльметдин Шәрәф эшчәнлеге:

20 нче еллар башында Г. Шәрәф татар банкын төзү өлкәсендә эш башлап җибәрә. Банк ачылгач, аны банкның идарә әгъзасы итеп сайлап куялар. Монда ул 1926 нчы елга кадәр эшли. Шушы чорда шактый изге эшләр башкара. Шул исәптән Аксуда мәктәп төзүгә һәм ачуга зур өлеш кертә. (Алар төзегән мәктәп рәсеме күрсәтелә). Аларның максаты Аксуны шәһәр тибында үстерү була: базар оештыру, больница төзү, яныннан тимер юл уздыру. Ләкин болар тормышка ашмый, чөнки бертуган Шәрәфләр репрессияләнә.

З.Рәмиев Оренбург губернасыннан Дәүләт Думасына депутат булып сайлангач, ярлыларга һәм ятимнәргә зур ярдәм күрсәтә. Шуның өстенә ул үз исәбенә чит илләрдә студентлар укыта, мәктәп-мәдрәсәләр өчен дәреслекләр алып бирә.

Бер укучы хәзерге чорда ятим балаларга зур изгелек күрсәткән Әсгать Галимҗанов турында сөйли. (рәseme слайдта күрсәтелә). Икенче укучы эшмәкәрләр Нәфис һәм Рәфис Кашаповлар эшчәнлеге турында сөйли.

**Үзбәя.**

**Укытучы сүзе:** 1905 нче елгы революция татар телендә газета-журналлар чыгару мөмкинлеге бирә. Рәмиевләр тырыша торгач, 1906 нчы елның февралендә – «Вакыт» газетасы, 1908 нче елның гыйнварында «Шура» журналы чыгара башлыйлар. «Вакыт» газетасының мөхәррире Ф. Кәрими була.

Ф. Кәрими турында сөйлиләр (рәсемнәре күрсәтелә).

Р. Фәхретдин турында чыгыш.

**Үзбәя.**

Шәҗәрә буенча аларның Рәмиевләр белән бәйләнеше аңлатыла.Ш.Рәмиев кызы – Фирдәвес-Р.Фәхретдиннең килене.

Ф.Кәриминең хатыны-Мәгъсүмә-Риза Фәхретдиннең апасы. Ш. Рәмиевнең кызы-Камилә-Садри Макъсудиның хатыны була.

Шуларга бәйләп авылдашыбыз Борһан Шәрәф турында мәгълүмат бирелә.

Борһан Шәрәф Оренбургка 1905 нче елгы революциядән соң китә. Ул һәм башка бик күп журналистлар Оренбургка Шакир һәм Закир Рәмиевләр чакыруы буенча китәләр. Шул уңай белән Тукай «Яшен» журналында «Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны» дигән бер җыр бастыра. (аның үзен дә чакыралар, ләкин ул китми).

Борһан Шәрәф «Вакыт» газетасында Ф. Кәрими җитәкчелегендә эшкә керешә. 1917 нче елга кадәр ул газетаның махсус хәбәрчесе була. Ираннан, Бохарадан

хәбәрләр җибәрә. 1924 нче елга кадәр газетада тәрҗемәче була. Б. Шәрәф Ф. Кәриминең сеңелесе-Закирәгә өйләнә.

Октябрь вакыйгаларын Дәрдмәнд ялгыз каршылый. (Шакир үлгән була). Оренбургтагы йортын калдырып, Орскига күчеп китәргә мәҗбүр була. Типографиясен, алтын приискаларын яңа хакимияткә тапшыра. Шәхси китапханәсен тар-мар итеп бетерәләр. Шигырьләре дә күпләп юкка чыга.

Балкан приискасындагы йортыннан бер бүлмә бирәләр. 1921 нче елга чаклы шунда яши *(рәсеме слайдта күрсәтелә)*.

Нәсел агачы буенча хәзерге буын вәкилләре турында кыскача сөйләшү:

Бер укучы Искәндәр Рәмиев турында сөйли.

Икенче укучы «Дәрдмәнд оныгы Бәшир» исемле мәкаләнең эчтәлеген сөйли («Ватаным Татарстан» 14.09.1994»).

Галимҗан Шәрәф турында белешмә бирү. (рәсемнәре слайдларда күрсәтелә). Г. Шәрәфнең хатыны-Әсма-Р. Фәхретдиновның кызы була.

Шулай итеп. Зыялы кешеләр үзләренә тормыш иптәше итеп тә укымышлы даирәдән парлар табалар. Бертуган Рәмиевләр бертуган Шәрәфләр белән тыгыз элемтәдә яшәгәннәр.

**III. Рефлексия, бәя этабы.**

**1.** Рефлексия.

Бүгенге көндә Оренбург шәһәрендә Дәрдмәнд йортына мемориаль такта куелган. Аның тормышы турында күп мәкаләләр язылган («Казан утлары» журналлары буенча курсәтелә). Ләкин иҗаты әле тулысынча анализланмаган. Дәрес башында куелган сорауларга җаваплар бирү.

Шулай итеп, З. Рәмиев, шәхес буларак, нинди кеше?

**Үзбәя, бәя.**

**Өйгә эш:** 1. Дәрдмәнд тормышы һәм иҗаты турында сөйләргә. 2.Бертуган Шәрәфләр турындагы Р.Вәлиевнең «Фаҗига» китабын укырга. 3. Өлкәннәр ярдәме белән үз шәҗәрәңне төзергә.

## ТЕМА: Ә. ЕНИКИНЕҢ «МАТУРЛЫК» ӘСӘРЕН ӨЙРӘНҮ (9 НЧЫ СЫЙНЫФ)

**Р.К. Билалова, Чистай районы**

**Максат:** 1. «Матурлык» хикәясенең эчтәлегенә төшендерү. 2. Әсәргә анализ ясау алымнарын кулланып, хикәянең тәрбияви әһәмиятен билгеләү, анда күтәрелгән мәсьәләләрнең хәзерге вакытта да мөһим икәнлеген күрсәтү.3. Укучыларда ата-анага карата миһербанлык тәрбияләү, укучыларда матур әдәбиятка мәхәббәт уяту.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәрне үзләштерү.

**Җиһазлау:** Ә. Еники портреты, әсәрләреннән китап күргәзмәсе, «Салкын чишмә» көе язмасы, түбәндәге эчтәлекле плакат:

Ана – бөек исем!
Нәрсә җитә Ана булуга.
Хатын-кызның бөтен матурлыгы,
Бөтен күрке Ана булуда...
(Һ.Такташ)

### Дәрес барышы

**I. Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.**

1. Дәресне оештыру моменты.

**Укучылар:**Чыңлады көмеш кыңгырау. Безне дәрескә чакырып. Кызыклы дәресне башлыйк. Парталар артына утырып.

**Укытучы:** Рәхмәт, ә хәзер бер-беребезгә уңышлар теләп, дәресебезне башлап җибәрик.

2. Мотивлаштыру.

**Укытучы:** Укучылар, без сезнең белән Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники иҗатын өйрәнүне дәвам итәбез. Алдагы дәресләрдә без аның тормыш юлы, иҗатының бер өлеше белән инде танышып үткән идек. Шулай ук аның сугыш елларында иҗат иткән хикәяләрен дә укып таныштык һәм, гомумән, Ә.Еникине хикәяләр остасы дип атадык. Кеше хисләрен бөтен барлыгы белән тасвирлау ягыннан Ә.Еники әсәрләре аерылып тора. Кеше күңеленең «аулак почмагында» сакланган кадерле серләрне күрә белү, үзәк өзәрдәй сагышны, сөенеч һәм көенечләрне тормыш вагыйгалары ярдәмендә үзенә генә хас булган язу алымы ярдәмендә күрсәтә белү – Ә.Еники стиленең үзенчәлекле ягы әнә шунда. Әйдәгез, аның әсәрләрен санап китик. *(Укучылар игътибарын китап күргәзмәсенә җәлеп итү)*

Күренекле шагыйрь Илдар Юзеев аны «Күңел карурманнарының тургае», дип атады. Ни өчен Илдар Юзеев шулай атаган икән? Дәрес барышында без бу сорауга да җавап бирергә тырышырбыз.

**II. Үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү: Ә. Еникинең тормыш һәм иҗат юлы (тест).

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

1. Актуальләштерү.

Һ.Такташның: *Хатын-кызның бөтен матурлыгы, бөтен күрке Ана булуда...* сүзләренә игътибар итик әле. Бүгенге сөйләшүебез, кемнәр турында булыр?

***Укучы:*** *Әниләр турында. Ана – ул дөньяда иң бөек шәхес. Бала дөньяга килгәнче, ана кеше аны йөрәге янында 9 ай буе йөртә. Тугач, күкрәк сөтен имезеп, төннәр буе аңа бишек җыры көйли. Үсә төшкән саен ата-аналар белән балалар арасында бик күп яңа мәсьәләләр килеп туа. Алар элек-электән, буыннан-буынга күчеп килгән. Һәм бик күп язучылар аларны үз иҗатларында чагылдыра.*

**Укытучы:** Сез моңа нинди мисаллар китерә аласыз?

*(Ә. Еники «Әйтелмәгән васыять», М. Җәлил «Ана бәйрәме», Туфан Миңнуллин «Әниләр һәм бәбиләр», И.С.Тургенев «Аталар һәм балалар» романы).*

***Укучы:*** *Алдагы сыйныфларда әдипнең «Әйтелмәгән васыять» әсәре белән танышкан идек. Әмирхан ага әлеге повестенда безгә халыкның рухи хәзинәсенә хөрмәт белән карарга, әти-әниләребезне соңгы көнгәчә тәрбияләп, аларның хәер-фатихасын алырга кирәклекне искәртә кебек.*

**IV. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

**Укытучы:** Сез өйдә язучының «Матурлык» хикәясен укып килдегез. Хәзер сөйләшүне әсәрнең үзенә юнәлтик. Алдыгызда әдәби әсәргә анализ үрнәге. Эш барышында без бу анализ үрнәгенең кайбер өлешләренә тукталып китәрбез.

**1.** Әсәргә анализ.

**Укытучы:** Әсәрнең исеменә игътибар итик әле. Ничек атала? Сез «матурлык» дигән төшенчәне ничек күзаллыйсыз? *(укучылар чыгышы)*

**Укытучы:** Җавапларыгызны хуплыйм. Ә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә менә болай аңлатма бирелгән. 1. Матурлык – гүзәл, күңелгә рәхәтлек бирә тор-

ган нәрсә (күренеш, эш, тормыш һ.б.); матур, сокланырлык урыннар (табигатьтә, матур әдәбият әсәрләрендә).

2. Ягымлы, сөйкемле, үзенә җәлеп итә торган тышкы кыяфәт; кеше характерындагы, эшчәнлегендәге хуплана торган сыйфат.

***Нәтиҗә:*** матурлык – бик тирән мәгънәле төшенчә ул. Шушы халык мәкальләрен укысак, матурлыкның чын мәгънәсенә төшенә алабыз *(мәкальләр уку).* Матурлыкны берегез табигатьтә күрә, икенчегез кеше күңеленең матурлыгы дип саный, өченчегез матурлык ул – беренче мәхәббәт, ди. Болары да дөрес. Ә матур кеше нинди сыйфатларга ия була*? (5нче слайд).* **М-**мәгънәле, миһербанлы; **А-**акыллы, аңлы; **Т**-тыйнак, тәртипле**; У-**уңган, укымышлы; **Р-**риясыз, рәхимле, рухи бай.

**Укытучы:** Укучылар, әйдәгез, бу әсәрнең жанрын билгеләп үтик.

***Укучы:*** *Бу әдәби әсәр хикәя жанрына карый, чөнки сөйләп бирүгә, хикәяләүгә нигезләнгән, катлаулы булмаган вакыйгаларны сурәтләгән кечкенә күләмле жанр төре.*

**Укытучы:** Хикәянең формасына игътибар итик әле. Кем исеменнән сөйләнә?

***Укучы:*** *Хикәядәге бөтен вакыйгага геройларның берсе бәя бирә. Без дә һәр күренешне аның күзе белән күрәбез. Ләкин бу күз шәкерт күзе түгел, ә карт әдип күзе. Карт әдип шәкерт чагын исенә төшереп, шул шәкерт чагындагы хисләренә үзенең өлкән кеше хисләрен дә өстәп сөйли.*

**Укытучы:** Хикәянең темасын билгелик. Ягъни без әсәр нәрсә турында дигән сорауга җавап табабыз. Ә.Еники үзенең бу әсәрендә «Матурлык» темасын ничек итеп ача соң? Авторның матурлыкны нинди мәсьәләләр аша күтәргәнен әйтеп китик.

***Укучылар:*** *Әсәр матурлык турында. Кешенең эчке матурлыгы. Бәдретдиннең күңел матурлыгы. Ана белән бала мәхәббәтенең матурлыгы. Гаилә мөнәсәбәтләренең матурлыгы. Табигать матурлыгы турында.*

**2. Төркемнәрдә эш**. Төркемнәрдә шушы мәсьәләләрне тикшереп китик әле.

1 төркем – Бәдретдиннең күңел матурлыгы;

2 төркем – Гаилә мөнәсәбәтләренең матурлыгы;

3 төркем – Шәкертләрнең матур мөгалләмәсе. *(укучыларның төркемнәрдә җаваплары)*

**Укытучы:** Хикәядә нинди вакыйгалар сурәтләнә?

***Укучы:*** *Берсе табигать күренеше, икенчесе Бәдретдин өендәге вакыйга.*

**Укытучы:** Хикәядә күренеп торган конфликт, ягъни каршылык бармы?

***Укучы:*** *Бар. Ямьсезлек - матурлык каршылыгы.*

**Укытучы:** Матурлыкны шәкерт ничек күрә? *(Ул урыннарны кычкырып уку).* Табигать хикәядә кабатланып бирелә. Ни өчен икән?

**Укытучы:** Шушы матурлыкка нәрсә каршы куела?

***Укучы.*** *Бәдретдиннең өе һәм өй эчендә герой-шәкерт күргәннәре. Ләкин беренче күргәндә ямьсез, чирканчык булып тоелган ямьсезлек тора-бара матурлыкка әйләнә бара. Лирик герой-шәкерт башта аптырый, аннан соң гаҗәпләнә, бу матурлыкка соклана.*

**Укытучы:** Шәкерт матурлыкны нидә күрә соң? Матурлык кайда? Бәдретдиндәме? Аның әнисендәме? Әллә әтисендәме?

***Укуч:****. Барысында да. Ләкин бу матурлык аерым-аерым матурлык түгел. Ул бу иске өйдәге ямьсез, имгәнгән кешеләрнең үзара мөнәсәбәтендә. Өй эчендәге «гади, табигый, җылы-якын мөнәсәбәттә». Шушы өй эчендәге*

*хәерчелек, ятимлек эченнән, чәчәк кебек, бу кешеләрнең үзара татулыгы, яратышуы, мәхәббәтләренең табагыйлеге үсеп чыга. Лирик герой шуны күреп ала. Бәдретдин әнисенең ямьсезлегеннән дә, гариплегеннән дә, бабасының сукырлыгыннан да, әтисенең мескенлегеннән дә уңайсызланмый. Бу кимчелекләрне ул бөтенләй күрми. Өйдәге бу мескенлекләр зур мәхәббәт астында күмелеп калалар. (Укучылар бу ямьсез ананың күзләре турында язылган урынны табын укыйлар, 235 бит, өстән икенче абзац)*

**Укытучы:** «Күңел көзгесе» дигән төшенчәне ничек аңлыйсыз? (Фикер алышу). Хикәянең сюжетына игътибар итик. Вакыйгалар үстерелешен, кульминацион ноктасын, чишелешне билгеләп китик әле.

**Укучылар:** *(Экспозиция - 1, 2 нче абзацлар; вакыйгалар үстерелеше-Бәдретдиннең кем икәнен ачыклау; кульминация – ананың йөзен күреп, шәкертләрнең тетрәнүе; чишелеш – куелган сорауларга җавап бирү һәм соңгы җөмлә.)*

**Укытучы:** Әнисе ни өчен Бәдретдин белән горурлана? Сез ананың бу хисе белән килешәсезме? Бәдретдин горурланырлык шәкертме? Бу образга характеристика биреп китик әле. *(Бәдретдингә характеристика бирү)*

**Укытучы:** Бәдретдиннең скрипкада уйнавы әллә ни түгел. Көе дә чеби тавышы кебек кенә чыга. Ләкин лирик герой- шәкерткә «бик ягымлы, бик тансык» булып яңгырый. Ни өчен?

***Укучы:*** *Бәдретдиннең скрипкада уйнавы дусларына бик ошый, чөнки скрипка моңнарында алар дусларының әнисенә булган мәхәббәтен, әнисенең улы белән горурлануын күрәләр. Искә төшерик: улы әнисеннән: «Ни уйныйм?» - дип сорый. Бала әнисенең яраткан көен уйный. Анага ул көй үзе кадерле түгел, ә улының шул көй аша күрсәткән хөрмәте, җылылыгы кадерле. Әйтерсең, шул көй аша ана белән бала*

*үзара аңлаша, сөйләшә. Менә ни өчен бу көй шәкертләргә дә бик тансык булып тоела.*

**Укытучы:** Әйдәгез әле укучылар, шушы «Салкын чишмә» көен без дә тыңлап китик. *(«Салкын чишмә» көе)*

**Укытучы:** Хикәя соңында мондый сүзләр бар: «Бу йортның безгә билгесез ниндидер тирән сере – бәхетсезлегеме, фаҗигасеме, әллә без аңлаудан гаҗиз бөек бер өлеше – бәхетеме торып калды». Җавап бирегез: чыннан да, кайсы? Фаҗигасеме, бәхетеме?

***Укучы:*** *Бәхет нәрсә ул?*

***Җавап:*** *Бәхет ананың баласында үзенә карата хөрмәт, ярату күрүендә, баласының уңган булуын күрүендә. Бәдретдиннең ярата белүендә, үзен шулай ярата белә торган әнисе булуында. Бәхет ул байлык та, кычкырып торган шатлык та түгел, ул кешенең кеше була белүендә.*

**V. Яңа белемнәрне үзләштерүне тикшерү.**

**Укытучы.** Кабат тургайларга әйләнеп кайтыйк. Автор ни өчен тургай сайравын ике тапкыр кабатлый?

***Укучы:*** *Матурлык тургай кебек матур кошларда, матур күктә, җирдә генә түгел икән. Дөнья киң икән. Дөньяда алар белмәгән почмаклар да бар икән. Ул почмакларда алар белмәгән күңел матурлыгы бар икән. Бу матурлык җимерек өй эчендә генә бикләнеп ята алмый. Ул барыбер күренә. Ул башка кешеләр күңеленә дә нур чәчә.*

**Укытучы**. Әсәрне йомгаклап, идеясен дә билгелик инде. Язучы нәрсә әйтергә теләгән?

***Укучы:*** *Әдип бу хикәясендә бала белән ана арасында булган мәхәббәт матурлыгын, бөеклеген билгели һәм шушы фикерне зур сәнгать дәрәҗәсенә күтәреп раслый.*

**Укытучы.** Бик күп шагыйрьләр, язучылар әниләр турында дан җырлаган. Әйе, «әни», «әнкәй» сүзләре кайсы

гына телдә әйтелсә дә, ул һәркемгә якын, изге сүз. Баланың шатлыгын, кайгы-хәсрәтен дә Ул уртаклаша, акыллы киңәшен дә бирә. Бу уңайдан Һ.Такташның Ана турында язган шигъри юллары да урынлы булыр.

*Ана – бөек исем!*
*Нәрсә җитә Ана булуга.*
*Хатын-кызның бөтен матурлыгы,*
*Бөтен күрке Ана булуда...*

**VI. Яңа белемнәрне ныгыту.**

**Укытучы:** Әсәрнең әһәмияте нәрсәдә?

*(эстетик кыйммәте (сәнгать әсәре буларак), тәрбияви әһәмияте, әлеге әсәрнең әдәбиятта токтан урыны турында сөйләшү)*

**Укытучы:** «Әмирхан Еники – күңел карурманнарының тургае» Илдар Юзеевның фикерен ничек дәлилләрсез? ***Укучы:*** *Шагыйрь хаклы, Ә.Еники – кешенең күңел кичерешләрен бөтен нечкәлекләре белән белгән язучы.*

**VII. Өйгә эш өч вариантта бирелә:**

1. Матурлык – биеклек символы. Моңа авылыбызның кемнәре лаек? Ни өчен?

2. Әсәргә нинди иллюстрацияләр ясар идегез?

3. «Сезнең өчен ут йотам,

Уйлап карагыз, балам» (шагыйрь Муса Җәлилнең әнисе Рәхимә Җәлилованың балаларына язган шигъри хатыннан өзек) исемле кыска иҗади инша язып килергә. Уңышлар сезгә! *Файдалану өчен материал: Т.Миңнуллин. Кырларым-тугайларым // Пьесалар җыентыгы. – Казан, 1982, 22-26 битләр.*

Рефлексия (дәрескә йомгак ясау).

*Мин бик яхшы эшләдем!*

*Мин яхшы эшләдем.*
*Миңа тырышырга кирәк! (үзбәя бирү)*

**Укучы:**
Әниемнең эше – иң изге эш,
Әниемнең сүзе – иң назлысы.
Әнием кулы – иң йомшагы,
Әниемнең йөзе – иң-иң яктысы!
Авыр сүзне әйтмик әниләргә
Аларга без итик гел ярдәм.
Әниләрне саклыйк, яратыйк
Калсын әле алар гел күркәм!
Әниләргә назлы сүзләр җитми,
Җитми әле мактау, котлау да!
Ә бит әниләрне гел яратып,
Зурлау кирәк барыбызга да!

**Укытучы:** Укучылар, әйдәгез, әниләрне саклыйк, олылыйк, хөрмәтлик. Безнең аларга карата мөнәсәбәтләребез гел Матур булсын! Рәхмәт. Дәрес тәмам.

## ТЕМА: ИСЕМНӘРНЕҢ ТАРТЫМ БЕЛӘН ТӨРЛӘНЕШЕ (3 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**Р.Д. Маннапова, Яр Чаллы**

**Дәреснең максаты һәм бурычлары:** Тартым кушымчасының функцияләрен һәм төрләрен билгеләргә һәм бу төр кушымчаларны аерып ала белергә өйрәтү; тартым кушымчаларының затын һәм санын билгеләү ысулларын сайлап ала белү күнекмәләрен формалаштыру; алгоритм төзү һәм шул алгоритм буенча эшли белү күнекмәләрен формалаштыру; бердәмлек, берлек хисен тәрбияләү.

**Дәреснең тибы:** Яңа белемнәр ачу дәресе.

**Регулятив универсаль уку эшчәнлеге:**

– мөстәкыйль рәвештә дәреснең темасын, максатын, бурычларын билгели белү;

– куелган максатка ирешү өчен үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү;

– эшчәнлекне башкарып чыкканан соң аңа үзгәрешләр кертә белү;

– биремне үтәгәндә үз эшчәнлегеңне аңлата белү; эшчәнлеккә бәя бирә белү.

**Коммуникатив универсаль уку эшчәнлеге:**

– фикереңне төгәл аңлата белү;

– биремнәрне укый һәм кабул итә белү;

– башкаларны тыңлый һәм аларның фикерен кабул итә белү;

– төркемдә эшли белү.

**Танып-белү универсаль уку эшчәнлеге:**

– белемнәр системасында ориентлаша белү; үзләштергән һәм яңа белемнәрне аеру;

– дәреслек һәм дәрестә алынган информация нигезендә яңа белемнәр ачу, сорауларга җавап бирү.

**Шәхси универсаль уку эшчәнлеге:**

– эшчәнлеккә үзбәя бирә белү;

– әхлак сыйфатлары формалаштыру.

**Җиһазлау:** компьютер, интерактив такта, презентация.

## Дәрес барышы

**1. Уку эшчәнлеген мотивлаштыру.**

Максат: укучыларны уку эшчәнлегенә тарту, уңай психологик мохит тудыру**.**

– Хәерле иртә, балалар.

– Хәерле иртә бүген.

– Кәефләрегез ничек соң?

– Кояшлы иртә кебек,

– Татар телен, Тукай телен

– Өйрәнергә дип килдек.

– Бүген туган телебез турында тагында күбрәк белербез. Сез бергәләп эшләргә әзерме? Ягез, бер-берегезгә карап елмаегыз һәм уңышлар теләгез. Дәфтәрләрдә бүгенге датаны языйк.

– Әйдәгез дәресне шигъри тәлгәшләрдән башлыйк әле. (Укытучы шигырь укый, сүзләре слайдта чыга):

Әби күзлек кия,
Чәчләренә ак кунган,
Беркөн дә соңга калмый,
Иртүк тора йокыдан.

– Я, кем бик игътибарлы? Нәрсә сиздегез? (Хата бар: әби түгел, әбием сүзе кирәк.)
– Хатаны төзәтик. Ә хәзер шигырьне хор белән укыгыз.
– Әбием күзлек кия,
– Чәчләренә ак кунган,
– Беркөн дә соңга калмый,
– Иртүк тора йокыдан.
– Кайсы вариант матурырак яңгырый, ни өчен? (2 нче вариант матур. Әбием йомшак әйтелә, ягымлылык өсти, әбинең бик кадерле кеше икәнен күрсәтә.)
– Шигырьнең исеме ничек, авторын искә төшерегез. (Минем әбием. Г. Латыйп сүзләре, А. Ключарев көй язган.)
– Әбием сүзендә -ем сүзнең кайсы кисәге? (Кушымча)
– Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшербез? (Кушымча турында. Кушымчалар турында белемнәребезне тирәнәйтәбез, яңа белемнәр ачабыз.)
– Яңа белемнәр ачу өчен безгә башта нишләргә кирәк? (Кушымчалар турында белгәннәрне искә төшерергә кирәк.)

**2. Алган белемнәрне искә төшерү (актуальләштерү).**

Максат: эшчәнлекнең яңа ысулын ачуга әзерләү**.**

– (Континиус Раунд Робин) 1 номерлы конвертны төркемнәрдәге 3 номерлы катнашучы ача, сораулар язылган карточканы ала, беренче укучыдан башлап, бирелгән сораулар нигезендә кушымча турында белгәннәрне искә төшерегез, җавапларны, мисаллар китереп, дәлилләгез.

Сораулар:

– Нәрсә ул кушымча?
– Кушымчаларның төрләрен искә төшерегез.

– Сүз ясагыч кушымчалар нинди эш башкаралар? Җавабыгызны дәлилләгез.

– Төрләндергеч кушымчалар ничә төркемгә бүленәләр?

– Сан кушымчасы нишли?

– Килеш кушымчалары ни өчен кирәк?

– Сорауларга 4 төркем җавап бирә башлый:

1 катнашучы: Кушымча – сүз кисәге, тамырдан соң языла, җөмләдә сүзләрне үзара бәйли.

2 катнашучы: Кушымчалар ике төркемгә бүленә: сүз ясагыч һәм төрләндергеч кушымчалар.

3 катнашучы: Сүз ясагыч кушымчалар сүзнең лексик мәгънәсен үзгәртәләр, яңа сүз ясыйлар. Мәсәлән, кошчык. Кош – зур кош, кошчык – аның баласы.


4 катнашучы: Төрләндергеч кушымчалар ике төркемгә бүленәләр: сан һәм килеш кушымчалары.

5 төркем 1 катнашучыдан башлап җавап бирә: Сан кушымчалары предметны яки аның эш-хәрәкәтен берлек һәм күплек санга куя, мәсәлән, китап, китаплар.

2 катнашучы: Килеш кушымчалары сүзләрнең формасын үзгәртеп, аларны үзара бәйли, мәсәлән, урманга – сүзгә юнәлеш килеш кушымасы ялганган.

– Кушымчаларны тикшерү алгоритмын искә төшерик. (Укучылар схеманың тәртибен әйтәләр, схема слайдта барлыкка килә.)

– Афәрин, булдырдыгыз.




– Без нинди белемнәрне искә төшердек? (Кушымчаларның төрләрен һәм аларның функцияләрен санадык.)

– Ни өчен кабатлау үткәрдек? (Бу белемнәр безгә уку мәсьәләсен табарга ярдәм итәчәк.)

**3. Уку мәсьәләсен табу.**

Максат: килеп чыккан авырлыкны табу, аның урынын һәм сәбәпләрен билгеләү.

– Әйдәгез, уку мәсьәләсен ачыклыйк. Түбәндәге сүзләрне бирелгән алгоритм буенча тикшерегез: дуслык, ярдәмчеләр, әнием (укучылар парларда эшли)

– Кемнәр биремне үти алмады? Ни өчен? (Әнием сүзендә -ем кушымчасының төрен билгели алмадык.)

– Ә кемнәр бу кушымчаның төрен аера алды? Җавабыгызны дәлилләгез. (-ем кушымчасы яңа сүз ясамый, димәк әни сүзен төрләндерә. Тик ул сан кушымчасы да түгел, килеш кушымчасы да түгел, ничек аталганын әйтә алмыйбыз.)

– Бу кушымчаның нинди эш башкарганын әйтә аласызмы? (Юк)

**4. Уку мәсьәләсен чишү проектын төзү.**

Максат: уку эшчәнлегенең максатын билгеләү, максатка ирешү юлларын һәм чараларын табу**.**

– Бүгенге дәреснең максаты нинди? (Яңа төр кушымчаның нинди эш башкарганын ачыклау, төрен билгеләү, схемада урынын табу.)

– Әнием сүзе белән җөмлә төзегез. (Бер укучы такта алдында эшли. Минем әнием гөлләр үстерергә ярата.)

– Җөмләдә кем турында сүз бара? (Әни турында).

– Ул кемнең әнисе соң? (Авторның әнисе).

– Ә автор кем? Җөмләне төзегән баланың исемен әйтәләр. Мәсәлән, Айнурның әнисе).

– (Укытучы класска мөрәҗәгать итә) – Айнурның әнисе турында нәрсә белдегез, языгыз. (Айнурның әнисе гөлләр үстерергә ярата. Бер укучы бу җөмләне тактага яза).

– Булат син Айнурның әнисе турында нәрсә белдең, Айнурның үзенә шул турыда әйт әле. (Айнур, синең әниең гөлләр үстерергә ярата. Җөмлә тактага һәм дәфтәрләргә языла).

– Ә сезнең әниләрегез гөлләр үстерергә яраталармы соң? Шул турыда җөмлә языйк әле.

Тактада: Минем әнием гөлләр үстерергә ярата.

Айнур, синең әниең гөлләр үстерергә ярата.

Айнурның әнисе гөлләр үстерергә ярата.

Безнең әниләребез дә гөлләр үстерергә яраталар.

– Беренче җөмләдә әни кемнеке? (Минем әнием).

– Икенче җөмләдә әни кемнеке? (Синең әниең).

– Өченче җөмләдә әни кемнеке? (Аның әнисе).

– Дүртенче җөмләдә әни кемнеке? (Безнең әниләребез).

– Беренче җөмләдә әни кайсы затка карый? (1 затка, берлек сан).

– Икенче җөмләдә әни кайсы затка карый? (2 затка, берлек сан).

– Өченче җөмләдә әни кайсы затка карый? (3 затка, берлек сан).

– Дүртенче җөмләдә әни кайсы затка карый? (3 зат, күплек сан).


– Нинди нәтиҗә ясыйбыз инде? ( -ем, -ең, -се, -ебез кушымчалары әни сүзенең кайсы затка караганын аңлата, алар берлек һәм күплек санда булалар.)

**5. Проектны тормышка ашыру.**

Максат: тартым кушымчасын схемада күрсәтү.

– Бу кушымчалар ничек атала икән? Моның өчен без дәреслекнең 40 битен ачыбыз, кагыйдәне укыбыз. (Тартым кушымчалары)

– Тартым кушымчасының урынын схемада күрсәтегез, эшчәнлекнең һәр адымын бергәләп билгеләгез. (Төркемдә эш) 2 номерлы конвертны төркемнәрдәге 1 номерлы катнашучы ача, схеманы ала.




(Слайдта схема күрсәтелә, һәр төркем үз эшен бәяли).

– Уку мәсьәләсен чишә алдыкмы? (Әйе, тартым кушымчалары турында белдек.)

– Хәзер без тартым кушымчаларын билгели алабызмы? (Схема буенча тикшерергә кирәк.)

– Нинди нәтиҗә ясыйбыз? (Без авырлыкны чиштек. Тартым кушымчаларын таба беләбез.)

**6. Беренчел ныгыту.**

Максат: тартым кушымчасын тикшерү алгоритмын төзү, яңа белемнәрне практикада куллану

– Хәзер нәрсә белән шөгыльләнербез? (Алган белемнәрне гамәлдә ныгытырга кирәк. Моның өчен күнегүләрне башкарырбыз). Дәреслекнең 40 битендә күнегүне табыгыз һәм укыгыз. Биремне каршыдагы партнерыгыз белән эшләгез. (ТАЙМД ПЭА ШЭА) (Бирем: сүзләрне укырга, кушымчасын билгеләргә һәм мәгънәсен аңлатырга ( сүзләр – китабым, ручкам, балалары, кешеләре, авылның, күлләре).

– Предметларның кайсы затка караганын ничек белдегез? (Зат алмашлыгы белән исемнән торган сүзтезмә ясыйбыз, минем китабым).

– Кемнәр биремне үтәгәндә авырлык кичерде? (Кайбер укучылар авылның сүзендә ялгышырга мөмкин).

– Кем авырлыктан чыгу юлын аңлата ала? (Авылның сүзе яныны бер зат алмашлыгын да куеп булмый, ул иялек килеш кушымчасы.)

– Балалары сүзенә кайсы алмашлыкны куйдыгыз? (Ике төрле вариант бар: Аның балалары, аларның балалары.)

– Ә тартым кушымчасын ничек тикшерербез?


1. Тамырны билгелим: бала.

2. Кушымчаларны табам, төрен билгелим: - лар – күплек сан кушымчасы,; -ы – тартым кушымчасы, 3 затка карый (санын билгеләү авыр).

– Дәреслекнең 41 битнен ачыгыз, күплек сандагы тартым кушымчалары турында нәрсә әйтелгән укыгыз (-лары күплек сан кушымчасы дип бирелә)

– Нинди нәтиҗә ясыйбыз? (предмет күплек санда бирелсә, тартым кышымчасы да күплек санда була, димәк, балалары сүзендә -ы тартым кушымчасы күплек санда була. )

– Схемага нәрсә өстибез?




– Чәчләреннән сүзен дәфтәргә языгыз һәм алгоритм буенча тикшерегез:

1. Сүзнең тамырын билгелим: чәч.

2. Кушымчаларын табам, төрен билгелим:

- ләр – төрләндергеч күплек сан кушымчасы;

- ен – аның чәчләрен, 3 зат, күплек сан тартым кушымчасы, чөнки предмет күплек санда бирелгән;

- нән – төрләндергеч чыгыш килеш кушымчасы.

**7. Мөстәкыйль эш һәм эталон буенча үзеңне тикшерү.**

Максат: алган белемнәр һәм дәреслектәге информация нигезендә тартым кушымчаларын табу.

– 4 нче номерлы катнашучы 3 нче номерлы конвертны ача, карточкаларны тарата, биремне үтисез,биремне башкарганда дәреслекнең 40 битендәге кагыйдәдән файдаланыгыз.

Бирем: күп нокталар урынына тиешле кушымчаны языгыз.

| Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|
| 1 зат дәфтәре…, китап… | 1 зат болыннар…, төннәр… |
| 2 зат көн…, бала… | 2 зат авыллар…, күлләр… |
| 3 зат шәһәр…, чаңгы… | 3 зат кызлар…, җирләр… |

ЭТАЛОН буенча тикшерү.

| Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|
| 1 зат дәфтәрем, китабым | 1 зат болыннарыбыз, төннәребез |
| 2 зат көнең, балаң | 2 зат авылларыгыз, күлләрегез |
| 3 зат шәһәре, чаңгысы | 3 зат кызлары, җирләре |

**8. Белемнәр системасына кертү.**

Максат: алган белемнәрнең дәрәҗәсен тикшерү, алдагы эшчәнлекне билгеләү**.**

(Финк-Райт-Раунд Робин) 2 нче катнашучылар 4 нче номерлы конвертны ачалар, биремне үтисез: түбәндәге сүзләргә тиешле кушымчаларны ялгап, килеп чыккан сүзләрне дәфтәргә яз, сүз составы буенча тикшер:

карлыгач + 2 зат, берлек сан тартым кушымчасы;

оч + сүз ясагыч кушымча + 1 зат, берлек сан тартым кушымчасы;

кул + 3 зат, берлек сан тартым кушымчасы+ чыгыш килеш кушымчасы; үрдәк + күплек сан кушымчасы + 3 зат тартым кушымчасы.

– Килеп чыккан сүзләрне 1 катнашучыдан башлап түгәрәк буенча укып чыгыгыз (Карлыгачың, очкычым, кулыннан, үрдәкләре).

**9. Рефлексия.**

Максат: уку максаты белән ирешелгән нәтиҗәләрне чагыштыру, үзбәя бирү**.**

– Бүгенге дәрестә нинди максат куйган идек? (Яңа төр кушымчаның нинди эш башкарганын ачыклау, төрен билгеләү, схемада урынын табу)

– Максатка ирештекме? Дәлилләгез. (Без тартым кушымчасының урынын схемада таптык, алгоритм төзедек).

– Без алган белемнәр тормышта кирәк булачакмы соң? (Тартым кушымчаларны сөйләмне матурлый, үзара якынлык хисен тудыра, предметның сөйлүчегә кадерле икәнен аңлата).

– Димәк тартым кушымчалары үзара матур итеп аралашу өчен кирәк икән.

– Кемгә дәрестә җиңел булды?

– Кем әлегә аңлап бетермәде?

– Авырлыкны җиңәргә кем яки нәрсә ярдәм итте?

– Кем бүген үз эшеннән канәгать?

**10. Дәрескә йомгак, өй эше бирү.**

– Афәрин булдырдыгыз. Тартым кушымчасы ни өчен шулай атала? Ни өчен тартым. Предмет миңа кадерле, югалтасым килми. Үземә тартып китерәм, кочагыма алам. Мәсәлән, бу минем китабым (укытучы дәреслекне күкрәгенә кыса), ул миңа Тукай телен аңларга ярдәм итә, матур итеп сөйләшергә өйрәтә).

– Өй эше: сез иң кадерле кешегез, әниегез турында кечкенә хикәя төзегез. Тартым кушымчаларының астына сызыгыз.

# II БҮЛЕК.

# РУС МӘКТӘБЕНДӘГЕ
# ТАТАР БАЛАЛАРЫНА
# ТАТАР ТЕЛЕ
# ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУ

## ТЕМА: БЕРЛЕК
## ҺӘМ КҮПЛЕК САНДАГЫ ИСЕМНӘР
## (3НЧЕ СЫЙНЫФ)

**К.К. Ахметшина, Яр Чаллы**

**Дәреснең темасы:** Берлек һәм күплек сандагы исемнәр.

**Дәреснең тибы:** Яңа белемнәрне ачу.

**Максат:**

1. Исемнең берлек һәм күплек саннары, күплек сан кушымчалары турында мәгълүмат бирү. Күплек сан ясаучы кушымчалар белән танышу. Кушымчаларны ялгау кагыйдәләрен үзләштерү. Исем турында белемнәрне ныгыту. Авазларның дөрес әйтелеше өстендә эшне дәвам итү.

2. Анализлау һәм чагыштыру осталыгын үстерүне дәвам итү. Бирелгән мәгълүматның иң әһәмиятлесен аерып алырга өйрәтү. Төркемдә эшләү, аралаша белү һәм фикер осталыгын формалаштыру.

3. Татар теленә ихтирам, әйләнә-тирәгә мәхәббәт уяту.

**Җиһазлау:** Җәнлек, кошлар, агачлар рәсемнәре. Сүзләр язылган карточкалар.

**Дәрес барышы**

| | |
|---|---|
| I.Оештыру-мотивлаштыру этабы.<br>Эшләү өчен без бүген ике төркемгә бүлендек. Төркем җитәкчеләре итеп кемнәрне сайлыйсыз.<br>– Төркем җитәкчеләре сез төркемдәгеләрнең эшен оештырырга,күзәтергә, бәяләргә ярдәм итәрсез.Тартмаларда смайликлар. Дөрес эш, тулы җавапларыгыз өчен сез смайликны үзегез аласыз.<br>II.Өй эшләрен тикшерү. Текстның тәрҗемәсен тыңлау. | Регулятив универсаль уку гамәлләре (максат кую, планлаштыру) |
| III. Актуальләштерү.<br>– Аю йоклаган шул урманга барасыгыз киләме?<br>– Әйдәгез җыеныйк та урманга экскурсиягә барыйк.<br>– Кышкы урманга бару өчен безгә ниләр кирәк була?<br>– Чаңгы, куртка, башлык, бияләй,<br>1) Бу сүзләр кайсы сүз төркеменә карый? (исем)<br>2) Исем нәрсәне белдерә?(предметны)<br>3) Исем нинди сорауларга җавап бирә?(Кем? Нәрсә?)<br>– Бу әйберләр һәркайсыбызга да кирәк булачак. Аларны күп итеп алыйк әле. Нәрсәләр алабыз?<br>– Чаңгылар, курткалар,башлыклар, бияләйләр.<br>– Димәк, бу предметлар нинди санда? Бу предетлар күплек санда. | Коммуникатив универсаль уку гамәлләре |

| | |
|---|---|
| – Ә берлек санда булса ничек була? (Чаңгы....)<br>– Димәк, бүгенге дәреснең темасы нинди булыр икән?(Берлек һәм күплек сандагы исемнәр.)<br>– Алдыбызга нинди максат куябыз?<br>– Бу максатка ирешү өчен дәрестә ничек эшләрбез?<br>IV. Яңа материалны аңлату этабы.<br>– Экскурсияне башлыйбыз. Урманда үзеңне ничек тотарга кирәк?<br>Карагыз әле, балалар, урман хуҗасы – аю безгә ниндидер серле тартма калдырган. Ачып карыйк әле анда ниләр бар икән?<br>– Ниндидер конвертлар?..<br>–Яшел конвертларга нәрсә язылган? Җәнлекләр<br>– Сары конвертларга нәрсә язылган? (АГАЧЛАР)<br>– Кызыл конвертларга өй эше дип язылган. Аларны әлегә читкәрәк алып куегыз. Тавышланмыйча гына без хәзер җәнлекләрне күзәтербез. Яшел конвертларны алыгыз әле. Анда сүзләр язылган карточкалар бар. Мин җәнлекне күрсәтәм кайсы төркемдә ул җәнлекне атаучы сүз бар, тактага чыгып ябыштырып куябыз.<br>(Рәсемнәрне карыйлар, тактага берлек сандагы сүзләрне ябыштырып куялар )<br>– Кайсы җәнлекләрне без кышкы урманда очратмыйбыз? (Аю, керпе)<br>– Тактадагы сүзләрне сузык аваз | Шәхси (әхлакый) универсаль уку гамәлләре<br><br>Регулятив универсаль уку гамәлләре(максат кую, планлаштыру) |

| | |
|---|---|
| хәрефләре буенча ике төркемгә бүләргә кирәк.<br>– Нинди төркемнәргә бүләр идегез? (Нечкә, калын)<br>– Ни өчен?<br>– Кайсы сүз бу төркемнәрнең берсенә дә керми? Поши<br>– Ни өчен? (Кабатлап әйтеп карыйлар)<br>– Урманда җәнлекләр күп булалар бит, әйдәгез аларны күплек санда язабыз. (Башта матур язу минуты үткәрелә, тактада бер укучы эшли, дәфтәрләргә бу сүзләрне күплек санда язалар<br>– Ни өчен поши сүзенә -лар /-ләр кушымчасы ялгадыгыз?<br>Бу сүзне әйтеп карыйк әле. Сүзнең ахыры ничек әйтелә? (калын) Шуңа күрә -лар языла.<br>– Нинди кисәкләр безгә исемнәрнең күплек санын ясарга ярдәм итте?<br>–Калын сүзләргә нинди кисәкләр ялганды?<br>– Нечкә сүзләргә нинди кисәкләрялганды?<br>– Бу сүз кисәкләрен без кушымчалар дип атыйбыз.<br>ФИЗКУЛЬТМИНУТКА<br>V.Белемне беренчел ныгыту.<br>– Урманда кошлар да яши бит. Алар белән дә танышыйк.<br>– Мин кошларны күрсәтәм, сез сүзлек дәфтәренә исемнәрен языгыз.<br>– Кошларны күплек санда әйтегез. Башта төркемдә эшлисез. Аннан җавап бирәсез. | Шәхси (әхлакый) универсаль уку гамәлләре<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Танып белү универсаль уку гамәлләре<br>Проблемалар кую, эзләнү<br><br><br><br><br><br><br><br><br>Коммуникатив универсаль уку гамәлләре |

| | |
|---|---|
| VI.Үрнәк буенча мөстәкыйль эш башкару.<br>– Хәзер агачларның хәлләрен белик. Кыш көне ап-ак юрган ябынып агачлар да йоклый .<br>– Мин сезгә җәйге агачларны күрсәтәм. Игътибар белән карагыз, русча исемнәрен әйтегез.<br>– Кыш көне алар бит яфраксыз. Танырсызмы икән аларны?<br>– Сары конвертларны алыгыз әле.<br>– Анда агач исемнәре язылган карточкалар бар.<br>– Экранда тәрҗемәләре бирелгән.<br>– Мин агачның рәсемен күрсәтәм кайсы төркемдә шул сүз бар, төркемнән бер укучы чыгып, тактага татарча исемнәренябыштыра. Күплек санга куеп языгыз. | |
| (Укучылар дәфтәрләрен алыштырып, бер-берсенең эшен тикшерәләр).<br>-нар, -нәр кушымчалары нинди исемнәргә ялганды? –Нинди нәтиҗә ясыйбыз?<br>-нар, -нәр кушымчалары н авазына беткән сүзләргә ялганды. | Шәхси (әхлакый) универсаль уку гамәлләре |
| VII. Өйрәнелгән материалны кабатлау этабы.<br>- Өйрәнелгән сүзләрне кулланып Кышкы урман турында телдән хикәя төзибез. Сорауларга җавапны башта төркемнәрдә әзерлисез.<br>– Кышкы урман нинди?<br>– Урман һавасы нинди? | Танып белү универсаль уку гамәлләре |

| | |
|---|---|
| – Анда нинди агачлар үсә?<br>– Урманда нинди җәнлекләр яши?<br>– Нинди җәнлекләр кышкы йокыда?<br>– Урманда нинди кошларны очратабыз?<br>– Аларга урманда азык җитәрлекме?<br>– Азык эзләп алар кая киләләр?<br>VIII. Рефлексия, бәяләү этабы.<br>– Экранга карап нәрсәләр әйтә алабыз? | |
| – Исемнең күплек сан формасы нинди кушымчалар ярдәмендә ясала?<br>– Калын сүзләргә нинди кушымчалар ялгана? | Танып белү универсаль уку гамәлләре |
| – Нечкә сүзләргә нинди кушымчалар ялгана? -нар ,- нәр кушымчалары нинди авазларга беткән сүзләргә ялгана?<br>– Бу кушымчалар белән без икенче дәрестә дә эшне дәвам итәрбез. Дәресебез ахырына якынлаша. Сезнең өчен дәрестә иң кызыклысы нәрсә булды?Нинди яңалыклар белдегез?Дәрес барышында алган смайликларга карап үзегезгә үзегез билге куегыз (Укучылар куелган билгеләрен аңлаталар)<br>IX. Өй эше. | Шәхси (әхлакый) универсаль уку гамәлләре |
| – Кызыл конвертларда сораулар язылган карточкалар бар. Шул карточкаларга нигезләнеп, кышкы урман турында хикәя төзергә кирәк. Кемнәр язмача эшләргә тели, алар кызыл карточкалар ала. Телдән хикәя төзергә теләүчеләр зәңгәр карточка ала. Дәрес өчен рәхмәт. Сау булыгыз! | Регулятив универсаль уку гамәлләре |

## ТЕМА: Р. ВАЛИЕВАНЫҢ «ТУГАН КӨНДӘ» ХИКӘЯСЕН ӨЙРӘНҮ (3 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**Э.Җ. Газизова, Яр Чаллы**

**Дәреснең тибы:** Яңа белемнәрне ачу.

**Максат:** 1. Әдәби әсәргә анализ ясау, әсәрнең идеясен билгеләргә өйрәтү. 2. Тикшеренү, эзләнү, иҗади фикерләү күнекмәләрен үстерү. 3. Мәрхәмәтлелек, ихтирамлылык, кешелеклелек, сыйфатлары тәрбияләү.  4. Укучыларда универсаль уку гамәлләрен формалаштыру.

**Җиһазлау:** Рәсемнәр, балалар язган иншалар, Р. Валиеваның шигырь китапларыннан күргәзмә, компьютерда презентация, балаларның проект эшләре.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру этабы.**

Сыйныфта уңай психологик халәт тудыру.Укучыларны барлау.

– Исәнмесез, укучылар! Хәерле көннәр сезгә. Зиһен һәм тел ачкычлары телимен һәммәгезгә!

**II. Актуальләштерү.**

Укытучы. Бүгенге дәрестәге әсәрнең исемен ачыкларга Рамиль булышачак. Хәзер аның проект эшен карап үтәбез.

(Рамилнең презентациясе)

Рамил: Бу нинди бәйрәм?

Балалар: Туган көн. Димәк, без дәрестә нәрсә турында сөйләшәбез!

Укытучы: Бүгенге әсәрнең исеме «Туган көндә». Бу хикәянең авторы Резедә Вәлиева. Аның турында безгә Рената сөйли. *(Рената презентациясе)*

*Үзбәя.*

**III.Уку мәсьәләсен кую.**

Теманы ачыклыйлар, максатларны укыйлар.

| |
|---|
| 1.Презентация. Балалар чыгышы.<br>2.Текст өстендә эшләү.<br>3.Сүзлек эше.<br>4.Сорауларга җавап бирү.<br>5.Геройларга характеристика бирү.<br>6.Проект эшләре. Укучылар чыгышы. |

**IV. Уку мәсьәләсен чишү. Текст өстендә эш.**

1. Текстны уку (*әсәрне яхшы укый торган укучы укып чыга*).

2. Сүзлек эше.

Сый-хөрмәт – тәмле ризыклар

Искиткеч – гаҗәеп, (удивительно)

Аңышмыйчарак – аңламыйча

Хәлсезләнеп – хәл бетеп (остаться без сил)

Кемнең сый-хөрмәте? Әбинең сый-хөрмәтен ашадык.

Искиткеч нәрсә?

3. Сорауларга җавап бирү.

– Әсәрдә кемнәр катнаша? (Әнисе, Фәридә, Фәридәнең әнисе, әбисе, автор)

– Фәридәнең туган көне турында ничек белдек?

– Катнашучылар арасында кем бар? (автор)

– Фәридәнең туган көненә әнисе нәрсәләр пешергән?

– Матур күлмәкне кем теккән?

– Чәчәкләрне кем алып кайткан?

– Фәридәнең әнисен нинди?

*(Тактага Фәридәнең әнисенә хас сыйфатлар язылган карточкаларны тезеп чыгалар).*

*Фәридәнең әнисе.* Эшчән, тырыш, кешелекле, сабыр, мәрхәмәтле, өлкәннәрне хөрмәт итә, игътибарлы, уңган, тәрбияле.

– Аны кем тәрбияләп үстергән?

– Фәридә әнисенә нәрсә әйтә?

– Әнисе нишли?

– Ул ни өчен шулай үзгәргән?

Фәридәнең әнисе кызының сүзләре белән килешәме?

– Ул уңган, игътибарлы, тагын нинди?

– Ул кемне ярата?

*Үзбәя.*

4. Рәсем буенча эш.

– Рәсемне карагыз. Фәридә нинди?

– Фәридәнең әбисе нинди?

– Фәридә гел шулай матур булып торырмы?

– Фәридәнең әбисе элек нинди нинди булган?

– Фәридәгә нинди киңәш бирерсез?

– Әсәрне ничә өлешкә бүлеп була? (ике)

– Беренче өлештә өйдәгеләрнең кәефе нинди?(күңелле)

– Икенче өлештә кәефләр ничек үзгәрә? (борчылу)

– Ни өчен?

Шатлык ----- борчылу

– Бу каршылык Фәридә әбисенең тышкы матурлыгын гына күрү аркасында килеп чыга. Димәк автор нәрсә әйтергә тели? *(Кешенең тышкы матурлыгына гына түгел, эшке матурлыкны күрә белергә кирәк)*

*2 слайд.*

– Укучылар, Фәридә хәзер матур булып күренәме?

– Ни өчен?

7) Сезнең барыгызның да әбиләре бар. Сез аларны яратасызмы?

– Әбиләрегез турында нинди җылы сүзләр әйтерсез? Хәзер сезнең проект эшләре белән танашып китик.

Айнур әбисе турында шигырь чыгарган.

Алия әбисе турында презентация ясаган.

Эльвина газета чыгарган.

Юля әбисенең портретын ясаган.

Гөльназ әбисенең нинди тәмле ашлар пешергәне турында сөйләп китәр.

Мансур әбисе турында сочинение язган.

Румиль әбиләр турында шигырьләр җыентыгы ясаган.

Регина әбисенең кул эшләренең күргәзмәсен оештырган.

– Сезнең әбиләрегезне яратуыгыз, аларга игътибарыгыз, хөрмәтегез чиксез булуы мине сөендерә.

Үзбәя.

**IV. Йомгаклау-рефлексия.** Нәтиҗәләр чыгару, слайдтагы мәкальләрне уку, үтелгән материалга йомгак ясау.

**V. Өй эше бирү.** Хикәяне дәвам итеп язарга.

# ТЕМА: ТИҢДӘШ КИСӘКЛӘР ЯНЫНДА ГОМУМИЛӘШТЕРҮЧЕ СҮЗЛӘР,АЛАР ЯНЫНДА ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕ (8 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**М.Г. Талипов, Казан**

**Дәрес тибы**: Яңа белем, күнекмәләр булдыру.

**Предметара бәйләнешләр**: Әдәби уку, рус теле, рәсем сәнгате.

**Җиһазлау:** Мультимедиа проекторы, Р.Ә. Асылгәрәева, Р.А. Юсупов, М.К. Зиннуров: Татар теле дәреслеге.

**Максат**:

1.Тиңдәш кисәкләр янынында гомумиләштерүче сүзләр килгәндә, аларның нинди җөмлә кисәге булып килүен ачыклау.

Укучыларда, тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр килгәндә, тыныш билгеләрен дөрес куя белү күнекмәләре булдыру.

2. Укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерүгә шартлар тудыру.

3. Аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру.

4. Укучыларда милли үзаң,толерантлык тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Предмет буенча:*

– гомумиләштерүче сүзләрнең нинди сүз төркеме белән белдерелүен ачыклау;

– тиңдәш кисәкләргә, гомумиләштерүче сүзләргә сораулар куя белү;
– гомумиләштерүче сүзләрнең тиңдәш кисәкләрдән алда яки алардан соң килүләренә карап, тыныш билгеләрен дөрес кую күнекмәләре булдыру;
– текст белән эшли белү.

**Метапредмет:**

*Регулятив:*

– уку мәсьәләсен кабул итү һәм дәрес дәвамында шуның буенча эшләү;
– куелган мәсьәлә нигезендә үз эшчәнлегеңне планлаштыру.

*Танып белү:*

– куелган мәсьәләне чишүдә алгоритмны куллана белү;
– язма һәм телдән сөйләмдә үз фикерләреңне формалаштыра белү;
– өлешләрдән бербөтенне төзи белү;
– гомумиләштерү.

*Коммуникатив:*

– сөйләмнең диалогик, монологик формалары белән эш итә белү;
– үз карашыңны, фикереңне формалаштыру;
– бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килә белү;
– иптәшеңнең җавабын тыңлый белү;
– үз карашыңны яклаганда, төпле дәлилләр китерә белү.

**Дәрес барышы**

*Оештыру моменты* (3 мин.)

Укытучы: Хәерле көн, укучылар!

Дәрес башыда әйдәгез

Кулларны языйк әле.
Аяклар да оешмасын,
Чүгәләп алыйк әле
Бер – бербезгә матур итеп,
Елмаеп карыйк әле!

**1. Белемнәрне актуальләштерү** (10 мин.)

*1нче слайдта текст бирелә*

1) Мин – татар баласы. (2) Мин татар дигән исемене беркемнән дә курыкмыйча һәм оялмыйча әйтәм.(3) Теләсә кем алдында әйтәм.(4)Татар булганым өчен кемдер мине читкә кагарга җыенса да, әйтәм. (5) Татарлыгымнан ваз кичүем өчен кемдер алтын таулар вәгъдә итсә дә, Алла боерса, ваз кичмәмен.(6)Бүтән милләт кешесе дә үзенең шул милләт баласы булуы белән горурлана икән, аны аңлыйм. (7) Аның моңа хакы бар. (8) Әгәр үз милләтеннән ваз кичеп, рус яки татар булып булып уйнарга тели икән, мин андый кешедән ераграк торырга тырышам. (9) Ике арада буталган, ягъни мәсәлән, ике сыерны имәргә җыенган бозауларны җенем сөйми. (10) Мин дөньядагы бер генә милләткә дә, бер генә халыкка да кимсетеп карамыйм. (11) Бөек халыклар һәм түбән сортлы халыклар юк дип һәрвакыт тәкрарлыйм (кабатлыйм).[...] (12) Шәхсән минем өчен халыкларның барсы да: яһүде дә, татары да, урысы да бертигез, берәүләрен күккә чөймим, икенчеләрен хурлап пычратмыйм.

Туфан Миңнуллин «Утырып уйлар уйладым». (Рәсеме күрсәтелә, аның турында кыскача мәгълүмат алына)

Укытучы: 1 Укучылар бу текстан дәфтәрләрегезгә тиңдәш кисәкле җөмләләрне язып алыгыз әле. Тиңдәш кисәкләрнең астына сызыгыз, схемаларын төзегез.

2. Укучылар, үз милләтен, үз туган телен яратучы кеше начар була аламы?

Ә нинди шартларда андый кеше начар була ала? (11 нче җөмләгә үз мөнәсәбәтегезне белдерегез.

**2. Яңа белемнәрне ачу** (14 мин.)

Укытучы: язып алынган җөмләләрдә ни өчен куелганын сез белми торган берәр тыныш билгесе бармы?

Төркемнәрдә киңәшкәннән соң, укучылардан берәү 12 нче җөмләдәге ике ноктаны әйтә.

Укытучы. Бик дөрес, укучылар. Без бүгенге дәрестә «Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре» дигән теманы өйрәнәчәкбез. Сез инде, бәлки, рус теле дәресләрендә бу теманы өйрәнгәнсездер дә. Әйдәгез, башта «гомумиләштерүче сүз» нең татарчага тәрҗемәсен ачыклыйк әле.

Җавап. Обобщающее слово.

Хәзер экранга карыйбыз. Анда сезнең күбегез өчен ана теле булып исәпләнгән рус телендә бер җөмлә бирелгән.

На картинах И.Левитана изображены знакомые с детства вещи: стога сена, почернелые от сырости; маленькие реки, кружащие в маленьких водоворотах палую листву; одинокие золотые берёзы: небо, похожее на тонкий лёд.

Укучылар төркемнәрдә эшләп әлге җөмләдәге тиңдәш кисәкләрне (однородные члены),гомумиләштерүче сүзне (рус теле дәресендә үтелмәгән булса, укытучы ярдәме белән) табалар.

Укучыларның игътибары янәдән экрандагы икенче җөмләгә юнәлдерелә.

Женя да, Таня да, Ләйлә дә (Оля Санфирова, татар кызы, Советлар Союзы Герое) юк – барысы да мәңгелек йокыда. Полкташларның шактые – таңда ачылган чәчкә кебек чибәр кызлар: Женя Руднева, Галя Докутович, Лена

Салихова сөясе-сөеләсе чакта очкычларында тереләй янып үлделәр.

Укытучы тарафыннан Әлеге төрле милләт кызларының Советлар Союзы Герое Мәгубә Сыртланованың сугышчан дуслары икәне әйтелә, экранда рәсеме күрсәтелә. Ләбибә Ихсанованың 6 нчы сыйныфта үтелгән «Лачын кыз» әсәре искә төшерелә.Барлык милләт вәкилләренең дә уртак Ватанны саклауга бердәй өлеш керткәннәренә басым ясала.

Укучылар, калын хәреф белән бирелгән сүз нинди сүз төркеме булыр?

Көтелгән җавап. Билгеләү алмашлыгы.

Укытучы.нинди билгеләү алмашлыкларын беләсез?

Төркемнәрдә киңәшкәннән соң, бер укучы җавап бирә. Алар күп түгел: һәр,бар, бөтен, һәммә ,үз.

Әйдәгез, хәзер бу җөмләдән тиңдәш кисәкләрне табыйк.

Укытучы. Женя да, Таня да, Ләйлә дә дигән тиңдәш кисәкләрне кайсы сүз гомумиләштереп килә?

Көтелгән җавап. Барсы да сүзе.

Укытучы. Димәк, укучылар, барсы да сүзе бу җөмләдә нинди сүз була?

Көтелгән җавап. Гомумиләштерүче сүз

Укытучы. Димәк, күп очракта нинди сүз төркемнәре гомумиләштерүче сүз булып килә икән?

Көтелгән җавап. Билгеләү алмашлыклары. 2нче җөмләгә синтаксик анализ ясала һәм гомумиләштерүче сүзләрнең дә, тиңдәш кисәкләрнең дә берүк җөмлә кисәге икәне әйтелә, тыныш билгеләренең куелышы аңлатыла,Бирелгән җөмләләрнең кайсы схемага туры килгәнен укучылар үзләре билгелиләр.

[ Г:Т,Т,Т]; [ Г: Т, Т, Т – Г]; [ Т, Т, Т – Г]

Экранда 2нче җөмләнең үзгәртелгән варианты күрсәтелә.

Таңда ачылган чәчкә кебек чибәр кызлар […] Женя Руднева, Галя Докутович, Лена Салихова […] очкычларында терелә́й янып үлделәр.

Сорау. […] урынына нинди тыныш билгесе куяр идегез һәм ни өчен?

**3. Үтелгән материалны беренчел ныгыту.**

Дәреслектән 235 нче күнегүне эшләү. (7 мин)

Аны анализлау: Тиңдәш кисәкләрне һәм гомумиләштерүче сүзләрне табу, тыныш билгеләренең куелышын аңлата белү.

Бәяләү критерийлары:

«5» – биремне үти алдым, барлык тыныш билгеләрен дә дөрес куйдым.

«4» – бер – ике урында гомумиләштерүче сүзне дөрес таба яки тыныш билгесен дөрес куя белмәдем.

«3» – биремне иптәшем ярдәмендә генә үти алдым.

**4. Төркемнәрдә эш һәм эталон буена үзтикшерү.**

(5 минут)

Укытучы. Хәзер шактый катлаулы эш төрен тәкъдим итәм. Һәр төркемгә икешәр схема бирелә, шулар буенча җөмләләр төзәргә кирәк булачак. ( 5 минут)

Экранда Левитанның «Алтын көз» картинасы күрсәтелә, җөмләләрне шушы картина эчтәлеге буенча төзергә киңәш ителә.

Укытучы.Укучылар, сез бу рәсемдә нинди төсләр күрәсез?

Укучылар җавабы. Зәңгәр, сары, кызгылт, һ.б. төсләр санала һәм рәссамнең ул төсләрне табигатьтән алганлыгы әйтелә.

– Табигатьтә бар нәрсә дә бер генә төрле төстән генә торса камил булыр идеме, әллә ул шушы хәлендә матурмы?

Нәтиҗә: димәк, табигать бар әйберне дә : хайваннарны да, үсемлкләрне дә төрледән – төрле, хәтта халыкларны да аерым-аерым милләтләр итеп яраткан. Әгәр кем дә булса бу балансны бозарга уйлый икән, ул бөтен табигатькә , кешелек дөньясына зыян салучы буларак тарихта калачак.

Үзбәя кую өчен критерий:

«5» – схема буенча җөмләләрне дөрес төзи алдым, җөмләләрем картина эчтәлегенә туры килә.

«4» – җөмләләрне картина эчтәлегенә туры китереп төзедем, ләкин 1 – 2 стиль хатасы бар.

«3» – биремне иптәшләрем ярдәмендә генә үти алдым.

**5. Эшчәнлеккә рефлексия.** (3 минут)

Укытучы. Укучылар, без бүгенге дәрестә нинди проблемааны чиштек?

Көтелгән җавап. Тәңдәш кисәкләр янындагы гомумиләштерүче сүзләрне дөрес табарга һәм алар янындагы тыныш билгеләрен дөрес куягарга өйрәндек

Укытучы. Алмашлыклардан башка сүз төркеме гомумиләштерүче сүз була аламы?

Көтелгән җавап: Җыю мәгънәсен белдергән исемнәр гомумиләштерүче сүз урынына кулланыла ала,әмма аларны – аныкланмыш, тиңдәш кисәкләрне тиңдәш аныклагычлар итеп карыйлар.

**6. Дәрескә йомгак ясау.** (2 минут)

Өйгә эш бирү. (1минут) 1. 236 нчы күнегүне эшләргә – татар телен камил белмәгән укучылар өчен.

2. Татар әдәбияты дәреслеге тышлыгындагы М. Хәертдиновның «Шомырт исе килә, кызлар» картинасы буенча кыска хикәя язарга. Тиңдәш кисәкләр **янында гомуми**ләштерүче сүзләре булган җөмләләр кулланырга.

# ТЕМА: КИСӘКЧӘЛӘРНЕҢ ТӨРКЕМЧӘЛӘРЕ (6 НЧЫ СЫЙНЫФ)

**Шәйхетдинова Г.З., Яр Чаллы**

**Дәреснең тибы:** Яңа теманы аңлату.

**Максатлары:**

1. Белем бирү максаты: кисәкчәләрнең төркемчәләре турында белем бирү.

2. Үстерү максаты: кисәкчәләрнең төркемчәләрен аера белү, сөйләмдә дөрес куллану күнекмәләрен үстерү; сәнгатьле уку күнекмәләрен, дөрес язу күнекмәләрен камилләштерү; логик фикерләү сәләтен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

3.Тәрбия бирү максаты: эстетик тәрбия бирү; акыл тәрбиясе бирү.

**Җиһазлау:** «Кисәкчәләрнең төркемчәләре» дигән таблица. Л.Ә. Фаттаховның «Таң атып килә» картинасы. «Кисәкчәләрнең төркемчәләре». Презентация.Татар урта гомуми белем мәктәбе 6 нчы сыйныф өчен дәреслек. Д.Г. Тумашева, Ф.Ю.Юсупов, К.З. Зиннәтуллина редакциясендә. Казан: Мәгариф, 2001.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше.**

Исәнләш.

Укучыларны тәртипкә чакыру.

Дәреснең максатын әйтү.

Без бүген кисәкчәләрнең төркемчәләре турында белем тупларбыз.

**II. Өй эше тикшерү.**

Иншаны уку.

– Ә хәзер өй эшен тикшерәбез. Сез кисәкчәләр кулланып «Сыерчыклар да кайттылар» темасына инша язырга тиеш идегез. Әйдәгез, иншаларны укып китик.

1 укучы: Менә тагын яз җитте. Кышкы озын төннәрдән соң, каты салкыннардан, ачы бураннардан соң тагын яз килде. Кошлар да җылы яктан кайттылар. Иң беренче булып каргалар, аннары сыерчыклар да кайттылар. Без сыерчыкларга оя ясарга булдык. Ул ояны түбә башына куйдык. Икенче көнне карасак, ул ояга ике сыерчык килгән иде. Алар чут – чут итеп сайрылар иде. Сыерчыклар шул ояда яши башладылар. Балалар чыгардылар. Соңыннан балаларын очарга өйрәттеләр. Ләкин алар озак тормадылар, урманга очып киттеләр.

2 укучы: Яз көне табигать, күзгә каршында боргаланучы гүзәл кыз кебек тоела. Ә күзге − зәңгәр күкләр, алар буенча йөзеп йөргән ак мамык болытлар.

Мин дә ел фасылларыннан бигрәк тә язны яратам шул. Чәчәкләр исен, агачларның бүрткән бөре исләрен яратам, җылы язгы күлдәвекләрне, чыпчыклар һәм песнәкләрнең күңелле чыркылдавын яратам. Кояш яктырак һәм җылырак карауга, алар үзләренең шат чыркылдаулары белән шатлыкларын сиздерә башлыйлар. Күгәрченнәр, кояшка чыгып утырып, кабарынып гөрләшәләр. Йорт кошлары да калышмыйлар. Алар ачык капкалардан чыгып, кояшта кызыналар, саран гына тамган тамчылардан авыз итәләр. Казлар да үзләренчә шатланалар, аларның тавышлары көр чыга. Шулай булмыйча соң, тиздән бит нәсел калдыру буенча зур эш башланачак.

Яз көне җылы якларда кышлаучы кошлар да очып кайта һәм оя кора башлыйлар. Ә сыерчыкларга җиңелрәк, чөнки аларга йортларны кешеләр алдан әзерләп куялар.

Шуңа күрә сыерчыклар үзләренең ояларын җыештыралар да шунда ук эшкә тотыналар: басу-кырларны кышкы йокыларыннан уянган корткычлардан чистарталар. Каргалар да эшли, гәрчә кешеләр аларга оялар ясап бирмәсәләр дә.

Болар табигатьтәге үзгәрешләр, бу – табигатьнең уяну вакыты, аның кышкы йокыдан уяну вакыты, иртәсе.

– Яхшы, укучылар.

**III. Белемнәрне актуальләштерү.**

1. Кисәкчәләр турында сорауларга җавап бирү.

– Ә хәзер без кисәкчәләр турында сорауларга җавап бирербез.

Укучылар, үткән дәрестә сез нинди яңа сүз төркеме белән танышкан идегез әле?

Укучы: Кисәкчәләр белән танышкан идек.

– Нинди сүз төркеме кисәкчә дип атала?

Укучы: Аерым сүзнең яки җөмләнең мәгънәләренә өстәмә төсмер бирә торган сүз төркеме кисәкчә дип атала.

– Сез нинди кисәкчәләр беләсез?

1 укучы: гына, генә, кына, кенә.

2 укучы: да, дә, та, тә.

3 укучы: ук, үк

4 укучы: иң, чалт,ямь,зәп

– Кисәкчәләрне җөмләдә ни өчен кулланалар?

Укучы: Чөнки алар җөмләгә мәгънә төсмере бирәләр.

– Яхшы, укучылар.

2.348 нче күнегүне эшләү.

– Ә хәзер без телдән 348 нче күнегүне эшләрбез. Сез текстны укырга,аңа исем куерга тиеш . Кисәкчәләрне табып, аларның кайсы сүзләргә нинди мәгънә төсмере өстәүләрен ачыкларга тиеш.

Укучы: Бүген Мусаны шунда алып китте Алиш. Аларга Фоат та иярде. Яз иде, мартның унбишләре булса да,

бездәге апрель урталары диярлек, кояшлы җылы көн иде. Агач бөреләре тәмам бүртеп, кып-кызыл ялтыравык, нәфис тырнаклары ачылып китәргә җыена иде. Аккүл буендагы тирәкләрдә сыерчыкларның шулчаклы дәрт белән ярсынып һәм өзеп-өзеп сайраулары күңелләрне әллә кайларга, язның шул беренче җырчыларына оя ясап йөргән малай чакларга алып китә иде. Әмма шуның белән бергә, аларның монда — немец җирендә сайравы барыннан да гаҗәбрәк һәм сәеррәк тоела иде. Чөнки сыерчыклар фәкать безнең илдә генә, безнең өй артында гына сайрый торган үз кош булып сабый чактан ук күңелгә сеңеп калган кадерле бер төшенчә иде. Шулай да аларның дәртсенеп сайравы чит-ят җирләрдә дә барыбер матур, барыбер сокландыргыч булганлыктан, күл буена килгән егетләр, байтак вакыт аларны тыңлап, сагыну хисләрендә онытылып утырдылар. (Ш. Маннур)

– Сез бу текстка нинди исем куяр идегез?

Укучы: Яз иде...

– Яхшы, укучылар.

**IV. Яңа белемнәрне аңлату һәм үзләштерү.**

Уен «Кем күбрәк?»

Ә хәзер без уен уйнап алырбыз. Уен « Кем күбрәк?» дип атала. Сез бирелгән хәрефләрдән кисәкчәләр төзергә тиеш.

*1 укучы:* Иң, чалт, гына, генә.

*2 укучы:* Мы, ме, да, дә, бит.

*3 укучы:* үк, һич, түгел, дыр, дер.

*4 укучы:* ла,лә, әллә, чы,че.

Яхшы, укучылар. Кисәкчәләрне ни өчен җөмләдә кулланалар соң?

*Укучы:* Чөнки алар җөмләгә нинди дә булса мәгънә төсмере өстиләр.

– Әйе, дөрес.

«Кисәкчәләрнең төркемчәләре» дигән таблица белән эшләү.

– Җөмләгә нинди мәгънә төсмере бирүләреннән чыгып кисәкчәләрне 8 төркемчәгә бүләләр. Кисәкчәләрнең төркемчәләре таблицада күрсәтелгән. Әйдәгез, таблицаны карыйк. Беренче төркемчәнең исеме көчәйткечләр дип атала. Аңа Иң, чалт, чатнама, дөм, нәкъ, шыр, өр, хәтта, соң, ямь-, нәкъ, – сап кебек кисәкчәләр керә. Мәсәлән: Чалт аяз көн. Ямь- яшел яфрак. Караңгы, хәтта юлны күреп булмый. Монда чалт һәм – ямь кисәкчәләр кулланылган. Икенче төркемчәнең исеме чикләүчеләр дип атала. Аңа Гына, генә, кына, кенә кебек кисәкчәләр керә. Мәсәлән: Бу юлы китап кына алырбыз. Монда кына дигән кисәкчә кулланылган. Өченче төркемчәнең исеме сорауны белдерүчеләр дип атала. Аңа -мы, -ме, - мыни, -мени кебек кисәкчәләр керә. Мәсәлән: Илгиз киттемени? Дүртенче төркемнең исеме якынлык-ераклык яки тизлекне белдерүчеләр дип атала. Аңа да, дә, та, тә, ук, үк кебек кисәкчәләр керә. Мәсәлән: Күргәч тә әйт, хәзер үк килсен. Монда тә дигән кисәкчә кулланылган. Бишенче төркемчәнең исеме раслаучы, ныгытучылар дип атала. Аңа Бит, ич, ла, лә, лабаса, ләбаса кебек кисәкчәләр керә. Мәсәлән: Илдус *бит*. Үзем күрдем *ләбаса*. Бу мисалда бит һәм ләбаса кебек кисәкчәләр кулланылган. Алтынчы төркемчәнең исеме билгесезлек,икеләнүне белдерүчеләр дип атала. Аңа әллә, -дыр,-дер, -тыр,-тер кебек кисәкчәләр керә. Мәсәлән: Гәрәйдер. Бу аның эшедер. Монда дер дигән кисәкчә кулланылган. Җиденче төркемчәнең исеме үтенү, теләкне белдерүчеләр дип атала. Бу төркемчәгә -чы, -че, -сана, -сәнә, әле, инде кебек кисәкчәләр керә. Мәсәлән: Я, акыллым, кил инде. Әйтче миңа дөресен. Бу мисалда инде һәм -че кебек кисәкчәләр кулланылган. Сигезенче

төркемчәнең исеме инкаръ итүне, юклыкны белдерүчеләр дип атала. Аңа һич, түгел кебек кисәкчәләр керә. Мәсәлән: Һич оныта алмыйм, онытырга мөмкин түгел. Бу мисалда һич һәм түгел кебек кисәкчәләр кулланылган.

3. Дәреслектәге кисәкчәләрнең төркемчәләре турында кагыйдәләр уку. Нәтиҗә ясау.

– Хәзер, укучылар, дәреслектән кагыйдәне укыйк.

*Укучы:* Кайбер кисәкчәләр берничә төрле мәгънә төсмере белдерә. Мәсәлән, да, дә, та, тә кисәкчәләре:

1. Тизлек төсмере өстиләр: *Нәфисә басудан кайтып ял итәргә* дә *өлгермәде, күңеле аны тагын иптәшләре янына тарта башлады. (Г. Бәширов)*

2. Көчәйтү төсмерен белдерәләр: *Газинур үз гомерендә шактый күп җырлар җырлаган, ишеткән кеше, әмма разведчиклар шикелле йөрәкләрне айкап, үзәкләрне өздереп җырлаганны моңарчы күргәне* дә, *ишеткәне* дә *юк иде. (Г. Әпсәләмов)*

3. Бергәлекне, ягъни аннан башка өстәмә предмет булуын төсмерләтә: *Аның язу өстәлендә куен дәфтәре* дә *ята иде. (М. Әмир)*

4. Шарт фигыль белән килеп, кире шарт мәгънәсен белдерә: *Соңга калса* да, *үкенмәде Таҗи. (Г. Гобәй)*

5. Бер үк вакытта кисәкчә һәм теркәгеч хезмәтен үти: *Егет килде* дә *китте. (Егет килде һәм китте. – Егет килде һәм озак тормыйча китте.)*

1. Аерым сүзнең мәгънәсенә ук, үк кисәкчәләре тизлек, якын-ераклык төсмере өстиләр.

2. Фигыльләр белән килеп, **әле** һәм **инде** кисәкчәләре я белдерелгән боеру мәгънәсен бераз йомшартып үтенүне, яки вакыт төсмерен, яисә ризасызлык һәм раслау кебек уйхисләрне белдерәләр.

– Укучылар, нинди кисәкчәләрнең берничә мәгънә төсмере бар?

*Укучы:* да, дә,та,тә.

Аларны санап чыгыгыз.

*Укучы:* Алар тизлек төсмере өстиләр, көчәйтү төсмерен белдерәләр, бергәлекне, ягъни аннан башка өстәмә предмет булуын төсмерләтә, шарт фигыль белән килеп, кире шарт мәгънәсен белдерә, бер үк вакытта кисәкчә һәм теркәгеч хезмәтен үтиләр.

Укучылар, ук һәм үк, әле һәм инде кисәкчәләре нинди мәгънә төсмере белдерәләр?

*Укучы:* Аерым сүзнең мәгънәсенә ук, үк кисәкчәләре тизлек, якын-ераклык төсмере өстиләр. **Әле** һәм **инде** кисәкчәләре я белдерелгән боеру мәгънәсен бераз йомшартып үтенүне, яки вакыт төсмерен, яисә ризасызлык һәм раслау кебек уй-хисләрне белдерәләр.

Яхшы, укучылар.

**V. Яңа теманы ныгыту.**

1. Дәреслектәге күнегүне эшләү (351 нче күнегү)

– Ә хәзер, укучылар, 351 нче күнегүне язмача эшлибез. Әйдәгез, биремне укып китик.

*1 укучы:* Укыгыз, кисәкчәләрне табыгыз, аларның нинди төркемчәгә каравын ачыклагыз.

*2 укучы:*1. Бөтен тирә-як тып-тын (көчәйткеч)Ярдагы учаклар да сүнгән. (якынлык-ераклык яки тизлекне белдерүче)Әле генә яр буе шау-гөр (көчәйткеч) килеп тора иде бит ләбаса.(раслаучы,ныгытучы) *(Г.Гобәй)* 2. Ул аны һич(инкарь итүне, юклыкны белдерә)кенә(чикләүче) дә (якынлык-ераклык яки тизлекне белдерә)исенә төшерә алмады. Кайдадыр күргән иде бит(раслаучы)ул аны. *(М. Әмир)* 3. Ул европача киенгән, үзе дә әйтеп бетергесез чибәр: кап-

кара (көчәйткеч) янып торган күзләр, сызылып киткән кара мыек....Бер секунд эчендә аның башыннан төрле уйлар узды. Иелеп, идәндә яткан кып-кызыл (көчәйткеч) йомшак чәчәкне кулына алды. *(А. Расих)*

4. Иң (көчәйткеч) якын дустың икән ул —
Фронтта булган кешең.
Үз итеп аңа сөйлисең
Хәтта син күргән төшең. *(С. Хәким)*

5. Аның каршысына килеп чыккан бу егет моңа кадәр белгән кеше түгел иде. Аның килеш-килбәте, үз-үзен тотуы да(якынлык-ераклык яки тизлекне белдерә) бистә егетләренеке кебек түгел, бөтенләй башка иде. *(К. Нәҗми)*

2.Кисәкчәләрнең төрле төркемчәләрен кулланып «Таң атып килә» дигән темага кечкенә хикәя язу.

Бик яхшы, укучылар. Ә хәзер кисәкчәләрнең төрле төркемчәләрен кулланып «Таң атып килә» дигән темага хикәя язарбыз.

*Укучы*: Таң ата... Бу – табигатьнең иң могҗизалы, иң серле, иң гүзәл вакыты.

...Әнә бар дөнья әкияттәгедәй сихри тынлыкка чумган, шылт иткән тавыш та юк. Күктәге берәм-сәрәм йолдызлар әкрен генә төссезләнәләр. Көнчыгыш ягы алсулана, аннан, агара төшеп, таң сызыклары беленә башлый. Тып-тын. Якында гына аккан чишмә тавышы табигатьнең тынлыгын матурлап тора. Кояш та, тын гына үрелеп, җиргә күз сала. Аның нурлары, үлән өстендәге чыкның күзләрен чагылдыра. Сандугач сайравы иртәнге тынлыкны җанландырып җибәрә.

Урман артыннан күтәрелгән кояшның алсу йөзе ашыкмый гына җир өстенә күз сала: «Мин юкта ул-бу булмаганмы, барысы да исән-саулармы?». Шуны гына көткәндәй, таллыкта сандугач сайрап җибәрә; әрәмәлектә күке аваз

сала; салкынча шаян җил агачларны, үләннәрне, битләрне сыйпап үтә; чыклы чирәм, кычыткан исе борыннарны кытыклый; кайдадыр кайтмый калган сарык бәтие тавыш бирә; абзарларда иренеп кенә сыерлар мөгрәп куя; йокы аралаш казлар каңгылдап ала. Ара-тирә капка ачылган-ябылган тавышлар ишетелгәли. Хуҗабикәләр торып, сыер саварга керешәләр. Тирә-якка җылы сөт исе тарала...

Ул арада кояш тагы да югарырак күтәрелә, серле тынлык юкка чыга, җирдә яңа көн башлана.

Бик яхшы!

*3. Әле* һәм *инде* кичәкчәләренең җөмләгә нинди мәгънә белдерүен ачыклау (354 нче күнегү)

Ә хәзер без 354 нче күнегүне телдән эшләрбез. Биремне укып китик әле.

*1 укучы:* Укыгыз, күчереп языгыз, ***әле*** һәм ***инде*** кисәкчәләренең астына сызыгыз. Аларның нинди төсмерләр белдерүен бергәләп ачыклагыз.

*2 укучы:1.* Урман бабай, дусларымны

Син дә саклый күр инде. (йомшартып үтенүне белдерә)

Син үзең дә,Энәбикә,

Зинһар, саграк йөр инде. (үтенүне белдерә) *(Х. Халиков)*

Авыл халкы аклар пароходының яр буена тукталганын белми иде әле.(раслауны белдерә). *(Г. Гобәй)* 3. Алар кузгалып киткәнгә шактый вакыт узган иде инде.(вакыт төсмерен белдерә) *(Ш. Камал)* 4. Без көткән, без хыялланган җирләр шушы булдымы инде!(ризасызлыкны белдерә) *(М. Гафури)* 5. Сез танышырга теләгән егет нәкъ үзе була инде.(раслауны белдерә) *(Г.Ахунов)* 6. Шул турыдан аз гына – биш-алты сүз сөйлим әле. (үтенүне белдерә); Гадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим әле.. (үтенүне белдерә) *(Г. Тукай) 7.* Бие инде, Йолдыз, бие! (үтенүне белдерә) *(А. Алиш)*

Яхшы, укучылар.

**VI. Йомгаклау.**

1. Сорауларга җавап бирү. Кире информация

Ә хәзер дәрескә йомгак ясыйк. Сез бүген дәрестә нәрсәләр белдегез?

*Укучы:* Кисәкчәләрнең төркемчәләре турында белдек.

Кисәкчәләрнең ничә төркемчәсе бар?

*Укучы:* Сигез төркемчәсе бар.

Аларны санап чыгыгыз.

*Укучы*: Көчәйткечләр, чикләүчеләр, сорауны белдерүчеләр, якынлык-ераклык яки тизлекне белдерүчеләр, раслаучы, ныгытучылар, билгесезлек, икеләнүне белдерүчеләр, үтенү, теләкне белдерүчеләр, инкарь итүне, юклыкны белдерүчеләр.

*Әле* һәм *инде* кисәкчәләре нинди мәгънә белдерәләр?

*Укучы:* Алар боеру мәгънәсен бераз йомшартып үтенүне, яки вакыт төсмерен, яисә ризасызлык һәм раслау кебек мәгънәләр белдерәләр.

Яхшы, укучылар. Сез бүгенге теманы аңлагансыз икән.

**VII. Өй эше бирү, билгеләр кую.**

Ә хәзер,укучылар, өй эше язабыз. 355 нче күнегүне күчереп язарга, кисәкчәләрнең астына сызарга, нинди төркемчәгә каравын билгеләргә. Күнегү азагындагы сорауларга җавап әзерләргә һәм «Таң атып килә» темасына инша язып килергә.

Вариантларда эш:

*1 нче вариант* көчәйткеч, чикләүче, сорауны белдерүче, якынлык-ераклык яки тизлекне белдерүче кисәкчә төркемчәләре кертеп; *2 нче вариант* раслаучы, билгесезлек, үтенү, инкаръ итүне белдерүче кисәкчә төркемчәләре белән җөмләләр төзеп язып килергә.

## ТЕМА: ХӘЛ ТУРЫНДА ТӨШЕНЧӘ (8 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**Ф.Ф. Әхәтова, Яр Чаллы**

**Максат:**

1. Җөмлә кисәкләре турында белемнәрен ныгыту, хәлнең мәгънәсе, сораулары, төрләре турында төшенчә бирү, аларны танып белү күнекмәләре булдыру.

2. Логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын һәм танып-белүне үстерүгә ярдәм итү.

3. Аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру.

**Җиһазлау:** компьютер, проектор, экран, тема буенча мультимедиа презентация, тестлар, кәгазь битләре, карандашлар, татар теле дәреслеге.

## Дәрес барышы:

| |
|---|
| **Уңай психологик халәт тудыру.**<br>*(Укытучы белән исәнләшү, бер-берсенә татар телендә сәлам бирү, куллар белән күрешү).* |
| Актуальләштерү. |
| **Өй эшен тикшерү.**<br>**КУИЗ-КУИЗ-ТРЕЙД**<br>– Өй эшенә җөмлә кисәкләре буенча сораулар әзерләп килергә кушылган иде. Сез хәзер сораулар ярдәмендә бер-берегезнең белемнәрен тикшерерсез. Моның өчен карточкалар ясарга кирәк булачак. 1 нче номерлы укучылар, ак битне алып, урталай бүләләр, яртысын каршы як партнерга бирәсез. Тагын икегә бүлеп, җилкәдәш партнерга бирәсез. Битнең астан ¼ өлешен бөкләргә кирәк. Битнең күренә торган өлешенә соравыгызны язасыз, ә күренми торган өлешенә җавабы языла. Моны үтәү өчен 2 минут вакыт бирелә. Вакыт башланды.<br>– Вакыт чыкты. Хәзер якындагы иптәшегез янына барып, соравыгызны бирәсез, иптәшегез җавап бирергә тиеш. Сораугa җввап бирә алмаса булышасыз. Дөрес җавап ишетсәгез мактыйсыз, аның соравын тыңлап, җавап бирәсез. Бергә кабатлыйсыз: рәхмәт, миңа синең белән эшләргә бик рәхәт булды. Аннан соң карточкаларыгызны алмашасыз, әлеге эшне 3 тапкыр кабатларга кирәк. Барыбыз да бастык, урындыкларны төзәттек. Парлар табабыз. Беренче булып соравын чәче озынрак укучы әйтә.<br>–Укучылар, булдырдыгыз! Өй эшен кабатлап килгәнсез. Ә хәзер җөмлә кисәкләре өстендә эшләүне дәвам итәбез. |

| |
|---|
| **Үткәннәрне ныгыту.**<br>**МИКС ПЭА ШЭА**<br>*Музыка астында укучылар төрле тәртиптә бүлмә буйлап йөриләр. Музыка туктагач, бер-берсенә якын булган укучылар белән парлашалар. Кулларын өскә тоташтырып, бер-берсен сәламлиләр. Укытучы соравына 3-4 секунд эчендә җавап бирәләр.*<br>– **1 сорау. Нәрсә ул җөмлә кисәге?** (Буе озынрак укучы сөйли. Мактыйлар, рәхмәт әйтәләр.) Хәзер бу сорауга җавап бирә...<br>– **2 сорау. Аергыч нинди сорауларга җавап бирә**? (Җавапны аяк киеме зуррак укучы сөйли.) Хәзер бу сорауга җавап бирә...<br>– **3 сорау. Җөмләнең оештыручы үзәген атагыз**. (Җавапны чәче карарак укучы әйтә.) Хәзер бу сорауга җавап бирә...<br>– Яхшы, укучылар, булдырдыгыз. Партнерларыгызга рәхмәт әйтәсез, мактыйсыз.Урыннарга башта так сандагы, аннары җөп сандагы укучылар утыралар. |
| II. Белем һәм күнекмәләрне гомумиләштерү. |
| **Әңгәмә.**<br>**ТЕЙК ОФ – ТАЧ ДАУН**<br>– Татар телендә җөмләнең ничә иярчен кисәге бар? Кайсы иярчен кисәкләрне өйрәндек? Мин атыйм, өйрәнгәннәренә басып җавап бирәсез. Тәмамлыклар? Аергыч? Хәлләр? |
| **Җөмләләр өстендә эш.**<br>Слайдтагы җөмләләрдән хәлләрне табабыз,сорау куеп, мәгънәсен билгелибез. *(Интерактив тактада укучылар җөмләләрдәге хәлләрне билгелиләр, аңлаталар. Калганнары дәфтәрләрдә эшлиләр)* |

| | |
|---|---|
| Дөньяда иң зур байлык –белем.<br>Сүзеңне үлчәп сөйлә.<br>Ашыксаң, кешене көлдерерсең.<br>Акчаңны югалтсаң да, акылыңны югалтма.<br>Былтыр кысканга быел кычкырмыйлар.<br>Кошларны ашату өчен, серле тартма ясагыз.<br>Җиде кат үлчә, бер кат кис. | 1.Дөньяда, эшнең урынын белдерә, кайда? соравына җавап бирә, урын хәле.<br>2.Үлчәп, эшнең рәвешен белдерә, ничек?, рәвеш хәле.<br>3.Ашыксаң, эшнең шартын белдерә, нишләсәң? соравына җавап бирә.<br>4. Югалтсаң да, көтелгән эшнең киресен белдерә, нәрсәгә карамастан? соравына җавап бирә, кире хәл.<br>5.Былтыр,быел, эшнең вакытын белдерә, кайчан? соравына җавап бирә, вакыт хәле.<br>Кысканга, ни сәбәпле? соравына җавап бирә, эшнең сәбәбен белдерә,димәк, сәбәп хәле.<br>6.Ашату өчен, нинди максат белән соравына җавап бирә, эшнең максатын белдерә, максат хәле.<br>7. Җиде кат, бер кат, эшнең күләмен белдерә, күпме? соравына җавап бирә, күләм хәле. |
| Нәтиҗә ясау:<br>Хәлләр нинди кисәкне ачыклап киләләр?<br>Хәл нәрсәне белдерә?<br>Нинди сорауларга җавап бирә?<br>Хәлләрне нинди төрләргә бүләләр? | Фигыль белән белдерелгән кисәкне ачыклап килә;<br>Эш яки хәлнең вакытын, урынын, сәбәбен,шартын,максатын, көтелгән эшнең киресен, күләмен, рәвешен белдерә.<br>Кайчан? Кайда? Ни сәбәпле? Ни өчен? Нинди максат белән? Ничек? Нәрсәгә карамастан? сорауларына җавап бирә. Хәлнең 8 төре бар: вакыт, урын, күләм, максат, сәбәп, шарт, кире,рәвеш. |

| |
|---|
| **Модельләштерү.**<br>**МОДЕЛЬ ФРЕЙЕР**<br>Сезнең алда альбом битләре ята. Башта аны икегә, тагын урталай бүләбез. Шул бүленгән кисәкнең почмагын әз генә бөклибез. Һәм битне вертикаль рәвештә ачып, алдыбызга куябыз. Әлеге биттәге бөкләнгән урыннарны карандаш белән кабатлап чыгабыз. Һәм уртага хәл дип язып куябыз. Беренче баганага билгеләмәсен язасыз, икенчесенә-- сорауларын, төрләрен, өченчесенә – мисаллар, ә дүртенче баганага капма-каршы мисаллар язасыз. Сезгә 4 минут вакыт бирелә. |
| **Билгеләмә** **Характеристика**<br>**ХӘЛ**<br>Мисаллар Капма-каршы мисаллар |
| Нәтиҗә ясау.<br>КОНТИНИУС РАУНД РОБИН<br>Ә хәзер һәрбер өстәлдән 1 нче укучыдан башлап һәркайсы үзләренең язган җавапларын бер-берсенә укыйлар, мактыйлар. Һәр төркемнән 2нче номерлы укучылар җавап бирәләр.<br>–Яхшы, укучылар, сез хәл төрләрен, сорауларын исегездә калдыргансыз. |
| Физкультминутка. Хәл турындагы белемнәрен тикшерү.<br>ИНСАЙД – АУТСАЙД СЁКЛ. |
| *–1,2 нче номерлы укучылар парта арасыннан чыгып, беренче тышкы түгәрәккә басалар. 3,4 нче номерлы укучылар эчке түгәрәккә урнашалар. Кара- каршы басып, бер-берегезне сәламлисез һәм хәл турында белгәннәрегезне сөйлисез, мактыйсыз. (эшне тышкы төркем башлый). Хәзер безгә җавап бирә...* |

<table>
<tr><td colspan="2">–Уң якка борылып, иярчен кисәкләр санынча барып, кара-каршы бер-берегезне сәламлисез һәм хәлнең сорауларын әйтәсез. (эшне эчке төркем башлый). Хәзер безгә җавап бирә...<br>–Уң якка борыласыз, хәлләрнең төрләре санынча атлап, кара-каршы бер-берегезне сәламләп, хәл төрләре турында сөйлисез (эшне тышкы төркем башлый). Хәзер безгә җавап бирә<br>–Уң якка борылып, баш кисәкләр санынча барып, хәлнең сорауларын әйтәсез. (эшне эчке төркем башлый).. Хәзер безгә җавап бирә... Бер-берегезгә рәхмәт әйтеп утырасыз.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Тест эшләү.<br>РЕЛЛИ ТЭЙБЛ.<br>Бер үк кәгазь битендә чиратлашып җавапларны билгелиләр.</td></tr>
<tr><td>Укучылар бер-берсен экрандагы җаваплар буенча тикшерәләр.<br>1. в);<br>2. б);<br>3. а);<br>4. а);<br>5. в);<br>6. в);<br>7. б).<br>8. а)</td><td>Җөмләнең нинди кисәге хәл дип атала?<br>А) Җөмләдә исем белән белдерелгән кисәкне ачыклап, нинди? кайсы? кемнең? нәрсәнең? сорауларының берсенә җавап бирүче иярчен кисәк;<br>Б) Җөмләнең фигыль белән белдерелгән кисәген ачыклап, кемгә? нәрсәгә? кемнән? нәрсәдән? кемдә? нәрсәдә? кебек сорауларның берснә җавап бирүче иярчен кисәк;<br>В) Җөмләдә эш яки хәлнең кайда, ничек, кайчан, нинди шартларда үтәлүен яки үтәлмәвен белдерә торган иярчен кисәк.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td></td><td>2. Мәгънәләре ягыннан хәлләр ничә төргә бүленә?<br>А) 6;<br>Б) 8;<br>В) 9.<br>3. Хәлләр күбрәк җөмләнең кайсы кисәген ачыклыйлар?<br>А) фигыль белән белдерелгән кисәген;<br>Б) исем белән белдерелгән кисәген;<br>В) алмашлык белән белдерелгән кисәген.<br>4. Бирелгән җөмләдәге хәлнең төрен билгеләргә.<br>Аз аша, күп чәйнә.<br>А) күләм хәле;<br>Б) максат хәле;<br>В) вакыт хәле.</td></tr>
<tr><td></td><td>5. Бирелгән җөмләдәге хәлнең төрен билгеләргә.<br>Кызлар, җырлый-җырлый, ашлык чистарталар.<br>А) максат хәле;<br>Б) шарт хәле;<br>В) рәвеш хәле.<br>6. Бирелгән җөмләдә хәл кайсы сүзне ачыклап килгән?<br>Сочинениене дәфтәрләр арасына куйдым.<br>А) сочинениене;<br>Б) арасына;<br>В) куйдым.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td></td><td>7. Бирелгән җөмләдә хәл нинди сүз төркеме белән белдерелгән?<br>Кичен көтү кайтты.<br>А) исем белән;<br>Б) рәвеш белән;<br>В) фигыль белән.<br>8. Уйнап сөйләсәң дә, уйлап сөйлә җөмләсендә хәлләрнең төрен билгеләргә.<br>А) рәвеш хәле, кире хәл;<br>Б) вакыт хәле, рәвеш хәле;<br>В) урын хәле, кире хәл.</td></tr>
<tr><td colspan="2">3.Нәтиҗә. ТЕЙК ОФ – ТАЧ ДАУН<br>– Тестны кемнәр хатасыз башкардылар? Тестта кемнәрнең бер хатасы булды? Ике хата ясаучылар бармы? 3 хаталы эшләр булдымы?...</td></tr>
<tr><td colspan="2">Өйгә эш бирү.<br>119 нчы күнегү.( Хәл төрләренә мисаллар уйлап язарга, җөмләләр төзергә)<br>Хәлләр кергән 7 мәкаль язарга.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Йомгаклау. СИНГЛ РАУНД РОБИН<br>Һәр укучы 30 секунд эчендә түгәрәк буенча дәрестә нинди яңалык ачканын бер-берсенә сөйли. Һәр өстәлдән бер укучы сөйли.<br>– Укучылар, бүген теманы кемнәр «5»легә үзләштерде? (кулларын күтәрәләр) Кемнәр үз эшчәнлегенә «4»ле куя? Кемнәр «3»ле билгесе ала?</td></tr>
</table>

# ТЕМА: ТИҢДӘШ ҺӘМ ТИҢДӘШ ТҮГЕЛ ИЯРҮЛЕ КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КАТЛАУЛЫ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘРНЕ КАБАТЛАУ (8 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**Р.С. Ганиева, Апас**

**Максат:**

1. Тиңдәш һәм тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләләрне актуальләштерү, аера белү, алган белемнәрен системалаштырырга ярдәм итү.

2. Гомумиләштерү күнекмәләрен камилләштерү.

3. Фәнгә аңлы караш, патриотик хисләр тәрбияләү.

Дәрес тибы – белемнәрне тигезләү.

**Җиһазлау:** таблица, интерактив такта,компьютер презентациясе, карточкалар мультимедиа система слайдлары,перфокарталар.

## Дәрес барышы

Кереш өлеш (укучыларны дәрескә әзерләү).

Өйрәнелгән материалны ныгыту.

**Укытучы:** Исәнмесез, укучылар. Хәерле көннәр. Кәефләрегез ничек? Бүгенге дәресебезне күп кырлы шәхес иясе, педагог, олпат дин әһеле Р. Фәхретдиннең гыйбрәтле сүзләре белән башлап җибәрәм. « Кешеләрне шатландыруың – үзеңне шатландыруыңдыр». Димәк, бүген сез үзегезнең ныклы белемнәрегез, ә мин сезне яхшы билгеләрем белән шатландырырмын.

Дәресебезнең темасы – тиңдәш һәм тиңдәш түгел ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләләрне кабатлау. Эпиграф итеп, мин күренекле шагыйребез Ә.Исхакның шигъри юлларын алдым :

**«Җир өстендә канлы сугыш кабатланмасын өчен,**
**Ятимнәрнең күз яшьләре кабат таммасын өчен**
**Ныгытабыз илебезне без тыныч хезмәт белән»**

Менә шундый аһәңле шигырь юллары. Укучылар, бу шигъри юлларда нинди мәгънә ята?

**Укучылар җавабы.**

**Укытучы**: Әйе, бу шигъри юлларның мәгънәсе тирән, эчтәлекле. Быел 1912 нче ел Рәсәйдә – Тарих, ә Татарстан Республикасында – тарихи – мәдәни мирас елы итеп билгеләнде. Димәк, без үзебезнең тарихыбызны, рухи традицияләребезне, гореф-гадәтләребезне, мәдәниятебезне, телебезне сакларга, онытмаска, үстерергә тиешбез. Дәрестә тикшерелә торган җөмләләребез дә тарихи-мәдәни мирас елына багышланган. Ә хәзер дәресебезнең эпиграфына кире кайтыйк әле. Экранда күрсәтелгән шигъри юлларыбыз безнең темабызга туры киләме? Ни өчен ?

**Укучылар җавабы.**

**Укытучы:** Кайсыгыз шул шигъри юлларның схемасын төзи ?

Бер укучы шигъри юлларның схемасын интерактив тактада төзи.

**Укытучы**: Ә хәзер 2 группага бүленәбез. Беренче группа тест, ә икенче группа перфокарталар белән эшли. (Һәр группага карточкалар (тестлар) һәм перфокарталар таратыла). 1-2 минуттан җавапларыгызны тикшерәм. Тестта 5 сорау, һәр дөрес җавапка 1 балл. Перфокартада тәкъдим ителгән җөмләләрнең төрен дөрес итеп урнаштырырга кирәк. (Тикшергәндә, тест һәм перфокарталардагы

җөмләләрнең үрнәкләре һәм җаваплары экранда(интерактив тактада) күрсәтелә бара).

**Укучылар җавабы.**

**Дәресне йомгаклау**

**1. Нәтиҗә.**

Укытучы: Бүгенге дәрестә без тиңдәш һәм тиңдәш түгел ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләләрне кабатлап, белмнәребезне ныгыттык, системага салдык, күп иярченле кушма җөмләләрнең төрләрен аера белергә өйрәндек. Дәресебезнең нәтиҗәсе булдымы? Бүген сыйныфта ничек эшләдек?

**Укучылар җавабы.**

**2. Укучыларның белемнәрен бәяләү.**

**Өй эше**

1 нче группага матур әдәбияттан тарихка багышланган тиңдәш, ә 2 нче группага милли мәдәниятебезгә кагылышлы тиңдәш түгел ияргүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләләр язып алырга.

**<u>Перфокартаның үрнәге</u>**

| **Саны** / **Төре** | 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|---|
| Тиңдәш ияргүле күп иярченле кушма җөмлә | | | | |
| Тиңдәш түгел ияргүле күп иярченле кушма җөмлә | | | | |

**<u>Җөмләләр</u>**

Мин киенәм дә, узган гасырларның байбичәләре крахмалланган киң итәкләре белән йөзеп кенә чыксын өчен ике якка ачылмалы итеп, әтәч кикригедәй купшы прическалары

тимәсен өчен биек итеп эшләнгән ишекнең сыңарын гына ачып, коридорга чыгам.

Күрде бу: кемдер землянка казый, кайберәүләр шалаш, чатыр ише нәрсә корып маташа.

Шартлау ишетелгәнгә кадәр, тирә-юнь яп-якты булып, вак ташларга хәтле күренде.

Күнелендә ни үкенечләр булса да, кеше, яше арта барган саен, тыныч тормышка омтылып яши башлый.

**<u>Тестның үрнәге</u>**

**Тест**

1. Берничә иярчен җөмлә бер баш җөмләгә буйсынып килә, һәм алар барысы да бер үк вазифаны башкара.

а) иярченле кушма җөмлә

ә) тезмә кушма җөмлә

б) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

в) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

2. Ил кузгалгач, халык күтәрелгәч, Ватан үз улларын һәм кызларын көрәш сафларына чакырды.(А.Ш.)

а) тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә

ә) тиндәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмлә

3. Иярчен җөмләләр бер үк баш җөмләгә карый, ләкин төрле вазифа башкара.

а) тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә

ә) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмлә

б) тезмә кушма җөмлә

в) иярченле кушма җөмлә

4. Менә шундый тургайлар сайрап торган кояшлы көннәрнең берсендә безнең Ефимов дигән солдатыбыз яшь үлән каплап киткән минага туры килеп һәлак булды да куйды. (Ә.Е)

а) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмлә

ә) тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә

5. Гади җөмләләре үзара ияртү юлы белән генә бәйләнгән катлаулы төзелмә…

а) тезмә кушма җөмлә

ә) тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә

б) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмлә

в) күп иярченле кушма җөмлә.

# ТЕМА: СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕН КАБАТЛАУ (2 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**Ә. Б. Җиһаншина, Яр Чаллы**

**Максат:**

Мәгънәләре, нинди сорауга җавап бирүләре буенча сүзләрне төркемнәргә бүлергә өйрәтү; укучыларның фикерләү сәләтен камилләштерү, сөйләм һәм язма телне үстерү, үз фикерләрен әйтә белүгә ирешү; уку хезмәтенә җитди караш, игътибарлылык, пөхтәлек тәрбияләү; үзара эшлекле аралашу мөнәсәбәтләре булдыру.

**Дәрес тибы:** Интеграция элементлары белән катнаш дәрес. Предметара бәйләнеш: әдәби уку, музыка.

**Дәрес төре:** Йомгаклау дәресе.

**Җиһазлау:** Дәреслек, компьютер, интерактив такта, пианино.

Дәрестә кулланылган **сингапур структуралары**: РАУНД ТЭЙБЛ, МИКС ПЭА ШЭА, ТАЙМД – ПЭА – ШЭА.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше.** Уңай психологик халәт тудыру.( Музыкаль сәламләү, дежур укучы белән әңгәмә, фонетик зарядка).

Мин дәрестә утырам. Игътибарлыгым үсә, Минем укыйсым килә!

Белемемне арттырам. Фикерләвем дә арта. МИН ӘЗЕР! МИН ЭШЛИМ!

**II. Дәреснең темасын билгеләтү.**

**Укытучы.** Укучылар, без сүз төркемнәрен өйрәндек. Нинди сүз төркемнәрен беләсез? (Исем, сыйфат, фигыль). Бүген сүз төркемнәре турында алган белемнәрне тагын да ныгыту өстендә эшләрбез.

**III. Алган белемнәрне актуальләштерү.**

1.Укучылар, тиздән халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көне җитә. Аның нинди әкиятләрен, шигырьләрен беләсез?(«Су анасы», «Шүрәле»,»Бала белән күбәләк»һ.б.) Г.Тукай үзенең әсәрләрендә балаларны ялкау булмаска, тырыш булырга өнди. Укучылар, тактага язылган мәкальне укыгыз әле. (Тырышкан табар, ташка кадак кагар). Бу мәкальнең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? (Әйе, тырыш кеше һәрвакыт максатына ирешә, укуда да тырышырга кирәк...)

Ә хәзер число языгыз һәм матур итеп бу мәкальне күчереп языгыз.

2. Өч укучы такта янында эшли һәм җавап бирә. Ә калган укучылар дәфтәрдә **юрган** сүзенә фонетик анализ ясыйлар.

бол...ыт [ ] ...фрак [ ] вакыт [ ]

Юрган [йургъан] – 5 хәреф, 6 аваз бар. Басымлы иҗек – -ган;

1нче иҗек – ябык, 2 нче иҗек – ябык;

[й], [р], [гъ], [н] – яңгырау тартыклар;

[у], [а] – калын сузыклар.

Бу – калын сүз.

(Экранга карап, фонетик анализны тикшерү).

**IV. Төп өлеш. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.**

1.Теманың үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү һәм бәяләү.

**Укытучы**. Мин сүзләр әйтәм, ә сез шул сүзләрне дәфтәрдә тиешле баганага языгыз.

Сүзләр: күбәләк, көчле, килде, кыш, оча, матур, салкын, исә, җил.

(Экранга карагыз, тикшерегез.)

**Сыйфат Исем Фигыль**

салкын күбәләк килде

матур кыш оча

көчле җил исә

– Шушы сүзләр ярдәмендә җөмләләр төзеп языгыз.

(Салкын җил исә. Матур күбәләк оча. Көчле җил исә.)

2. Физкультминут. (Хәрәкәтләр белән күрсәтеп әйтәләр).

Яңгыр ява шып та шып. Тамча тама тып та тып.

Күк йөзенә карадык, битләребез чыланды,аяклар юешләнде. Җилкәләрне сикерттек, тамчыларны селектек.

Без яңгырдан куркабыз, куакларга качабыз!

3. Ишетеп аңлауны тикшерү.

**Укытучы**. Ә хәзер сүзне музыка укытучысы Ирина Александровнага бирәм.Рәхим итегез.

**Музыка укытучысы.**

– Укучылар, бүген сез дәрестә сүз төркемнәре турында сөйләштегез, аларны искә төшердегез. Ничек уйлыйсыз, сүз төркемнәрен музыка әсәрләрендә очратып буламы?

– Менә хәзер без сезнең белән бергә фольклор әсәрләренең бер төре – такмаклар турында сөйләшербез. (Такмаклар турында әңгәмә).

**Укытучы.** Укучылар, игътибар белән сыйныфташларыгыз башкаруында такмаклар тыңлагыз. Такмакта яңгыраган сүз төркемнәрен истә калдырырга тырышыгыз.

РАУНД ТЭЙБЛ структурасы кулланыла. 3 укучы такмаклар җырлый. Калган укучылар җырда яңгыраган сүз төркемнәрен, чиратлашып, кәгазьгә язып баралар. 1нче сан

астында утыручы укучы башлый. (Һәр такмакка 4 минут вакыт бирелә).

1. Яшел сумкалар тоткансың 2. Җылы бияләй кигәнсең
Яшел сумка килешә. Бияләең өр-яңа.
Яшел сумка тоткан кызлар Җылы бияләйләр киеп,
Теләгенә ирешә. Килгәнсең безнең янга.
3. Зәңгәр яулык матур була
Кызлар бәйләсә генә.
Дусны дус дип әйтеп була,
Сүзендә торса гына.

Сыйфатлар: яшел, җылы, өр-яңа, зәңгәр, матур.

Фигыльләр: килешә, ирешә, килгәнсең,әйтеп була.

Исемнәр: сумка, кызлар, бияләй, яулык, дус.

Экранга карагыз, тикшерегез. (Хаталар булса, төзәтегез).

**V. Ныгыту**.

1. Уен.

**Укытучы.** Хәзер кунакка сүз төркемнәрен чакырабыз: исемне, сыйфатны һәм фигыльне (3 укучы такта янына чыга).

– **Мин – исем**. Мин предметны белдерәм, кем? нәрсә? сорауларына җавап бирәм. Кем? соравын кешегә карата гына куярга ярый. Мин берлек санда һәм күплек санда булам. Күплек санда миңа -лар, -ләр, -нар, -нәр кушымчалары ялгана. Минем урыным уртада. Сул ягымда – фигыль, уң ягымда сыйфат торырга тиеш.

– **Мин – фигыль**. Предметның эшен, хәрәкәтен белдерәм, нишли? нишләде? нишләгән? нишләр? нишләячәк? сорауларына җавап бирәм. Мин исемнән артта торырга тиеш, аның эшен белдерәм. Шуңа күрә татар телендә мине җөмләнең ахырында язарга кирәк.

– **Мин – сыйфат**.Предметның билгесен белдерәм, нинди?кайсы? сорауларына җавап бирәм. Исемнең алдында торам, җөмләдә исемгә иярәм, аны ачыклыйм. Мин сөйләмне матурлыйм.

2. МИКС ПЭА ШЭА структурасы кулланыла. Музыка яңгырый. Укучылар каршыда утыручы партнёрлары белән саубуллашалар, таралышалар. Музыка туктагач, якындарак торган укучы белән парлашып басалар, бер-берсен сәламлиләр. Сүз төркеме булып, чиратлап сөйлиләр. ТАЙМД – ПЭА – ШЭА структурасы кулланыла. Беренче булып кыскарак буйлы укучы(исемендә хәреф саны азрак булган укучы; озын чәчле укучы) сөйли. Рәхмәт әйтеп, хушлашалар.

**VI. Рефлектив кабатлау.**

– Без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләштек?
– Кайсы сүз төркемнәрен искә төшердек?
– Җөмләдә фигыльнең урыны кайда булырга тиеш?

**VII. Йомгаклау.** Өйгә эш бирү. Билге кую.

Өй эше: 1. (Җиңеләйтелгән вариант). Сүз төркемнәрен кулланып, яз турында 2 җөмлә төзеп язарга. 2. (Катлаулы вариант). Сүз төркемнәрен кулланып, яз турында кечкенә хикәя төзеп язарга.

## ТЕМА: Е ХӘРЕФЕ ҺӘМ [ Е] АВАЗЫ (1 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**Г.Р. Әхмәтшина, Бөгелмә**

**Максат:** 1. Е авазын дөрес әйтергә өйрәтү, схемасын күрсәтү, е хәрефенең сүздә тоташтыру ысулларын өйрәнү; Укучыларның хәтерендә е хәрефенең күрмә-хәрәкәт образын формалаштырып аны алгоритм буенча язарга һәм хәрефләрне астан, өстән, уртадан дөрес тоташтырырга өйрәтү.

2. Укучыларда аналитик – синтетик фикерләү эшчәнлеген, фонематик ишетү, сүздәге өйрәнелә торган авазны аны чагырдыручы хәрефкә һәм хәрефне авазга күчерү күнекмәләрен үстерү.

3. Сөйләм эшчәнлегенең төре буларак язуга уңай мөнәсәбәт һәм тотрыклы танып белү мотивы тәрбияләү.

**Җиһазлау:** «Перспектив башлангыч мәктәп» укыту-методик комплекты «Әлифба» И.Х. Мияссарова, Ф.Ш. Гарифуллина, Казан «Мәгариф-Вакыт» 2011.; тема буенча презентация.

**Дәрес тибы**: Яңа белем бирү. **Дәрес төре**: Катнаш.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру.**

–Укучылар, кәефләрегез ничек?

Елмайган кояш кебек? (күтәренке кәефлеләр кул чаба)

Бераз болыт каплдымы? (төшенкерәк кәефлеләр булса, кул чабалар)

Киттеме яңгыр сибеп? (начар кәефлеләр өчен)

Күрәм, кәефегез бик яхшы,болай булгач, без дәрестә күп нәрсәләр өйрәнербез. Хәзер бер-беребезгә карап елмаеп алыйк та,дәресне башлыйк.

**II. Уку мәсьәләсен кую һәм актуальләштерү.**

– Балалар, безгә бу дәрестә бик тә игътибарлы булырга кирәк, чөнки без тагын бер хәрефне дөрес әйтергә язарга өйрәнербез. Әйдәгез, хәзер игътибарлылыгыгызны ачыклап алыйк.

1. **«Уйлап кара» уены.**

**Ю а н л ы ө**

Балалар, монда кайсы хәреф әле безгә таныш түгел? (Көтелгән нәтиҗә:«е » хәрефе,чөнки без аны әле өйрәнмәдек, ә калган хәрефләрне өйрәндек.)

– Балалар, димәк, без бүгенге дәрестә кайсы хәрефне укырга, язарга өйрәнергә тиеш булабыз инде?

(Балалар белмәсә икенче табышмак тәкъдим итеЛә.

Елда да бар хәрефем,
Елан да мине алган.
«Елый» сүзендә булсам да,
Яратмыйм елакларны.



– Е хәрефен

2. « Е » хәрефе һәм [е] авазы турында

– Әйдәгез әле Ю һәм Я хәрефе турында искә төшереп китик. Ю хәрефе турында кем сөйләп китәр икән? Ә калганнар игътибар белән тыңлый,кирәк булса төзәтмәләр кертергә әзерләнә (көтелгән нәтиҗә: алар 2 аваз белдерәләр.

**III. Яңа белем ачу.**

**Дәреслек белән эш**

– Рәсемгә карагыз. Бу рәсемдә сез кемнәрне күрәсез? (бүре.төлке)

Бүре нишләгән? (өшегән)

– Ни өчен өшегән? (чөнки ул кыш көне елга (боз) өстендә утыра)

| | | | |
|---|---|---|---|
| [б] | [ү] | [р] | [э] |

**Бүре**

**елга**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| [й] | [ы] | [л] | [г] | [а] |

Нәтиҗә: е

[йы] [йэ]

– Кайсы очракта е хәрефе 2 аваз белдерә? (сүз башында килсә)

– Укыгыз, нечкә һәм калын әйтелешле сүзләрне табыгыз

**е уен**

**ел өем**

**ела тиен**

**елан иген**

**ер ишек**

**ера**

Нәтиҗә

– димәк нәрсәләргә карап без аларның нечкә һәм калын сүзләргә аерабыз(сузык авазларга карап)

Физкультминут. Әйт әле үскәнем.

**1. Укучылар хәтерендә хәрефнең күрмә образын формалаштыру**.

– Чагыштырып, охшаш һәм аермалы якларын табыгыз. Ә хәрефе

е ә

– Ә хәзер кирәкле өлгеләрне табып «е» хәрефен төзеп карагыз.

**2. Укучылар хәтерендә хәрефне дөрес әйтергә өйрәтү.**

– Булдырдыгыз, балалар. Игътибарны экранга юнәлтик һәм юл «е» хәрефенең кайдан башлап язылганын ачыклыйк.

– Әйдәгез, бергәләп юл «е» хәрефен язу эзлеклелеген төзеп карыйк. (1 укучы язу алгоритмын сөйли, укытучы һәм калган укучылар булыша, укытучы тактага хәрефне яза)

– Ә хәзер мин сезгә хәрефне тактлап язу алгоритмын күрсәтәм. Игътибар белән тыңлагыз. (Тактада эшләү)

**Физкультминут–ехәрефенимитацияләүкүнегүләре** (слайдтагы ручкага ук белән басып хәрәкәтләндерү)

– Балалар, әйдәгез, парта кырыйларына чыгып басып бу хәрефне һавада язып карыйк:

– баш белән язабыз;

– гәүдә белән;

– уң (сул) терсәк белән;

– имән бармак белән;

– ике кулның да имән бармаклары белән берьюлы

– хәрефләрне күз белән йөртеп чыгабыз;

– ручканы дөрес итеп тотып хәрефне йөртеп чыгабыз;

**IV. Беренчел ныгыту.**

**1. Дөрес утырып язу кагыйдәләрен искә төшерү.**

– Балалар, Әминә язу дәресендә нинди кагыйдәгә таянып эшли? Әйдәгез, без дә бу кагыйдәне искә төшерик һәм аны үтик (кушымта-№1)

– Дәфтәрнең 26 нче битендәге зәңгәр рамкада эшли башлыйбыз («е» хәрефен язу алгоритмын бергәләшеп кабатлап языла)

**2. Дәфтәрдә эш.**

– Дөрес торышны бер юлны язып бетергәнче саклап, дөрес итеп язарга өйрәнү кагыйдәсен үтәп (кушымта – №2)«е» хәрефен бер юл язабыз һәм үзегез иң дөрес язылган дип уйлаган хәреф астына сызыгыз (индивидуаль ярдәм күрсәтелә).

**V. Яңа белемнәрне куллану, үрнәк буенча мөстәкыйль эшләү, үзанализ һәм үзтикшерү.**

**1. Хәрефләрне тоташтырып язу күнегүләре**.

– Икенче һәм өченче эш юлына язылган сүзләрне рәттән берәм-берәм укыйбыз, хәрефләрне тоташтыру төрен әйтеп барабыз (2 нче юл – өстән, 3 нче юл астан тоташтыру), дөрес утыру торышын саклап, сүзне хатасыз язу кагыйдәсен искә төшереп язабыз (кушымта – №3).

**VI. Эшчәнлеккә рефлексия.**

– Дәрес башында без бүген тагын бер хәрефне әйтергә, язарга белә башлаячакбыз дигән идек.

– Балалар, бүгенге дәрес безгә нәрсә бирде,шуны ачыклыйк (схема буенча балаларның җаваплары тыңлана).

| | |
|---|---|
| | өйрәндем |
| | исемдә калдырдым |
| Мин | белдем |
| | гаҗәпләндем |
| | аңлап бетермәдем |

– Укучылар, кәефләрегез ничек?

Елмайган кояш кебек? (күтәренке кәефлеләр кул чаба).

Бераз болыт капладымы? (төшенкерәк кәефлеләр булса, кул чабалар).

Киттеме яңгыр сибеп? (начар кәефлеләр өчен).

Күрәм, кәефегез бик яхшы, сез дәрестә күп нәрсәләр өйрәнгәнсез. Хәзер бер-беребезгә карап елмаеп алыйк та, дәресне тәмамлыйк.

## ТЕМА: О, Ө, Ы, Э (Е) ХӘРЕФЛӘРЕНЕҢ ДӨРЕС ЯЗЫЛЫШЫ (5 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**В.Ә. Гаделшина, Бөгелмә**

**Максат:** Татар сүзләре һәм алынма сүзләрдә о,ө,ы,э(е) хәрефләрен дөрес язу, әлеге хәрефләр кергән сүзләрне дөрес әйтә, сөйләмдә дөрес аера белү күнекмәләре формалаштыру; укытучы куйган максаттан чыгып, үз эшчәнлекләрен планлаштыру һәм аларны тормышка ашыру юлларын, чараларын эзләү, табу, сынап карау, нәтиҗә ясау.

Укучыларның чагыштыру, анализ ясый белү, кагыйдәләр формалаштыра һәм дәлилли белү күнекмәләрен үстерү, әдәби телдә дөрес һәм образлы итеп сөйләү телен үстерү, укучыларның сүзлек байлыгын арттыру.

Укучыларда үз-үзләренә карата таләпчәнлек, төгәллек, әйләнә-тирә дөньяга, янәшәдәге кешеләргә игътибарлылык, дуслык хисен һәм дусларга карата хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Проектор, ноутбук, электрон презентация, биремле карточкалар (вариантларда эшләү өчен әзерләнгән таратма материал); дәреслек: Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү мәкт. 5нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен). Ф.Ф. Харисов,Ч.М. Харисова. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2012. – 159 б.

### Дәрес планы

**I. Оештыру моменты.**

1. Укучыларны сәламләү.

2. Укучыларның дәрескә әзерлеген тикшерү,дежур укучы рапортын тыңлау.

3. Уңай психологик халәт формалаштыру һәм дәресне башлау.

**II. Өй эшен тикшерү.**

1. Укучыларга өй эшен тикшерү максатыннан тест биремнәре тарату.

2. Җавапларны парларда тикшерү.

3. Нәтиҗә ясау.

**III. Яңа белем һәм күнекмәләр формалаштыру.**

**1. Төп этапта булачак актив эшчәнлеккә әзерлек. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәрес эпиграфы итеп сайланган шигъри өзекне уку. Дуслык турында әңгәмә (слайдлардагы мәкальләр белән танышу).

Астына сызылгын сүзләргә транскрипция ясау.

Уку мәсьәләсен формалаштыру.

2. Яңа теманы аңлату.

Биремле сүзлек диктанты язу.

О, э хәрефләренең алынма сүзләрдә һәм татар сүзләрендә әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләре буенча нәтиҗә ясау. Кагыйдә формалаштыру.

**V. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.**

Тәрҗемә эше.

Физкульминут ясау.

Дәреслек белән эш. 153 нче күнегү.

3. Вариантлап биремле карточкалардан эшләү.

4. Вариантларны алмашып, парларда биремнәр үтәлешенең дөреслеген тикшерү.

**VI. Өй эше бирү.**

1. 72, 75нче бит – кагыйдә, 154нче күнегүне эшлә.

2. Бүгенге темага кагылышлы сүзләр кергән 5 мәкаль яки табышмак табып яз.

3. Кагыйдә үзенчәлекләрен чагылдырган әкият иҗат ит.

**VII. Йомгаклау.**

1. Укучыларның дәрестәге эшчәнлегенә бәя.

Дәрес барышы.

**I. Оештыру моменты.**

*Укытучы өчен максат:* балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру. Моның өчен укучылар белән әңгәмә үткәрү.

*Укучылар өчен максат:* дәрескә игътибар булдыру.

– Саумы, кояш, саумы,көн!
Дусларым, хәерле көн!
Телим сезгә сәламәтлек,
Бәхет һәм яшәү дәрте.
Уе изге баласына
Булышыр табигать тә.
Эшкә тотыныйк, дусларым
Хуш, хәерле сәгатьтә!

(бу урында тәртип буенча дежур укучы рапорты тыңлана).

– Бүген 3 нче декабрь. Дүшәмбе көн. Урамда кыш фасылының матур көне. Без татар теле дәресенә әзерләндек. Сыйныфта барыбыз да бар. Дәрескә бөтенебез дә әзер. Өй эше «Татар телендә сузык авазларны белдерүче хәрефләр» темасына карата бирелгән сорауларга җаваплар әзерләргә иде».

– Укучылар, сезнең барыгызны да исән-имин күрүемә мин бик шат. Дәрестә яңа теманы үзләштерүдә зур уңышлар һәм җиңеллекләр телим үзегезгә.

**II. Өй эшен тикшерү.**

*Укытучы өчен максат:* Үткән теманы аңлау дәрәҗәләрен ачыклау.

*Укучылар өчен максат:* Үткән теманы үзләштерү дәрәҗәсен, ягъни өй эше дөреслеген тикшерү.

– Укучылар, сез үзегезгә бирелгән сорауларга дөрес җавап бирсәгез, дәрестә алга таба уңышка ирешерсез. Шуңа күрә өй эшен тикшерү максатыннан, мин сезгә тест биремнәре тәкъдим итәм. (Һәр балага тест биремнәре таратыла. Укучылар биремнәр белән танышалар, аңлашылмаган төшенчәләр, сүзләр булганда сорыйлар). Балалар, барыгыз да биремнәр белән таныштымы? Биремнәрнең бөтенесе дә аңлашыламы? Хәзер сез нәрсә эшләргә тиеш?

– Без бирелгән сорауларга бер дөрес җавапны гына сайларга тиеш. (Тест җаваплары махсус тест дәфтәрләрендә теркәлә.)

**ТЕСТ**

*Һәр сорауга бер дөрес җавапны гына билгеләгез!*

Ике аваз кушылмасын белдерүче хәрефләр дөрес күрсәтелгән җавапны тап.

А) я, а, ю, э

ә) ю,я, е

Б) э,е,ё

2.Кайсы рәттәге сүзләрдә «э» хәрефе генә төшеп калган?

А)...пиграф,...лемтә,..кран

Ә) т..л..фон, т...кст, т...ман

Б) шахт..р, самол..т, вертол...т

3. «Юллар» сүзендә

А) 5 хәреф, 5 аваз

Ә) 6 хәреф, 5 аваз

Б) 5 хәреф, 6 аваз

4. [а] авазы рус сүзләрендә иренләшәме?

А) әйе

Ә) юк

Б) белмим

5. Кайсы юлдагы сүзләрдә «Э» хәрефе саңгырау тартык һәмзәгә тамга булып йөри?

А) аэрочана, экран, эскәмия

Ә) каратэ, эзлекле, телеэкран

Б) мөэмин, тәэмин, тәэсир.

– Укучылар, әгәр дә җавап бирү төгәлләнсә, янәшәдәге иптәшегез белән дәфтәрләрегезне алмаштырып, тест җавапларының дөреслеген тикшерик (парларда тикшерү) .Инде ахыргы нәтиҗәне ясау өчен, слайдка игътибар итегез. (Слайдта дөрес җаваплар күрсәтелә.) Балалар, кемнең бер хатасы да юк – бишле, 1 хатага дүртле, 2-3 хатага өчле билгесе куябыз.

(Слайдта дөрес җавап күрсәтелә: 1-ә, 2-а, 3-б, 4-ә, 5-б. Парларда билгеләр куела, дәфтәрләр хуҗаларына кайтарыла).

(Укытучы өйгә эшнең үтәлеш дәрәҗәсен билгеләп китә).

**III. Яңа белем һәм күнекмәләр формалаштыру.**

1. Төп этапта булачак актив эшчәнлеккә әзерлек. Уку мәсьәләсен кую.

– Инде мин сезнең алдагы слайдка күз салуыгызны үтенәм. Монда Сибгат Хәкимнең шигыреннән өзек бирелгән. Кемнең кычкырып укып күрсәтәсе килә?

– <u>Эзләмә</u> син диңгез <u>төбеннән</u><br>
Һич табылмый торган энҗене;<br>
Тап иптәшең булыр <u>кешене</u>,<br>
Гади бер дус – үзең ишене.

*(Дуслык турында әңгәмә үткәрү)*

– Бу шигырь нәрсә турында?

– Дуслык турында?

– Ә нәрсә соң ул дуслык? Кем ничек аңлый бу төшенчәне?

– ... (җаваплар тыңлана)

– Дуслык кемнәр арасында булырга мөмкин?

– ... (җаваплар тыңлана)

– Дус кеше нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

– ... (җаваплар тыңлана)

– Дуслар ни өчен кирәк?

– ... (җаваплар тыңлана)

– Әйе,балалар, яхшы иптәш белән уйнавы да, эшләве дә күңелле.Чын дус авыр чакта ташлап китмәскә тиеш. Дусларсыз яшәве бик күңелсез, алар тормышта һәрвакыт кирәк.

Укучылар, дуслык турында сөйләшүебезне төгәлләп, слайдтагы язылган мәкальләр белән танышып чыгыйк әле....., укысын әле.

– Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсачы.

Кош-канаты белән, кеше дуслык белән көчле.

Юлга чыкканда, иптәшең үзеңнән яхшы булсын.

Чын дуслыкның кадерен бел.

– Алга таба без үзебез укыган шигырьдә асларына сызылган сүзләргә транскрипция ясарбыз. Мин 3 укучының такта янына чыгуын, ә башка укучыларның әлеге биремнәрне урыннарда башкаруын сорыйм. Дәфтәрләргә бүгенге числоны, сыйныф эше дип язып куегыз. Аннан соң сүзләрнең транскрипциясен язып куегыз....,...,..., такта янында эшлиләр.

Эзләмә-[эзләмә], төбеннән-[төбөннән], кешене-[кэшэнэ].

(Транскрипциядә укучылар э хәрефенең сүз башында гына килүен,ирен гармониясе чагылышын һәм е хәрефенең [э] авазы белән бирелүен күрә һәм әйтә алырга тиеш.)

– Укучылар, без бергәләп нинди зур теманы үзләштерә башладык, искә төшерик әле.

– Без татар теле грамматикасының «Орфография» бүлеген өйрәнә башладык. Орфография сүзләрнең дөрес язылышын өйрәнә торган фән.

– Балалар, әйдәгез бергәләп, бүгенге дәресебездә үзебез өчен максат куйыйк. Моның өчен тактадагы сүзләргә тагын бер кат карагыз.

Көтелгән җавап үрнәге:

– Бүгенге дәрестә без о, ө, ы, э(е) хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу кагыйдәләрен үзләштерергә, искәрмә очраклар булса, аларны истә калдырырга тиешбез.

– Бик дөрес, балалар, бүгенге дәресебез, чыннан да, о,ө, ы, э(е) хәрефләренең татар сүзләрендә һәм алынма сүзләрдә дөрес язылышына багышлана. Бергәләп формалаштырган максатыбызга ирешү өчен, без төрле күнегүләр башкарырбыз, чагыштырып нәтиҗәләр ясарбыз, үзебез чыгарган кагыйдәләрне дәреслектәге билгеләмәлмәр белән чагыштырырбыз, дөресләрбез.

2. Яңа теманы аңлату.

– Балалар, дәресебезне алга таба дәвам итик. Бүгенге дәресебездә безгә татар сүзләре белән беррәттән алынма сүзләр дә очрар. Мин сезнең әлеге сүзләрне аера белү дәрәҗәгезне билгеләр өчен, биремле сүзлек диктанты яздырам. Сезнеңчә, «эремчек» һәм «элемент» сүзләренең аермасы нидә?

Көтелгән җавап үрнәге:

– Эремчек – татар сүзе, элемент – алынма сүз.

– Фикерләвегез дөрес, укучылар. Мин ике укучының тактада эшләвен сорыйм. Урыннардагы укучылар дәфтәрләрегезне 2 баганага бүлеп ( татар сүзе, алынма сүз), мин әйткән сүзләрне дөрес итеп язабыз. (Сүзләр сүзлек диктанты яздыру методикасына туры китереп яздырыла).

Борыч, озынборын, микрофон, мотор, орган, эңгер-меңгер, орган, каратэ, эчемлек, энергия

Укучылар эше түбәндәгечә килеп чыгарга тиеш:

Борыч микрофон

Озынборын мотор

Эңгер-меңгер каратэ

Орган орган

Эчемлек энергия

– Укучылар, хаталарыбызны тикшерик, барыбыз да дөрес эшләде микән? (слайдта дөрес эшләнеш бирелә). Балалар, әйтегез әле, бу ике баганадагы сүзләрне нәрсә берләштерә?

– Һәр ике баганадагы сүзләрдә дә о, э(е) хәрефләре бар. Ләкин 2 багана сүзләре арасында алар үзара әйтелешләре белән аерыла. Рус теленнән кергән алынма сүзләрдә о, э(е) хәрефләре татар сүзләрендәгегә караганда озынрак әйтелә. Язылыш үзенчәлекләренә килсәк, татар сүзләрендә э хәрефе сүз башында гына язылган.

– Димәк, укучылар, нәтиҗә ясап, татар сүзләрендә о хәрефенең тамыр сүзнең беренче иҗегендә генә язылуын, э хәрефенең сүз башында гына килүен күрдек. Рус телендә әлеге хәрефләрнең язылышы буенча мондый кагыйдә юк. ( укучыларга үз-үзләрен бәяләргә кушыла, бәяләү критерийлары: хатасыз яки 1 хата – 5, 2 хата – 4, 3-4 хата – 3.)

Слайдта язылган кагыйдәне укып китик:

– Татар сүзләрендә о, ө хәрефләре **тамыр сүзнең** беренче иҗегендә генә языла. Алдагы иҗекләрдә [о],[ө]

авазлары ишетелсә дә, ы, е хәрефләре языла. Э хәрефе татар сүзләрендә сүз башында гына языла, башка иҗекләрдә [Э] авазы е хәрефе белән бирелә. Алынма сүзләрдә э һәм о хәрефе сүздә озын әйтелә һәм төрле урыннарда язылырга мөмкин.

**V. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.**

– Дәресебезне дәвам итик, укучылар. Сезнең русча текстларны татар теленә никадәр дөрес һәм төгәл тәрҗемә итүегезне белер өчен, мин сезнең түбәндәге җөмләләрне татарчага тәрҗемә итүегезне сорыйм. Әлеге җөмләләр Радий Погодинның «Жаба» әсәреннән алынды.

Җөмләләр :

Позавчера нам было гораздо интереснее.

Долгожданные гости прибудут послезавтра.

Всякое существо рождается для жизни на Земле. (Р.Погодин «Жаба»)

(*Көтелгән тәрҗемә үрнәге: Өченчекөн безгә күпкә кызыграк иде. Көтелгән кунаклар берсекөнгә килеп җитә. Һәртөрле җан иясе җирдә яшәү өчен туа.)*

– Укучылар, бу җөмләләрне тәрҗемә итүнең нинди сере булды соң? Кем бик игътибарлы икән?

Көтелгән җавап:

– Бу җөмләләрдә без уза торган темага караучы өченчекөн, берсекөнгә, һәртөрле сүзләре бар.

– Бик дөрес, балалар, әлбәттә, шулай. Мин бу тәрҗемә эшен нәкъ менә сезнең игътибарны шушы сүзләргә юнәлтәсем килгәнгә оештырдым. (слайд. Әлеге сүзләрнең дөрес язылышы һәм транскрипциясе күрсәтелә.) Бу сүзләрне язуда сез беркайчан да хата ясамассыз дип ышанам.

(Тактада: өченчекөн -[өчөнчөкөн], берсекөнгә -[бөрсөкөнгә], һәртөрле -[һәртөрлө]).

Физкультминут ясау (хәрәкәтләр белән)

«Бездә дуслык»

Бер-кулларны алга сузабыз.

Ике-кулларны күтәрәбез.

Өч-кулларны як-якка сузабыз.

Дүрт-кулларны төшерәбез.

Бер, ике, өч-бездә дуслык, бездә көч.

– Балалар, эшебезне дәреслек буенча дәвам итик. 75нче битне ачабыз, 153нче күнегүне табабыз. Барыгыз да таптыгызмы?

– Әйе.

– ...., биремен укы әле.

– Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куеп,сүзләрне укыгыз. О, ы, е хәрефләре кайсы авазларны белдерә? Үрнәктәгечә языгыз.

– Әйе....., сүзләрне укып чык әле.

– Транспорт, орчык, төлке, торт, торна, йорт, кыргыч, төтен, нокта, этажерка, элек.

– Яхшы. Алга таба.... дәвам итә.

– Тыныч, электр, сызык, сыр, очкын, эремчек, төзек, тормыш, борыч, сөтле, көчле.

– Хәзер эшне үрнәктәгечә язма рәвештә дәвам итәбез. Һәр ике төркемгә дә 3әр сүз язабыз.

– ....

– Эшләп бетердегезме?..., үзең язганнарны укып чык әле.

– ..... (мәсәлән, орчык, йорт, очкын, төтен, төзек, көчле сүзләре)

– ...., син нинди сүзләр яздың?

– ..... (мәсәлән, транспорт, торна, нокта, төлке, төтен, сөтле сүзләре)

– Молодцы! Балалар, инде дәресебез ахырына якынлаша. Һәркайсыгызның бүгенге теманы үзләштерү дәрәҗәсен

ачыклау йөзеннән, мин сезгә биремле карточкалар таратам. Биремнәр төрле вариантта төрлечә, эшегездә уңышлар телим..

Карточкалар таратыла.

Карточкаларның үрнәге.

**1 нче вариант.**

***Бирем.*** **Төшеп калган хәрефләрне куеп күчерегез, сүзнең транскрипциясен ясагыз.**

Төш...нке, к...зг..., б...р...ч, й...мр..., Б...г...лмә, Г... лй...з...м.

**2 нче вариант.**

***Бирем.*** **Сүздәге хаталарны төзәтеп языгыз.**

Чөгөндөр, тормош, көчлө, елэмтә, көнгөрә, болот.

(Биремнәр башкарылгач, укучылар дәфтәрләрен башка варианттагы партадашлары белән алыштырып, берберләренең хаталарын тикшерә, бәяли. Слайдта **дөрес җаваплар** күрсәтелә.

**1нче вариант.** Төшенке-[төшөңке], көзгө-[көзгө], борыч-[бороч], йомры –[йомро], Бөгелмә -[бөгөлмә], Гөлйөзем-[гөлйөзөм].

**2 нче вариант**. Чөгендер, тормыш, көчле, элемтә, көнгерә, болыт.

– Бик яхшы, балалар. Сез бу биремне дә бик җиңел башкарып чыктыгыз.

**VI. Өй эше бирү.**

– Укучылар, һәрвакыттагыча, мин сезгә 3 төрле өй эше тәкъдим итәм. Көндәлекләрегезгә язып куегыз.

1.72,75нче бит – кагыйдә, 154нче күнегүне эшлә.

2. Бүгенге темага кагылышлы сүзләр кергән 5 мәкаль яки табышмак табып яз.

3. Кагыйдә үзенчәлекләрен чагылдырган әкият иҗат ит.

**VII. Йомгаклау.**

– Инде дәрестә үзебез чыгарган кагыйдәне һәркем эчтән генә исенә төшерсен һәм дәреслекнең 72, 75нче битләрендә бирелгән кагыйдә белән чагыштырсын. Укучылар, без күнегүләрдән соң ясаган нәтиҗәләр дөрес булганмы? Дәреслектәге кагыйдә безнекеннән аерылмыймы?

– Юк, аерылмый. Дәреслектә дә о, ө, ы, э(е) хәрефләренең дөрес язылышы турында без әйткән кагыйдә язылган.

– Балалар, ә без нинди кагыйдә китереп чыгардык соң? Кемнең кагыйдәне әйтеп күрсәтәсе килә? (Вакытның күпме калуына карап, 2-3 укучыдан кагыйдә яңадан әйттерелә.)

– Әйе, укучылар, чыннан да, сез бүген дәрестә кагыйдәне шулкадәр дөрес һәм төгәл китереп чыгардыгыз, мин сезнең белән горурланырга хаклы.

– Инде дәрестә алган билгеләрегезне йомгаклап, гомумән дәрес өчен билге куяр вакыт җитте....,.... сезгә «5» билгесе,....,.... «4» билгесе куям. Балалар, бүгенге дәрестә сезнең эшчәнлектән мин бик канәгать калдым. Булдырдыгыз, өй эшләрен дә барыгыз да эшләп килер дип уйлыйм. Дәресебез тәмам. Сау булыгыз.

## ТЕМА: АЛМАШЛЫК
## (6 НЧЫ СЫЙНЫФ)

**Ф.Г. Абдуллина, Буа**

**Дәрес тибы:** Яңа төшенчәләр формалаштыру.

**Предметара бәйләнешләр**: Татар әдәбияты, рус теле, әйләнә-тирәне өйрәнү.

**Җиһазлау:** Н. В. Максимов, М. З. Хәмидуллина: Татар теле дәреслеге, индивидуаль биремле карточкалар.

**Максат:**

1. Яңа сүз төркеменең грамматик билгеләрен ачыклау, билгеләмәне формалаштыру.

2. Укучыларның иҗади фикерләүләренә уңай йогынты ясау, үз-үзеңә бәя бирү мөмкинлекләрен үстерүгә шартлар тудыру.

3. Туган телгә ихтирам тәрбияләүгә этәргеч ясау, аны өйрәнүгә карата җирлек тудыру.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Предмет буенча:

– нәрсә ул алмашлык икәнен белү;
– алмашлыкларга сораулар куя белү;
– тоташ сөйләмнән алмашлыкларны таба белү;
– башка сүз төркемнәреннән алмашлыкларны аера белү;
– алмашлыкның морфологик билгеләрен таный белү;
– алмашлыклы җөмләләрне җөмлә кисәкләре һәм сүз төркемнәре ягыннан тикшерә белү;

– текст белән эшли белү.

Метапредмет:

**Регулятив:**

– уку мәсьәләсен кабул итү һәм дәрес дәвамында шуның белән эшләү;

– куелган мәсьәлә нигезендә үз эшчәнлегеңне планлаштыру.

**Танып белү:**

– язма һәм телдән сөйләмдә үз фикереңне формалаштыра белү;

– тикшерүгә алынган сүз төркеме алмашлыкның билгеләрен анализлау;

– гомумиләштерү.

**Коммуникатив:**

– сөйләмнең диалогик формасы белән эш итә белү;

– хезмәттәшлектә башкаларның фикерләрен исәптә тоту һәм карашыңны яклый белү;

– бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү.

## Дәрес барышы

**I этап. Оештыру моменты** (3 мин).

**Укытучы:** Хәерле көн, укучылар! Дәресебез башында әйдәгез, бер-беребезне яңа көн белән котлыйк һәм бер-беребезгә елмаеп карыйк.

*Укучылар теләкләр телиләр:*

Яңа көн тынычлык алып килсен!

Яңа көндә бары «5»леләр генә алыйк!

Әти-әниебезгә ягымлы булыйк!

Яңа көндә барыбыз да яхшы эшләр генә кылыйк!

Дусларча без елмайыйк, хәерле көннәр телик!

Утырыгыз укучылар, дәресебезне башлыйбыз. Әйтегез әле, сезгә әлеге теләкләр ошадымы? Ни өчен?

**Көтелгән җаваплар:** Әйе, ошады.

**Укытучы:** Әйтегез әле, ә кайсы юллар сезгә аеруча ошады?

**Көтелгән җавап:** Дусларча без елмайыйк, хәерле көннәр телик!

**II этап. Белемнәрне актуальләштерү** (7мин).

**Укытучы:** Яхшы. Әйдәгез без бу җөмләне тикшереп карыйк әле. Дәфтәрегезгә җөмләне языгыз һәм җөмлә кисәкләре, сүз төркемнәре ягыннан тикшерегез.*(Укучылар җөмләне язалар һәм тикшерәләр.)*

**Укытучы:** Укучылар, әйдәгез, эшегезне тикшереп алыйк. Җөмлә кисәкләре ягыннан тикшергәндә нинди фикерегез туды?

**Көтелгән җаваплар:** Җөмләнең хәбәре – елмайыйк (фигыль). Дусларча – (рәвеш) хәл, көннәр – (исем), тәмамлык, хәерле – (сыйфат), аергыч булып килә.

**Укытучы:** Нигә фикерегез тулы түгел?

**Көтелгән җаваплар: Без** сүзенең астына сыза белмибез.

**Укытучы:** Ни өчен сыза белмисез?

**Көтелгән җавап:** Нинди сүз төркеме икәнен белмибез.

**Укытучы:** Бәлки бу фигыльдер?

**Көтелгән җавап:** Юк, бу сүзгә нишли соравын куеп булмый.

**Укытучы:** Бәлки бу сыйфаттыр?

**Көтелгән җавап:** Сыйфат та түгел, чөнки ул предметның билгесен белдерми. Аның янында ачыклаган исем юк.

**Укытучы:** Нинди нәтиҗә ясарга мөмкин?

**Көтелгән җавап:** Бу ниндидер яңа, безгә таныш булмаган сүз төркеме.

**III этап. Яңа белемнәрне ачу** (14 мин).

**Укытучы:** Безнең алда нинди проблема туды?

**Көтелгән җавап: Без** сүзенең нинди сүз төркеме булуын ачыклау.

**Укытучы:** Әйдәгез, искә төшерәбез, нәрсә ул сүз төркеме?

**Көтелгән җавап:** Бу бертөрле грамматик билгеләре булган сүзләр.

**Укытучы:** Димәк, **без** сүзенең нинди сүз төркеменә каравын белү өчен аның грамматик билгеләрен аерып карыйк.

**Укытучы:** Бу сүзне берлек санда әйтеп карагыз.

**Көтелгән җавап:** Берлек санга куеп була.

**Укытучы:** Килеш белән төрләндереп карагыз.

**Көтелгән җавап:** Төрләнә.

**Укытучы:** Тартым белән төрләндереп карагыз.

**Көтелгән җавап:** Төрләнә.

**Укытучы:** Зат – сан белән төрләндереп карагыз.

**Көтелгән җавап:** Төрләндереп була.

**Укытучы:** Нинди нәтиҗә ясарга мөмкин?

**Көтелгән җавап:** Бу сүз төркеме төрләнә.

**Укытучы:** Бу сүзгә нинди сорау куеп була?

**Көтелгән җавап:** Кем?

**Укытучы:** Бу сүз нинди җөмлә кисәге булып килгән?

**Көтелгән җавап:** Җөмләнең баш кисәге –ия.

**Укытучы:** Укучылар, без алмашлыкны өйрәнү буенча түбәндәге **модельгә** чыктык. (Тактага язу)

Сүз төркеме.

Соравы.

Төрләнә.

Ия.

**Укытучы: Без** сүзенең нинди сүз төркеме булуын белү өчен мин сезгә кроссворд тәкъдим итәм. (дәреслек, 236нчы күнегү).

**Укытучы:** Нинди сүз төркеме килеп чыкты?

**Көтелгән җавап:** Алмашлык.

**Укытучы:** Димәк, бүгенге дәресебезнең темасы нинди булыр?

**Көтелгән җавап:** Алмашлык сүз төркеме.

**Укытучы:** Дәрес алдында нинди бурычлар тора?

**Көтелгән җаваплар:** Нәрсә ул алмашлык икәнен белү. Алмашлыкларга сораулар куя белү. Алмашлыклы җөмләләрне җөмлә кисәкләре һәм сүз төркемнәре ягыннан тикшерә белү.

**IV этап. Беренчел ныгыту һәм үзтикшерү** (10 мин).

**Укытучы:** Модельгә карап, кем кагыйдәне формалаштыра ала?

**Көтелгән җавап:** Алмашлык – сүз төркеме, исем, сыйфат, сан һәм рәвешне алмаштырып килә, төрләнә, җөмләдә - ия, хәбәр, тәмамлык, хәл, аергыч була.

**Укытучы:** Хәзер мин сезгә индивидуаль карточкалар белән эш тәкъдим итәм. Бирелгән җөмләләрне языгыз һәм алмашлыкларга сорау куегыз. Аннары янығызда парыгызның эшләрен эталон буенча тикшерегез.

Мин сине көтәрмен, онытма, акыллым. (М. Хөсәенов)

Мин сезгә әйттем бит, монда ул гаепле түгел. (Ф. Хөсни)

Кем эшләми, шул ашамый. (Мәкаль)

Бәяләү критерийлары:

«5» – биремне үти алдым, барлык алмашлыкларга сорауларны дөрес куйдым.

«4» – бер-ике алмашлыкка сорауларны дөрес билгеләмәдем.

«3» – биремне иптәшем ярдәмендә генә үти алдым.

**Укытучы:** дәреслекнең 138нче битен ачып, кагыйдә белән танышыгыз. Без билгеләмәне дөрес биргәнбезме?

**Көтелгән җавап:** Әйе, төгәл.

**Укытучы:** Хәзер мин сезгә бирелгән тексттан ялгызлык исемнәрен алмашлыклар белән алыштырырга тәкъдим итәм. (Текст экранда бирелә).

Гаяз беренче тапкыр мәктәпкә барды. Гаязны баскычта Наилә Якуповна каршы алды. Наилә Якуповна Гаязның букчасын күтәрергә ярдәм итте. Гаяз рәхмәт әйтте.

**Укытучы:** Җавапларыгызның дөреслеген эталон буенча тикшерегез һәм үзбәя куегыз. (Экранда дөрес җаваплар эталоны һәм үзбәя өчен критерий бирелә).

Үзбәя кую өчен критерий:

«5» – биремне үти алдым, барлык ялгызлык исемнәрен алмашлык белән алыштырдым.

«4» – бер-ике исемгә алмашлыкны дөрес билгеләмәдем.

«3» – биремне иптәшем ярдәмендә генә үти алдым.

**V. Төркемнәрдә эш һәм эталон буенча үзтикшерү.** (5мин).

**Укытучы:** Сезгә төркемләп эш тәкъдим итәм. Һәр төркемгә ике мәкаль. Бирем: мәкальләрне язарга, алмашлыкларны табып, аларга сорау куярга, нинди җөмлә кисәге булуын билгеләргә.

1нче төркем.

Телең белән тегермән корма, аннан барыбер он чыкмас.

Бакма кешенең йөзенә, бак син әйткән сүзенә.

2нче төркем.

Иртә торгач тел сөякләрдән: «Ни хәлегез бар?» – дип сорар, ди. Сөякләр: «Син тик торсаң, безнең хәл яхшы», – дип әйттеләр, ди.

**Укытучы:** Хәзер җавапларыгызның дөреслеген эталон буенча тикшерегез һәм үзбәя куегез. (Экранда күнегүнең дөрес җавабы һәм үзбәя өчен критерий бирелә).

Үзбәя кую өчен критерий:

«5» – биремне үти алдым, барлык алмашлыкларны табып, дөрес сыйфатлама бирдем.

«4» – бер-ике алмашлыкка дөрес сыйфатлама бирмәдем.

«3» – биремне иптәшем ярдәмендә генә үти алдым.

**VI. Эшчәнлеккә рефлексия.** (3мин)

**Укытучы:** Укучылар, бүгенге дәрестә без алдыбызга нинди бурыч куйган идек?

**Көтелгән җавап:** Без сүзенең нинди сүз төркеме булуын ачыклау.

**Укытучы:** Моны ачыклау өчен без нәрсәләр эшләдек?

**Көтелгән җавап:** Җөмләне җөмлә кисәкләре һәм сүз төркемнәре ягыннан тикшердек. Кроссворд чиштек. Җөмләләрдә, мәкальләрдә бирелгән алмашлыкларга сораулар куйдык, нинди җөмлә кисәге булуларын ачыкладык.

**Укытучы:** Бүгенге дәрестә нинди билгеләмә уйлап таптыгыз?

**Көтелгән җавап:** Алмашлык – сүз төркеме, исем, сыйфат, сан һәм рәвешне алмаштырып килә, төрләнә, җөмләдә – ия, хәбәр, тәмамлык, хәл, аергыч була.

**Укытучы:** Хәзер үзегезнең эшегезгә бәя бирегез.

Универсаль критерий (экранда тәкъдим ителә):

Нәрсә эшләргә тиеш идек? Ничек эшләдек? Нинди нәтиҗә ясадык? дигән сорауларга

а) терәк конспекттан файдаланмыйча, үз –үзенә сөйли алса – «5».

ә) терәк конспекттан файдаланмыйча сөйли алса – «4».

б) терәк конспекттан, (тактадан, дәфтәрдән) файдаланып сөйләп бирә алса – «3».

(Укытучы критерий бирә. Шул нигездә балалар үз – үзләренә билге куялар, ягъни үз эшчәнлекләренең кайсы критерийгә туры килүен билгелиләр).

**VII. Өйгә эш бирү** (3 мин).

**Укытучы.** Сезгә 3 вариантта өй эше тәкъдим итәм. Берсен сайлап эшләгез:

237нче күнегү, 138нче бит: алмашлыкларны табарга, аларга сыйфатлама бирергә.

239нчы күнегү, тәрҗемә итәргә, алмашлыкларның астына сызарга.

Бирелгән алмашлыкларны кулланып, шигырь язып карагыз: Мин, монда, ниндидер, ничә.

# ТЕМА: ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ДӘРӘҖӘСЕ ЯГЫННАН СҮЗЛЕК СОСТАВЫ. ИСКЕРГӘН СҮЗЛӘР (5 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**Л.Ә. Хәертдинова, Яр Чаллы**

**Максат:** 1. Компьютер технологияләрен кулланып, укучыларга татар теленең сүзлек составында искергән сүзләр булуын, аларның тарихи сүзләргә һәм архаизмнарга бүленүе турында мәгълүмат бирү.

2.Укучыларда аңлатмалы сүзлекләр белән мөстәкыйль эшләү күнекмәләре формалаштыру.

3. Укучыларда Г.Тукай иҗатын өйрәнүгә кызыксыну уяту, шигырьләре аша укуга, хезмәткә, туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Дәреслек, аңлатмалы сүзлекләр, компьютер, проектор.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру.**

1. а) Психологик уңай халәт тудыру.

**Укытучы:** Хәерле көн,укучылар! Кәефләрегез ничек? (Кояшлы көн кебек, Ана телен, Тукай телен өйрәнергә дип килдек.)

Хәерле көн телик таңнар саен,
Аяз күкләр телик җиребезгә.
Кояшлы көн телик һәр кешегә,

Һәм иминлек телик җиребезгә,

Хәерле көн телик барчабызга,

Хәерле көн телик үзебезгә.

Барчабызга да хәерле көн теләп, дәресебезне башлыйбыз.

ә) Без узган дәрестә нинди тема өстендә эшләдек? (Модель әйтелә)

**2. Өй эшен тикшерү.**

Ярым иҗади һәм иҗади өй эшен тыңлау.

**3. Мөстәкыйль эш башкару.** Бирем: һәр аңлатманың янына атамасын язарга.

1.Сөйләм авазларын өйрәнә торган фән – **фонетика.** 2. Мәгънәләре буенча охшаш сүзләр – **синонимнар.** 3. Бер иҗектә янәшә килгән ике сузык – **дифтонг.** 4. Кабул ителгән билгеле бер тәртип буенча урнашкан хәрефләр – **алфавит**. 5. Билгеле бер һөнәр ияләре генә кулланган сүзләр – **профессиональ сүзләр**. 6. Татар теленә башка телләрдән кергән сүзләр – **алынмалар.**

(Биремне экранга чыгару)

(Үзбәя)

*Хатасыз –»5»ле. 1 хата – «4»ле. 2-3 хата –»3»ле. 4 һәм артыграк хата – «2»ле.*

**II. Яңа белемнәрне үзләштерү.**

Экранда Г. Тукайның «Эшкә өндәү» шигыре.

Укытучы шигырьне сәнгатьле итеп укый.


**Укытучы:**

– Г. Тукайның тагын нинди әсәрләрен беләсез?

– Бу шигырь безне нәрсәгә өйрәтә? (Эш сөючән, тырыш булырга өйрәтә.)

– Укучылар, әлеге шигырьдә кайсы сүзләрне аңлау сезгә авыррак тоелды? (ушбу, җиһан, иҗтиһад, олугъ, мөкаддәс)

– Сез ничек уйлыйсыз, бу нинди сүзләр? (иске сүзләр)
– Бу сүзләрнең мәгънәләрен без каян белә алабыз? (Өлкәннәрдән сорый алабыз, аңлатмалы сүзлектән таба алабыз.)
– Ягез әле, аңлатмалы сүзлекләрдән әлеге сүзләрнең мәгънәләрен эзләп карыйк.
– ушбу – бу, шушы.
– җиһан –дөнья
– иҗтиһад – тырышлык
– олугъ – зур, бөек
– мөкаддәс – изге
– Укучылар, әлеге сүзләр искергән сүзләр дип йөртелә. Аерым сүзләр, искереп, кулланыштан төшеп калалар, яңа сүзләр барлыкка килә. Шул рәвешле тел гел үзгәреп тора.
(Үзбәя)
2**. Модельләштерү.**




(Үзбәя). (Дәфтәрләргә тема языла)
**3. Тарихи сүзләргә һәм архаизмнарга бүлеп язарга:**
Мәсәлән: Архаизмнар: Тарихи сүзләр:

аршын  өяз
инсан мәхәллә
арык  сөңге
вә  ядрә
(Үзбәя)
(Ял минуты)

**III. Алган белемнәрне ныгыту.**

1. 214нче күнегү. Биремне эшләргә. Гыйлем – белем, углым – улым, ошбу – шушы, мөгаллим – укытучы, гакыл – акыл, берлән – белән, өмит – өмет, мәркәз – башкала, шәкерт – укучы.

(Үзбәя)

2. Г.Тукай шигырьләреннән алынган өзекләрне күчереп языгыз, искергән сүзләрнең асларына сызыгыз һәм төрен билгеләгез.

1. Каты йоклап Ай бишектә мәгърибкәчә,
Торып чыга, көлеп, җиргә нурын чәчә;
Кояш һәм Ай – ике туган агай-эне –
Менә шулай дуслык берлән нәүбәтләшә.
2. Эченнән сөйләде шунда Күгәрчен:
«Бу Лачын нинди көчле кош, күрәмсең?
Вә ләкин мин ризамын язмышымнан,
Ходай кылган мине көчсез колыннан:
Зәгыйфь, корбан буллу артык, Ходаем,
Булудан андый көчле һәм дә залим?»
(Үзбәя)

**III. Йомгаклау, бәяләү.**

1. – Дәрестә нинди теманы тикшердек?

– Телнең сүзлек составы ни өчен үзгәреп тора? (Вакыт узган саен кайбер сүзләр искерә, кайберләре яңа мәгънә белдерә башлый, яңа сүзләр ясала).

2. Дәрескә гомуми бәя кую.

3. Өй эше: 1. 215 нче күнегү. 2. Әдәби әсәрләрдән искергән сүзләр кергән 5 җөмлә табып язарга.

## ТЕМА: АНЫКЛАГЫЧ ЯНЫНДА ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕ (7 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**Л.Н.Муллагилова, Чистай районы**

**Максат:** Аныклагыч янында тыныш билгеләрен танып белергә өйрәтү; 7 сыйныфта үткән аныклагыч темасы буенча белемнәрне гомумиләштереп кабатлау;

Сөйләмдә куллану күнекмәләрен камилләштерү; үз эшеңә, иптәшләреңнең хезмәтенә бәя биреп, нәтиҗә ясап, фикереңне дәлилле белү күнекмәләрен үстерү; укучыларда туган якка карата патриотик хис тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Тестлар, җөмләләр язылган карточкалар, таблица, картиналар, интерактив такта.

### Дәрес барышы

**I. Актуальләштерү.**

**7 сыйныфта үткәннәрне кабатлау.** Укытучы интерактив тактада язылган җөмләләрне укый. Укучылар 7 сыйныфта алган белемнәрен искә төшереп, укытучы ярдәме белән аерымланган аныклагычларны танып беләләр, аларның алдагы сүзне ачыклап килүенә, алар янында тыныш билгесенә игътибар итәләр һәм нәтиҗә ясыйлар.

**II. Аныклагычлар һәм алар янында тыныш билгеләре темасын аңлату өстендә эш.**

Таблица белән эш. Теманы искә төшерү, аңлату.

Укучылар белән таблица ярдәмендә аерымланган аныклагычлар янында тыныш билгеләрен искә төшерү. Икенче, өченче графалар буш бирелә. Шуларны тутырып нәтиҗә ясарга. Интерактив тактада эшләргә.

| **Аерымланган аныклагычлар янында тыныш билгеләре** | | |
|---|---|---|
| Мисаллар | Аныклагыч | Аңлатма |
| 1. Без, **биш бала**, туган йортыбызга җыелдык.<br>Өч сугышчы еракка, **дошман тылына,** разведкага китте. | биш бала<br>дошман тылына | Зат алмашлыгы һәм рәвеш белән белдерелгән кисәкне аныклап килгәндә, өтер куела. |
| 2.Без, сөйләүчеләрне, **аеруча авылдашларыбызны,** игътибар белән тыңладык. | аеруча авылдашларыбызны | **Хәтта, ягъни, мәсәлән, бигрәк тә, аеруча** кебек сүзләр белән килгән аныклагычлар янында өтер куела. |
| 3.Беренче ике урынны иске чемпионнар – **Сабиров һәм Васильевлар** алды. | Сабиров һәм Васильевлар | Исем белән белдерелгән аныкла478мыштан соң **ягъни** сүзе төшеп калса, сызык куела. |
| 4.Якын дуслар – **Айзилә, Айгөл, Гөлназ** –шатланып, гөрләшеп бакчада эшлиләр. | Айзилә, Айгөл, Гөлназ | Аныклагычлар тиңдәшләнеп килсәләр яки тестны укырга һәм аңларга кыенлык туса, ике яктан сызык белән аерыла. |
| 5. Кама суының йөзе яктырды: **көзге кебек булды.** | көзге кебек булды | Фигыль белән белдерелгән хәбәрне ачыклаучы аныклагыч алдыннан **ягъни** сүзе булмаса, ике нокта куела. |

| | | |
|---|---|---|
| 6. Гаяз Исхакый Чистай районы Яуширмә авылында **(элекке Чистай өязендә)** туган. | элекке Чистай өязендә | Аныкламышның башка атамасы булган аныклагычлар җәя эченә алына. |

***Нәтиҗә.*** Ияртүче кисәктән соң килеп, аның мәгънәсенә өстәмә төгәллек, аныклык кертә торган сүзләр **аныклагыч** дип аталалар.

**III. Белемнәрне ныгыту, күнекмәләр булдыру.**

**1. Китап белән эш.** Китаптан билгеләмәне уку. Күнегү өстендә эш.

**2. Карточкалар белән эшләү.** *Тиешле тыныш билгеләрен куярга,* **интерактив тактадан тыныш билгеләрнең куелышын дөресләргә,** *ни өчен бу тыныш билгесен куйганлыкка аңлатма бирергә.*

Кәҗә рәхмәт укый: **сакалын селкетә**. (Г. Тукай).

Аныклагыч фигыль белән белдерелгән кисәкне аныклап килсә, аныклагычлы кисәк алдыннан ике нокта куела.

Аның сөйгән егете – **мединститут студенты** – фронтта үлгән. (М. Мәһдиев).

Аныклагыч та, аныкламыш та исем белән белдерелеп, икесенең дә мәгънә күләме бердәй булса, аныкламыш ике яктан да сызык белән аерыла.

Без, **малайлар,** сыйныф бүлмәсендә калдык. (М. Мәһдиев).

Зат алмашлыгын аныклап килгән аныклагычлар ике яктан да өтер белән аерылалар.

Китап чәчәк кебек: «иркәләгәнне», «назлаганны», **ягъни укыганны** ярата. (М. Госманов).

Аныклаучы теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр аныклanып килгәндә, алар алдыннан өтер куела.

**3. Бирелгән рәсемнәр буенча кечкенә күләмле бәйләнешле текст төзергә.**

**Рәсем:** «Казан Кремле», «Сөембикә манарасы».

**4. Тест белән эшләү.** Укучыларга тест бирелә, дөрес җавапларны табып тамгаларга.

Интерактив тактада җавапларны тикшерү. Укучылар бер – берсенең җавапларын тикшереп, карандаш белән иптәшләре ничә хата җибәргәнне билгели.

**IV. Дәрестә үтелгәннәргә нәтиҗә ясау. Йомгаклау. Өй эше бирү.** Матур әдәбияттан аныклагычның һәр очрагына 1 җөмлә табып язарга.

## ТЕМА: СҮЗЛӘРНЕ КУШУ ЫСУЛЫ. КУШМА, ПАРЛЫ, ТЕЗМӘ СҮЗЛӘР (5 НЧЕ СЫЙНЫФ).

**А.Ә. Хайбрахманова, Алабуга**

**Максат:**

1. Сүзләрне кушу ысулы белән кушма,парлы,тезмә сүзләр ясалу ысулларын, лексик мәгънә мөнәсәбәтләрен аңлату.

2.Укучыларның белемнәрне тирәнәйтү, иҗади һәм эзлекле фикер йөртү сәләтен үстерү.

3. Туган телгә мәхәббәт, татар халкының үткәненә кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Дәреслек – Ф.Ф. Харисов,Ч.М. Харисова «Татар теле» 5, компьютер, экран, биремнәр язылган карточкалар.

**Дәреснең төре:** катнаш дәрес.

**Укыту алымнары:** таблица төзү,карточкалар белән эшләү, тема турында фикер алышу, сүзләр белән җөмләләр төзетү.

Эш төркемнәрдә алып барыла.

### Дәрес барышы

**I. Уңай психологик халәт булдыру.**

*Укытучы*. Исәнмесез,укучылар. Бер-беребезгә хәерле көн теләп, дәресебезне башлап җибәрик. Барыгызның да дөрес җавап бирүегезне һәм актив эшләвегезне телим.

**II. Актуальләштерү.**

*Укытучы*. Без сүз ясалышы ысулларын өйрәнәбез. Узган дәрестә без яңа сүзләр ясауның нинди ысулын өйрәндек?

*Укучы*. Сүзләргә сүз ясагыч кушымчалар өстәп, яңа сүзләр ясарга өйрәндек.

*Укытучы*. Укучылар, бүгенге дәрестә дә сүз ясалу ысулларын өйрәнүне дәвам итәрбез. Хәзер игътибар белән тактада бирелгән сүзләргә карагыз. Сүзләр төзелешләре ягыннан нинди? Таблицаны тутырыгыз.

Көньяк, һәлак булу, аккош, аш-су, үги ана яфрагы, унике, көне-төне, күз салу, очсыз-кырыйсыз, юлбашчы, дус-иш, егерме ике, алмаш-тилмәш, күзаллау, бүләк итү.

*Көтелгән җавап*

| | | |
|---|---|---|
| аккош | дус-иш | бүләк итү |
| унике | аш-су | һәлак булу |
| күзаллау | көне-төне | күз салу |
| юлбашчы | очсыз-кырыйсыз | егерме ике |
| көньяк | алмаш-тилмәш | үги ана яфрагы |

*Укытучы*. Мондый сүзләр сүз ясалышы ысулларының кайсына карый? *Укучы*. Таблицаның беренче баганасындагы сүзләр – кушма сүзләр, икенчесендә – парлы сүзләр һәм өченчесендә – тезмә сүзләр. Алар сүзләрне кушу ысулы белән ясалган.

*Укытучы*. Әйтелгәннәрдән чыгып, дәрескә уку максаты куегыз.

*Укучы*. Без бүген сүзләрне кушу ярдәмендә яңа сүзләр ясалуы турында сөйләшербез.

**III. Яңа белем һәм күнекмәләр формалаштыру.**

*Укытучы*. Дөрес.Сүзләрне кушу ысулы белән кушма, парлы, тезмә сүзләр ясалу үзенчәлекләре турында сөйләшербез.Татар теленең сүз байлыгы белән танышыр-

быз. Хәзер дәфтәрләргә бүгенге числоны, теманы язып куйыйк. Аннары дәреслекне ачып, бирелгән кагыйдәләр белән танышырбыз.

*Укучы* (укый). Сүзләрне кушу ысулы белән яңа сүзләр ике яки берничә сүзне кушып,теркәп яки тезеп ясалалар. Төзелешләреннән чыгып, әлеге ысул белән ясалган сүзләрне кушма,парлы,тезмә сүзләр дип атыйлар.

*Укытучы.* Хәзер дәреслектә бирелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, нәтиҗәләр ясагыз һәм,бергәләп,сүзләрне кушу ысулының моделен төзегез.

Сүзләрне кушу юлы белән ясала

| Кушма сүзләр | Парлы сүзләр | Тезмә сүзләр |
|---|---|---|
| *- ике сүз, кушылып, бер мәгънә белдерә*<br>*- кушымчалар да өстәлә ала*<br>*- кушылып языла* | *- антоним, синоним, авазда́ш сүзләрне парлап,сүзләрне кабатлап ясала*<br>*- сызыкча аша языла* | *- ике яки берничә сүздән тезелеп ясала*<br>*- бер төшенчәне белдерә*<br>*- аерым язылалар* |

*Көтелгән җавап:*

**IV. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.**

*Укытучы.*Хәзер,укучылар,бирелгән парлы сүзләр белән эшләрбез. Алар нинди мәгънә мөнәсәбәтендә торган сүзләрдән ясалган? Сүзләрне 4 төркемгә бүлеп языгыз.

Уен-көлке, кием-салым, биек-биек, сирәк-мирәк, гореф-гадәт, ут- су, йорт-җир, исәнлек-саулык, эреле-ваклы, аң-белем, китап-дәфтәр, караңгылы-яктылы, зур-зур, ара-тирә, көчкә-көчкә, матур-матур, берән-сәрән, көне-төне, тиз-тиз,аз-маз, анда-санда, ишекле-түрле, бала-чага.

*Көтелгән җавап:*

| Антонимнары парлап ясалган сүзләр | Синонимнары парлап ясалган сүзләр | Авздаш сүзләрне парлап ясалган сүзләр | Сүзләрне кабатлап ясалган сүзләр |
|---|---|---|---|
| Кием-салым | Уен-көлке | Сирәк-мирәк | Биек-биек |
| Ут-су | Гореф-гадәт | Берән-сәрән | Зур-зур |
| Эреле-ваклы | Йорт-җир | Аз-маз | Көчкә-көчкә |
| Караңгылы-яктылы | Исәнлек-саулык | Анда-санда | Матур-матур |
| Көне-төне | Аң-белем | Бала-чага | Тиз-тиз |
| Ишекле-түрле | Ара-тирә | | |
| Китап-дәфтәр | | | |

*Укытучы.* Димәк, нинди нәтиҗә ясый алабыз? Парлы сүзләр ничек ясала икән?

*Укучы.* Парлы сүзләр бер-берсенә я капма-каршы мәгънәле, я мәгънәдәш, я аваздаш булган ике сүзне теркәү яки сүзне кабатлау юлы белән ясалалар. (үзбәя)

*Укытучы.*Бирелгән сүзләрне укыгыз. Алар ничә компоненттан тора? Бу сүзләр турында нәрсә әйтә аласыз ? Һәр компоненты да мәгънә белдерәме?

| | | |
|---|---|---|
| ару-талу | ботак-чатак | әлҗе-мөлҗе |
| йөз-кыяфәт | нәсел-нәсәбе | ырык-шырык |
| чиле-пешле | шөгыль-мөгыль | әпен-төпен |
| бөгелү-сыгылу | яшь-җилбәзәк | ыбыр-чыбыр |
| буй-сыны | сирәк-мирәк | эңгер-меңгер |
| аң-белем | ертык-портык | |

*Укучы.* Бу сүзләр-парлы сүзләр. Беренче баганадагы сүзләрнең ике компоненты да мәгънә белдерә, икенче баганадагы сүзләрнең бер компоненты гына мәгънә белдерә, ә өченче баганадагы сүзләрнең берсе дә мәгънә белдерми.

*Укытучы*. Парлы сүзләрнең барлыкка килүенең тарихы да кызыклы.Төрки халыклар элек-электән аралашып

яшәгәннәр,шуңа күрә кайбер парлы сүзләрнең ике компоненты да нигездә бер үк төшенчәне белдерә. Мәсәлән,савыт-саба, ир-ат, бала-чага, мал-туар, азык-төлек, кыз-кыркын, кош-корт, бала-чага.Әмма аларның беренче компонентлары татар әдәби телендә генә кулланылалар, икенче компонентлары исә аерым диалектларда, ә ат, туар, төлек сүзләре башка төрки телләрдә дә очрый.

Кыз-кыркын (*кыркын* борынгы төрки телдә *хезмәтче кыз* дигәнне аңлата)

Ыбыр-чыбыр (кыргызча ыбыр-сы «кече булу»)

Алам-салам (*алама*- начар дигән сүз)

Бала-чага (төрекмәннәр баланы *чага* диләр)

Укучылар*, ир-ат* сүзенә игътибар итегез әле. Бу сүз бик матур яңгырый бит, килешәсезме? Тарихыбызны искә төшерик. Татарның гомере ат өстендә үткән: атка менеп яуга чыккан, ат җигеп иген иккән, кирәк-ярак ташыган, ерак юлга чыккан. Юкка гына, ат – ир кешенең юлдашы да, моңдашы да, димәгәннәр. Яраткан шагыйребез Роберт Миңнуллинның «Атларым – канатларым» шигырендә мондый юллар бар:

Ир-атлар туа иярдә,
Ир канаты ат кына.
Очырта да алып китә,
Тезгененнән тарт кына!

*Укытучы.* Мин сезгә тагын бер бирем тәкъдим итәм. Бер укучы такта янында эшләр. Бирелгән мисалларны укыгыз,тезмә сүзләрне аерып языгыз. 3 сүз белән җөмлә төзегез.

Кычыткан чыпчыгы, яхшы укучы, акыллы бала,сукыр кычыткан, каен гөмбәсе, сабыр кеше, ямьле вакыт, бал корты, кышкы көн, киң дала, хәбәр итү, кәҗә сакалы, чүп үләне.

*Көтелгән җавап:*

Кычыткан чыпчыгы,сукыр кычыткан, каен гөмбәсе, бал корты, хәбәр итү, кәҗә сакалы, чүп үләне.

*Укытучы.* Биремне дөрес эшләгәнсез. Хәзер нәтиҗә ясыйбыз. Бу сүзләр ничек ясалган?

*Укучы.* Тезмә сүзләр ике яки берничә сүздән тезелеп ясалалар. Бер төшенчәне белдерәләр һәм бер сорауга җавап бирәләр. (үзбәя)

Укытучы. Бу кушма сүзләр нинди сүзтезмәләр нигезендә барлыкка килгәннәр? Кушма сүзләрне чыганак сүзтезмәләре белән парлап күчереп языгыз. Чиратлап такта янына чыгып эшләрбез.

Аръяк, кулъяулык, алмагач, бүген, быел, каражимеш.

Җаваплар: аргы як, кул яулыгы, алма агачы, бу көн, бу ел, кара төстәге җимеш.

*Укытучы.* Кушма сүзләрнең нинди үзенчәлекләре бар? Нәтиҗә ясыйк.

*Укучы.* Кушма сүзләр ике сүзнең кушылып бер мәгънә белдерә башлавы нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр.

*Укытучы.* Хәзер төркемнәрдә эшне дәвам итәбез. Һәр партага кушма сүзләр язылган карточкалар таратам. Түбәндәге бирем безгә сүз төркемнәрен искә төшерергә ярдәм итәр. Бирелгән кушма сүзләр нинди сүз төркемнәре кушылып ясалган? Бирем аңлашылса, эшли башларга мөмкин.

Өчпочмак, Гөлүсә, Айтуган озынборын, эшкуар, тиктормас, бишьеллык, үзбушаткыч, ункөнлек, көнкүреш.

Көтелгән җавап: өчпочмак- сан + исем, Гөлүсә-исем + фигыль, Айтуган-исем + фигыль, озынборын-сыйфат+исем, эшкуар-исем+фигыль,тиктормас-рәвеш +фигыль, бишеллык-сан+ исем, үзбушаткыч-алмашлык+ фигыль, ункөнлек- сан+ исем, көнкүреш-исем+ фигыль.

*Укытучы*. Бу бирем безгә сүз төркемнәрен искә төшерергә ярдәм итте. Шулай ук нәтиҗә ясыйбыз. (үзбәя)

*Укучы.* Кушма сүзләр төрле сүз төркемнәреннән ясалганнар.

*Укытучы.* Эшебезне дәвам итәбез. Бу сүзләрдә хәрефләр төшеп калган икән, укучылар. Кирәкле хәрефләрне куеп языгыз.

Бер.юлы, буар.елан, биш.еллык, аш.яулык, ар.як, мең. яфрак, бер.яклы, йөз.яшәр.

Җаваплар: Берьюлы, буаръелан, бишьеллык, ашъяулык, аръяк, меңь-яфрак, берьяклы, йөзьяшәр.

Укытучы. Укучылар, бу биремне үтәп без нәрсәгә ирештек?

Укучы. Дөрес язу кагыйдәләрен искә төшердек

Укытучы. Димәк, нинди нәтиҗә ясыйбыз?

Укучы. Ъ,ь хәрефләре,е,я,ю алдыннан килгәндә, аеру билгесе вазифасын үтиләр. Калын иҗектән соң -ъ, нечкә иҗектән соң ь хәрефе языла.(үзбәя)

**V. Йомгаклау.**

*Укытучы.* Ә хәзер дәресебезгә гомуми йомгак ясыйк.Бүген нинди сүзләр белән таныштык? Алар нинди ысул белән ясалган? Дәрестә нәрсәгә өйрәндегез? Туган телебезнең сүз байлыгы турында нәрсәләр әйтә аласыз?

*Укучы*. Парлы, кушма,тезмә сүзләрнең белән эшләдек. Сүзләрне дөрес язарга өйрәндек.Сүзләрне кушу ысулы белән яңа сүзләр ясалуын белдек.Туган телебездә кушма, парлы,тезмә сүзләр күп.

*Укытучы.* Татар теле-халкыбызның зур байлыгы, иң кадерле рухи хәзинәсе. Халкыбыз үзенең телен саклап, мең еллар буена үстереп килгән, аны баеткан, матурлаган. Сез

дә, укучылар, туган телебезне яхшы итеп өйрәнегез, аны саклагыз.

*Укучыларның белемнәрен бәяләү. Үзбәя.*

*Өйгә эш*:

1) Вакыт, баш, көн, бер, яулык сүзләре катнашкан кушма, парлы, тезмә сүзләр ясап язарга.

2) Әдәби әсәрләрдән кушма, парлы, тезмә сүзләр кергән 5 җөмлә күчереп язарга.

# ТЕМА: Ә. ЕНИКИНЕҢ «ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ» ӘСӘРЕН ӨЙРӘНҮ (11 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**А.Г. Ризванова, Яр Чаллы**

**Максат:** Укучыларның Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәре буенча алган белемнәрен системага салу; сөйләм телен үстерү; укучыларда әсәрне анализлау, фикерләү күнекмәләрен камилләштерү; Акъәби образына таянып, балаларның ата-аналары алдындагы бурычлары турында фикер алышу; укучыларда туган җиребезне, әниләребезне, туган телебезне ярату һәм халкыбызның гореф-гадәтләренә хөрмәт хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Язучының портреты, эти-әниләрне хөрмәтләү турындагы татар халык мәкальләре язылган плакатлар, төсле рәсемнәр, магнитофон

**Дәрес өчен материал:** 1. Әдәбият: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 7 нче с-фы өчен дәреслек-хрестоматия /Ф.М. Хатипов, Ф.Г. Галиуллин. – Казан: Мәгариф, 2006.

2. Д.Ф.Заһидуллина.Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2000.

3. А.Г. Яхин. Әдәбият: Татар урта гомуми белем мәк. 11 нче с-фы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2003.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру.**

*Дәрес оештыру моментыннан һәм укытучының кереш сүзеннән башлана.*

Укытучы. Шушы көннәрдә илебездә зур бәйрәм - Әниләр бәйрәме гөрләп узды.Бүгенге дәресебез дә безнең сөекле әниләребезгә багышлана, шуңа күрә мин сезне шәһәребездә яшәп иҗат итүче шагыйрә Заһирә Гомәрованың аналар турында шигыре белән таныштырырга телим.

Аналарга дан җырлыйк без,
Аналарны гел зурлыйк без,
Туу белән алып кулга,
Һәммәбезне туры юлга
Ул чыгарды.
Ана мәхәббәте көчен
Тулы итеп белү өчен
Үлчәү бармы?
Беркайчан да ялгызлыкта,
Ятимлектә калдырмыйк без
Сөекле аналарны !

Укучылар, тормышыбызда ата-аналарга карата шәфкатьсезлек, мәрхәмәтсезлек көннән-көн арта бара. Илебездә картлар йортлары күбәя. Нигә шулай соң? Бу сорауга җавапны,бәлки, Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәре буенча фикер алышкач, табарбыз. Без сезнең белән бу әсәрне укып чыктык, сез алдан әзерләнгән күп санлы сорауларга өйдә җавап эзләргә тиеш идегез. Сорауларга җавап биргәндә, актив катнашырсыз дип ышанам.

**II. Төп өлеш. Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрен өйрәнү.**

*Дәрестә түбәндәге сораулар тикшерелә:*

– Әсәрнең төп геройлары кемнәр?

Укучылар геройларны санап китәләр.

– Сезгә аеруча кемнәр ошады? Ни өчен?

Укучылар үзләренә ошаган геройлары турында фикер алышалар.

– Акъәби һәм аның ире балаларын ничек тәрбияләп үстергәннәр?

**Көтелгән җавап**.

Яхшы, башта алар Юлкотлыда укыганнар, аннан соң күрше авыл мәктәбендә, әтиләре күрше авылга атка утыртып аларны укырга йөрткән. Урта белем алгач, алар шәһәргә киткәннәр, анда институтларда укып, югары белем алганнар, зур кешеләр булганнар. Олы улы Суфиян отставкадагы полковник, кызы Гөлбикә институтта укыта, бер кызы табиб, кече улы инеженер.

– Әлбәттә, Акъәби балалары белән горурлана, ләкин гомер үткән саен боега, моның сәбәбе нәрсәдә?

**Көтелгән җавап**.

Еллар үткән, әбинең карты үлеп китә, балалары төрлесе-төрле якка таралышалар. Акъәби берьялгызы торып кала, үзенчә көн күрә. Һәр көнне балаларының кайтуын көтә, сагына. Аларның авылдан чыгып китүләренә, туган туфрактан читләшүләренә борчылып яши. Өлкән улы Суфиян рус кызына өйләнә, Акъәбинең күңеле моңа бик әрни, чөнки оныклары белән белән аралаша алмый, улы балаларына әбиләре белән сөйләшә алырлык башкортча берничә дистә сүз дә өйрәтми!

Әбинең сәламәтлеге начарлангач, аны кемнәр карый?

**Көтелгән җавап.**

Күршеләре аны ташламыйлар, алар кереп, аны ашаталар, кош-кортларын карыйлар, өен җылыталар. Авыл хал-

кы әбине бик ярата, шуңа күрә әбигә соңгы кадер-хөрмәтен күрсәтергә тырыша.

Менә Акъәби шәһәрдә кызында яши башлый, аның тормышы ничек үзгәрә?

**Көтелгән җавап**.

Әлбәттә, балалары аның хәлен яхшырту өчен барысын да эшлиләр, яхшы белгеч-врачлар чакырталар, аерым бүлмә бирәләр, урын-җире дә чиста, ашарына да әзер. Ләкин аның картлык көннәре бөтенләй башка төрле юнәлештә ага башлый...Шаулы шәһәрнең тиз агышында кайнаган балалары һәм оныклары үлем түшәгендә яткан карчыкның мөһим фикерләрен, уй-хисләрен, кичерешләрен, изге теләкләрен, әйткән һәм әйтелмәгән васыятен аңламыйлар.

Ни өчен?

**Көтелгән җавап**.

Акъәби үзенең васыятен әйтә алмыйча газаплана, чөнки балаларының әниләрен тыңларга вакытлары юк. Алар эштә. Ял көннәрендә еш кына аларга кунаклар киләләр, ялгыз бүлмәдә үлем түшәгендә яткан карчыкка кунакларның исе дә китми. Сирәк кенә кунакка килгән шагыйрь аның янына керә, хәлен белешә, үзенең әнисе булмаганга моңая: «Әни яшь балаларга гына түгел, минем кебек сакаллы кешеләргә дә кирәк,» – ди. Сирәк булса да оныклары да керәләр, әби аларга җанын борчыган сүзләрне әйтергә тели, ләкин, русча белмәгәнлектән, бер сүз дә әйтә алмый. Шулай итеп, васыятьне тыңламауның тышкы сәбәпләре: кызы Гөлбикә әсәенең үлеме турында уйларга курка, кияве үзен борчырга теләми, килен һәм аның балалары башкортча белмиләр, улы Суфиянны хәрби хезмәт үзгәрткән.

Бу күренешнең тамыры шушы нәрсәләрдә генәме?

**Көтелгән җавап.**

Акъәбинең балалары туган җирләрен ташлап шәһәргә китәләр, руслашалар, мөселман диненнән аерылалар, авылга кайтып йөрмәгәч, яхшы күңелле авыл халкы белән дә аралашмыйлар, туган телләренә хөрмәт белән карамыйлар, милли гореф-гадәтләрдән читләшәләр. Әбине өйләренә алып кайту да алар өчен мәшәкать, әмма бу мәшәкатькә алар бурыч үтәү өчен генә риза булалар. Алар тарафыннан эшләнгән бу яхшылыкны мәҗбүри эшләнгән яхшылык дип атарга мөмкин. Мәҗбүри яратып булмаган кебек, мәҗбүри рәвештә эшләнгән яхшылыкның начарлык икәнлеген әби аңлый, шуңа күрә борчыла. Моннан тыш, Акъәбинең һәр милләтнең талантын, матурлыкны аңлый белүен, яшәү рәвешен күрсәткән, ата-бабаларының төсе итеп саклап килгән ядкарьләре бар. Әби бу әйберләрне балаларына төсе итеп калдырырга тели. Ләкин балалары Акъәбинең соңгы теләген тыңларга вакыт таба алмыйлар, кирәксенмиләр дә. Хәтта ананың әйтелгән соңгы васыятен – аны үзебезчә җирләүне дә оештыра алмыйлар. Белгәнебезчә, Акъәбинең балалары халык тарафыннан тупланган рухи байлыктан йөз чөерәләр, ә бу өлкән буын белән яшь буын арсында упкын барлыкка китерә, буыннар арасындагы рухи бәйләнешләр өзелә. Моны Акъәбинең васыяте балаларына барып җитмәүдә күрәбез.

– Ә менә өлкән буын вәкиле Миңлебай картның тормышы белән Акъәби тормышы арасында нинди аерма бар?

**Көтелгән җавап.**

Без әсәрдә яшь буынның төрле вәкилләрен күрәбез. Миңлебай картның балалары туган җирләрендә ата-аналарын хөрмәт итеп яшиләр, гореф-гадәтләрне саклап, халыкның рухи байлыгын үзләреннән соң килгән яшь буынга кадер-хөрмәт белән тапшырырга җыеналар!

Әсәрдә Акъәбине аңлаучы, аны үз анасы кебек якын итүче тагын бер кеше бар. Кем ул?

**Көтелгән җавап.**

Балаларына кунакка килүчеләр арасыда шактый күренекле бер шагыйрь була. Ул килгән саен әбинең хәлен белешә, бик якын итеп сөйләшә. Акъәби аңа үзенең уй-хисләрен сөйли, күңелен бушата. Шагыйрь дә аны үз әнисе кебек ярата, аның күңел кичерешләрен аңлый.

– Талантлы язучы Ә.Еники бу әсәрендә әйбер-образларны әсәрнең үзәгенә куя, символик образ дәрәҗәсенә күтәрә, безне уйландырырга мәҗбүр итә. Акъәби үлгәннән соң, аның улы, буыннарга тапшыру өчен, бүре аулаганда кулланыла торган камчыны сайлап ала. Ни өчен? Камчы символик образ буларак безгә нәрсәләр аңлата соң?

**Көтелгән җавап**.

Акъәби, уйланып ятканда, матур әйберләр, бизәнү әйберләрен васыять итәргә теләп, камчыны хәтеренә дә алмый. Яшь буын исә явызлык, усаллык, мәрхәмәтсезлек символын сайлап ала, матурлыктан баш тарта, бу истәлекле әйберләрне театрда яки музейларда гына карый торган экспонатка әйләндерә. Камчы бит ул – яра сала торган корал да. Моның белән язучы үзенең әсәрендә күтәрелгән проблемаларның актуаль булуын искәртә сыман, безне дә уйландыра, гомумкешелек сыйфатларны югалтмаска өнди.

Әсәр табигать күренеше белән башлана, табигать күренеше белән бетә. Ни өчен?

**Көтелгән җавап**.

Автор хикәянең башында Акъәбине гомерен үткәргән дала белән хушлаштыра, карчыкны табигатьнең бер кисәге, бер баласы итеп күрсәтә. Башкорт даласын күрсәтү аша язучы безне тирән мәгънәгә – хикәянең өлкән буын кешеләре, аларның туган җиргә карашы мәьсәләсенә кагылачыгына юнәлтеп куя.

– Күренекле язучы Ә. Еники әсәрдә ялгызлык исемнәренә дә олы мәгънә салган: Юлкотлы, Акъәби... Бу исемнәрнең мәгънәләрен ничек аңладыгыз?

Авылның исеме Юлкотлы, ягъни бәхетле юлга, тормышка илтүче. Чынлап та, бу авылда әби бәхетле яшәгән, чын исеме Акбикә була. Ул гомере буена ак, пакь күңелле булган. Шуңа күрә авыл халкы аны Аккилен, Акҗиңгә, ә картайгач Акъәби дип йөрткән.

– Миңлебай карт: «Аккилен үлмәде, ул кайтыр, учагы сүнмәсен,» – ди. Моның белән язучы нәрсә әйтергә теләгән?

**Көтелгән җавап.**

Ут, учак элек – электән кешеләрне җылыткан, ашаткан, димәк, ут, учак образлары – тормыш чыганагы, кешеләргә яшәү өчен кирәк әйберләрнең символлары. Рухи байлык та кешеләргә яшәү өчен кирәк. «Акъәбинең Туган җире, туган халкы, туган теле турындагы изге уйлары, хис-теләкләре үлмәде. Киләчәктә халыкның уллары, кызлары туган телләренә хөрмәт белән карарлар, туган халкын һәм туган җирләрен ташламаслар» дип әйтәсе килгәндер язучының. Шул рәвешле әсәрдә өлкән буын өчен әһәмиятле булган кыйммәтләр югалмас дигән фикер белдерелә.

Укытучы: чынлап та, Ә.Еники үзенең яшьләр белән әңгәмәсендә әсәрнең язылу тарихы турында сөйли һәм түбәндәге сүзләрне әйтә: «Әсәрдә кузгатылган мәсьәләләр бер башкортка гына карамый, алар бер үк дәрәҗәдә барлык халыкларга да хас нәрсәләр. Әйтик, туган җиргә мәхәббәт, туган халкыңны онытмау, олыларга хөрмәт саклау, күңел сизгерлеге һәм күңел сафлыгы – болар бит барысы да гомумкешелек сыйфатлары». Димәк, язучы бу әсәрендә милләтне саклап калу проблемасын да күтәргән. Милләтләрнең бергә кушылып, «бер урыс милләте генә калачак» дип без-

не ышандырырга теләгән авыр заманнарда Ә.Еники бу зур проблеманы күтәрергә курыкмаган.

**III. Йомгаклау.** *Дәрестә йомгаклау сүзе белән ана чыгыш ясый.*

Ул балаларны әхлаклы, шәфкатьле булып үсәргә чакыра, туган туфракның изгелегенә басым ясый, ата-аналарның кадерен белергә, аларның сүзләрен тыңларга өнди.

*Укучылар әниләргә багышлап җырлар җырлыйлар*.

Укытучы, дәресне йомгаклап, түбәндәге сүзләрне әйтә: Туган җир...Туган ана.. Туган тел... Һәр кеше өчен бу сүзләр изге. Әхлаклы, тәрбияле кеше үзенең туган җирен, ата-анасын ярата, туган телендә сөйләшә. Әхлак – туган җирне, әти-әнине ярату хисен күп еллар саклап калуда. Кешегә бик авыр булганда, ул һәрвакыт туган җиренә кайта, туган җиреннән авырлыкларны җиңәргә көч-куәт тә ала.

Мөхәммәт пәйгамбәрдән сораганнар:

Кеше иң беренче кемгә бурычлы? – дип. Ул җавап биргән:

Анага.

Икенче булып кемгә бурычлы? – дип сораганнар.

Анага, – дигән Мөхәммәт пәйгамбәр.

Өченчесе кем ? – дип сораганнар.

Анага, – дигән пәйгамберебез. Аның фикере буенча, баланың дүртенче бурычлы кешесе ата икән.

Ә инде туган телебез әти-әниләребез, әби-бабаларыбыз тарафыннан безгә бүләк ителгән зур байлык, мирас, шуңа күрә без аны саклап, үстереп киләчәк буыннарга тапшырырга тиешбез.

Өй эше: «Кадерле әнием, мин сиңа бик рәхмәтле…» дигән фикерне дәвам итәргә.

# ТЕМА: ЛЕГЕНДАГА ӘЙЛӘНГӘН ТАТАР ШАГЫЙРЕ (9 НЧЫ СЫЙНЫФ)

**М.Г. Талипов, Казан**

Рус мәктәбенең 9 нчы сыйныфында әдәбият дәресендә Самат Шакирнең «Үлемнән көчлерәк» очеркы өйрәнелә. Очеркта сүз батыр командир һәм шагыйрь Мөҗәһит Хәйретдинов (Хәйретдин Мөҗәй) турында бара. Муса Җәлилләр батырлыгыннан һич тә ким каһарманлык күрсәтмәгән бу шәхеснең исеме бераз күләгәдәрәк калып тора сыман.. Бу дәресне очеркны өйрәнүгә кадәр уздыру отышлырак булыр. Дәрестә күтәреләчәк мәсьәләләр хакында укучыларга бер-ике атна алдан хәбәр ителә, укучыларның чыгышлары билгеләнә.Дәреснең эчтәлеге буенча конкрет консультация уздырыла, материаллар тәкъдим ителә.

**Максат:** Самат Шакирнең «Үлемнән көчлерәк» очеркын кабул итү өчен мотивацион җирлек тудыру.

Дәрес геройлары үрнәгендә укучыларда ватанпәрвәрлек, халкыңның каһарман уллары белән горурлану хисләрен тәрбияләүне дәвам итү.

Мөстәкыйль эшләү күнекмәләре аша, укучыларның танып – белүгә омтылышларын арттыру.

## Дәрес барышы

Эмиль Җәләлетдинов язмасында «Унике батыр турында баллада» җыры яңгырый. Нури Арсланов сүзләре, Рөстәм Яхин музыкасы.

Бер-бер артлы җәлилчеләрнең рәсемнәре күрсәтелә.

**Укытучы:**

– Укучылар,әле генә сез тыңлаган җыр һәм экрандагы рәсемнәр турында нәрсәләр әйтә аласыз?

Җәлилчеләрнең әсирлектә фашизмга каршы көрәше турында әңгәмә уздырыла.Үлем куркынычы астында да Туган илләренә, халкына тугрылык саклап калган җәлилчеләрнең исемнәре атала.Укучылар тиңдәшсез батырлыгы өчен Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирелүен әйтәләр.Экранда указның тексты күрсәтелә. Укытучы калган каһарманнарның бары тик 1990 нчы елда, һәлак булганнарына 45 ел тулгач кына, «Бөек Ватан сугышы» ордены белән бүләкләнүләрен әйтеп дә әйтеп үтәләр.

**Укытучы** сүзе.Совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңеп чыгуына татар халкы да үзеннән ифрат зур өлеш кертте. Ул давыллы, дарылы елларда татар халкының ике йөздән артык кыз – уллары Советлар Союзы Герое дигән югары исемгә лаек булдылар. Алар орыш кырында дошман белән күзгә – күз очрашканда гына түгел,ә язмыш шуклыгы белән дошман әсирләгенә эләгеп, иң аяныч шартларда калганда да,көрәшне башка юллар белән дәвам иттеләр. Шундыйларның берсе – батыр сугышчы һәм шагыйрь – Хәйретдин Мөҗәй иде. Аны якташлары зур горурлык хисләре белән « Башкортстан Җәлиле» дип атап йөртәләр. Шул хакта сөйләү өчен **сүз Наиләгә** бирелә. (Экранда Хәйретдин Мөҗәйнең хәрби киемдәге рәсеме, 1931 нче елда полкташ дуслары белән төшкән рәсемнәре күрсәтелә. Рәсемнәр «Хәйретдин Мөҗәй. Тормыш юлы һәм иҗаты» дигән китаптан алынды.Төзүчесе Мирсәй Гариф). 1963 нче елның ноябрь санында «Совет әдәбияты» журналында «Батыр сугышчы һәм шагыйрь» дигән мәкалә дөнья күрә.Ул мәкаләдә сүз Х. Мөҗәй каһарманлыгы ту-

рында бара. Хакыбызның Күп кенә батыр уллары турында документаль очерклар,повестьлар авторы Самат Шакир бу мәкаләгә дә битараф калмый.Шагыйрьнең әсирлектәге язмышы хакында материаллар эзләү максаты белән Мәскәүгә юл тота. Ул анда тарих фәннәре кандидаты Ефим Аранович Бродскийдан Х. Мөҗәй турында бик кыйммәтле материаллар ала. Бродскийга Нюрнберг процессында катнашырга туры килгән.Шунда Чехсловакиядән килгән доктор Франц Блаха гитлерчыларның 92 югары чиндагы совет офицерлаын җәзалап үтерүләре турында сөйли.Ефим Бродский Берлин һәм Мюнхен архивларыннан шул офицерларның эшен табып ала.Ул «БСВ»ны (Боевое содружество военнопленных) фаш итү» дип атала. Мюнхендагы югары чиндагы совет әсирләре концлагеренда яшен оешма төзелә. Аның җитәкчеләре немец антифашистлары белән бәйләнешкә керәләр. Җитәкчеләрнең берсе, «Самсон» кушаматы белән йөргәне, М.Хәйретдинов була. (Аның әсирлектәге рәсеме күрсәтелә). «БСВ» үзенең эшен шактый киң җәеп җибәрә. Моның нәтиҗәләре дә күренә. Власов армиясенә көчләп язу өзелә.Күп кенә баракларда яшрен оешма членнары провакаторларны, сатлыкларны юк итәләр.Бу хәлне күргән яки ишеткән власовчылар агентлары лагерьдан хурыклы рәвештә качалар. Фашист гаскәрләренең Сталинградтагы тар – мар ителүеннән соң, Мюнхен студентлары Гитлерга каршы чыгыш ясыйлар. Студенлардан фашизмга һәм сугышка каршы язылган листовкалар табып алалар. Берлиннан империянең куркынычсызлыгын саклау баш идарәсе начальнигы Кальтенбруннер килә һәм кулга алынганнарны җәзаларга боерык бирә. Бу вакытта Мюнхенда көчле восстание кабынып китәргә тора. «БСВ» членнары, немец коммунистлары белән сөйләшеп, восстаниегә хәзерлек эшләре алып баралар.Иң элек авиация мастерскойларын, хәрби

корал складларын һәм аэродромны кулга төшерү планлаштырыла. Әмма бер сатлыкҗан оешма турында гестапога җиткерә.Оешма җитәкчеләрен кулга алулар башлана.Болар арасында полковник Тарасов, подполковник Шелест, майор Зингер,авиация майоры Карл Озолиннар белән рәттән полковник Хәйретдинов та була. 1944 нче елның 23 февралендә гестапочылар 33 совет очучысын җәзалап үтерәләр. 1944 нче елның 4 нче сентябрендә чират 92 офицер – кызыл командирга җитә. Аларны атарга кечкенә төркемнәр белән көчле конвой белән китерәләр. Күренеп тора: шушы хәлдә дә алар гитлерчылар өчен куркыныч булып калалар. Антифашист әсир Оскар Мюллернең әйтүенә, полковник Тарасов төркеме, атарга алып килгәч,фашист палачларына ташлана һәм аларны кул сугышында штыклар белән кадап һәлак итәләр. Бу геройлар арасында татар шагыйре,батыр командир Хәйретдин Мөҗәй дә була. (Экранда скульптор Д.В.Юсуповның «Утта яндырылган, ләкин буйсынмаган» бронза бюсты күрсәтелә).

**Укытучы өстәмәсе.** Х. Мөҗәйнең әдәби мирасы да шактый була. Сугышка кадәр үк аның «Мылтыклылар»,»Шлемлы кыз»,»Ил чигеннән»,»Ату маршы» »Качкын»кебек шигырь җыентыклары дөнья күргән. Сугыш барышында ул проза жанрына да мөрәҗагать итәргә була.Аның әле безнең игътибарда булачак «Сугыш язмалары» Мөҗәйнең прозаиклык таланты ачыла башлавының бер ачык мисалы.

**Диләрә чыгышы:**

Мөҗәһит Хәйретдиовның туган ягы Башкортостанның Туймазы районы Төрекмән авылы.Бу авылга Явыз Иван яуларыннан качып килгән татарлар нигез сала.1920 нче елларда бу авылда 1257 кеше яшәгән. Авылда ике мәчет эшләп килгән. Авылның үзәк урамындагы бер йортта Хәйретдин

абый белән Фәрхиҗамал апа гаилә корып яшәгәннәр. Алар бик итәгатьле һәм тәква кешеләр булганнар. Шушы гаиләдә, дүртенче бала булып,Мөҗәһит дөньяга килә.Шигырьләр язуын ул мәдрәсәдә укыган елларында ук башлый.

Тумышы белән Башкортстаннан булса да, күңеле белән Х. Мөҗәй гел Казанга, Татарстанга тартылган. Аның «Татарстанга» дигән шигырендәге: «Чакрымнар ерак...Ә йөрәгем бөтенләй үз халкым янында,–» дигән юллары шуны раслап тора. (3 укучы өлешләргә бүлеп яттан шул шигырьне сөйлиләр. Сыйныф белән бергә шигырьнең идеясе ачыклана).

**Диләрә чыгышын дәвам итә.** Х. Мөҗәйнең 1932 нче елда Казанда «Мылтыклылар» җыентыгы басылып чыга. Шул китапка кергән шигырьләр арасында «Апам хаты» дигән шигырьдә түбәндәге юллар бар:

(яттан укыла,экранда апасы Хәҗуафаның туганнан туганы Хөсникамал белән төшкән рәсеме күрсәтелә)

Их, туганым,әгәр сугыш чыкса,
Бу башыңны кемнәр өзәрләр,
Йөрәк, маңгаеңны иләк итеп
Үткен уклар тишеп үтәрләр
Челтәрләнеп,егылып калырсың,
Туплар өзәр аяк – кулларыңны
Кемнәр генә җыеп алыр соң?
Лирик геройның җавабы мондый:
Шулай, апам!
Зинһар,кыстый күрмә,
Кала алмыйм озак янында
Үз юлымда бөек эшләр өчен
Мин китәм, апам, тагын да
Йөрәгемне телеп алсалар да,
Тотып ассалар да үземне;
Соңгы сулышта да дошманнардан

Саклармын мин туган илемне!

Х. Мөҗәй бу сүзләренә соңгы сулышына кадәр тугры калды.

**Укытучы өстәмәсе.** Х. Мөҗәйнең дә, һичшиксез, әсирлектә иҗат иткән шигырьләре булган. Күрәсең, алар гитлерчылар тарафыннан юк ителгән.Аның әдәби мирасын барлау һәм табу өстендә язучы С. Шакир күп эшләде. (Рәсеме күрсәтелә). Нәтиҗәдә шагыйрьнең «Гөлнаһар» дигән поэмасы һәм «Күк куак» дигән либреттосы табылды.

Һәр ел саен 4 сентябрьдә әдипнең туган авылындагы мәктәп музеенда, Октябрьски шәһәре мәктәпләрендә патриот – шагыйрьгә багышланган хәтер көне уздрыла. (Экранда Хәтер көненнән рәсемнәр күрсәтелә)

**Иделия чыгышы.**

Бөек Ватан сугышының беренче көннәрннән үк татар язучыларының күпчелеге, кулына корал алып, фашизмга каршы көрәшкә күтәрелде.54 язучының 27 се сугышның беренче елында ук фронтка китте. Шулардан Ф. Кәрим, Г. Кутуй, Н. Баян, Р. Ильяс, М. Вәдүт, Х. Рахман, Д. Фәтхи кебек талантлы язучылар сугышта шәхси батырлык үрнәкләре күрсәтеп һәлак булалар. (Рәсемнәре күрсәтелә). М. Җәлил, А. Алиш, Р. Саттар, Х. Мөҗәй кебек язучыларның сугыш өермәләре эчендәге катлаулы язмышлары һәм дошман кулында, әсирлектә күрсәткән тиңдәшсез ныклыклары, фашистларга каршы алып барган яшерен көрәшләре, героик үлемнәре сугыштан соңгы елларда гына ачыкланды. Шушы урында тагын Х. Мөҗәйнең «Ант» шигыреннән түбәндәге шигырь юлларын искә төшереп китәсе килә.

Сөйгән анам кебек, ил өчен,
Басып йөргән изге җир өчен,
Кызганмадым кайнар канымны,
Кызганмадым йөрәк җанымны.

Дошман «җиңдем» дигән чакта да,
Мин үзем гел өскә атылдым.
Минем антым, аның һәр сүзе
Йөрәктә ут кебек тордылар.
Һәрбер эшем, һәр адымым өчен
Секундомер кебек булдылар.
Мин йөрәктә антны сакладым,
Антым белән илне якладым.
Илем өчен булган көрәштән дә
Бөегрәк нәрсә тапмадым.

Советлар Союзы Маршалы Р.Я. Малиновский (рәсеме күрсәтелә) татар сугышчылары турында болай дип әйткән: «Мин, карт солдат буларак, сугыш кырларында татар сугышчыларын һәм офицерларын күп күрдем.Һәм аларның сугышта какшамас ныклык күрсәтүләренә һәм корыч ихтыярларына һәрвакыт сокланып киләм. Советлар Союзының бәйсезлеге өчен алып барыла торган бөек көрәшебездә татар халкы үзенең сугыш эчендә чыдам һәм батыр йөрәкле солдатлары белән бөтен армиябез каршында хөрмәт казанды».

Рефлексия.

– Укучылар, без бүгенге дәрестән нәрсәләр белеп калдык?

Укучылар җавабы.

Татарлар сугышларда рус армиясенең гел алгы сызыгында булганнар. Уртак Ватанны дошманнан саклап калуда зур өлеш керткәннәр. «1912 елгы Ватан сугышы бәете»н искә төшерү дә җитә.

Алар иң кыен шартларда да дошман белән көрәшнең оптималь юлларын эзләп таба белгәннәр. Болар безгә милләтебез белән горурланырга тулы мөмкинлек бирә.

– Җиңү көнен якынайтуда татарның сәнгать әһелләре,язучылары да үзләренең өлешләрен кертәләр. Мәсәлән, бүген искә алынганнарга өстәп Харис Якупов, Сибгат Хәким, Фатих Кәрим. Габдрахман Әпсәләмов, Фәрит Яруллиннарны да атап китәргә кирәктер.

**Укытучы.** Укучылар, бүгенге дәрестә искә алынган язучыларның рәсемнәренә тагы бер кат күз төшерегез әле. Аларның исем – фамилияләре күрсәтелмәгән. Уң як баганадагы күпләгән исемнәрдән тиешлеләрен сайлап урнаштырып чыгыгыз.

**Укытучы.** Әйдәгез хәзер түбәндәге тест сорауларына да җавап биреп карыйк әле.

– Х. Мөҗәйнең 1932 нче елда басылып чыккан шигырьләр җыентыгының исеме. (Җавапны төркемдәге 1нче номерлар әзерли. Чыгыш ясаучылар бу тестларда катнашмый)

А) Калычлылар;

Ә) Мылтыклылар;

Б) Байраклылар;

В)йолдызлылар;

Түбәндә саналып киткән җыентыкларның кайсысы Х. Мөҗәйнеке түгел, кемнеке? (2 нче номерлар әзерли)

А) Ату маршы;

Ә) Ил чигеннән;

Б) Шлемлы кыз;

В) Хат ташучы.

Бу язучыларның кайсысы Мәҗәйнең әдәби мирасын өйрәнгән?(3 нче номерлар әзерли)

А) Шамил Рәкыйпов

Ә) Самат Шакир;

Б) Рафаил Мостафин;

В) Шаһинур Мостафин;

Либреттоларның кайсысы Х. Мөҗәйнеке. (4 нче номерлар әзерли)

А) Качкын;

Ә) Алтынчәч;

Б) Күк куак;

В) Илдар;

**Укытучы.** Эчтәлекле чыгышларыгыз өчен барыгызга да зур рәхмәт. Чынлап та, укучылар, сугыш барышында әсирлеккә эләгеп,бер милләт вәкилләре тарафыннан күрсәтелгән батырлык һәм ватанпәрвәрлекне сугышлар тарихы башка белми. Алар үзләре бүген әдәби әсәрләрнең геройлары булып әверелделәр. Шәйхи Маннурның «Муса» романы, Әнвәр Давыдовның «Муса абый» поэмасы, Илдар Юзеевның «Язылмаган поэмасы» әнә шундыйлардан.

**Өй эше.** «Мирас» журналының 2005-2006 нчы елгы саннарында басылган Х. Мөҗәйнең «Сугыш язмаларын» укып килергә. (Һәр укучыга 1 әр сан), эчтәлеген сөйли белергә.

## ТЕМА: «КОШЛАРЫМ, ДУСЛАРЫМ». ГАЛИ ХУҖИ «КОШЛАР КАЙТА» ШИГЫРЕ. (4 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**З. Сафина, Норлат шәһәре**

**Максат:**

1.Укучыларны безнең якларда кышлаучы һәм яз көне күчеп килүче кошлар белән таныштыру; танырга өйрәтү,аларның яшәү рәвешләре белән таныштыру.

2. Сөйләм телен үстерү.

3.Кошларның корткычларны бетерүдә әһәмиятен аңлату. Кошларны саклау, аларга ярдәм кирәклегенә төшендерү.

**Дәреснең тибы:** Катнаш дәрес.

**Җиһазлау:** Презентация, карточкалар.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше**.

**1. Дәрескә әзерлекне тикшерү.**

**2. Уңай психологик халәт тудыру.**

Хәерле көн телик таңнар саен,
Аяз күкләр телик җиребезгә.
Кояшлы көн телик һәр кешегә,
Һәм иминлек телик җиребезгә,
Хәерле көн телик барыбызга,
Хәерле көн телик үзебезгә.

– Хәерле көн укучылар.

**3. Кизү укучы белән әңгәмә.**

**4. Табигатьтәге үзгәрешләр турында сөйләшү.**

– Сез нинди ел фасылларын беләсез? Хәзер елның кайсы фасылы? Табигатьтә нинди үзгәрешләр бар?

– Әйе,укучылар,бүген кышның соңгы көне. Иртәгә беренче март. Март ае елның кайсы фасылына керә? Нинди яз айларын беләсез?

– Иртәгә безнең язның беренче көне дидек. Кышны озату бәйрәме «Май чабу» турында ниләр беләсез ?

– Ә менә татар халкының яраткан бәйрәме Нәүрүз турында ниләр беләсез?

– Әңгәмә.

– Укучылар, әйдәгез без дә бергәләшеп язны чакырыйк әле.

– Яз, яз кил инде,
Бер елмаеп көл инде,
Карлар тизрәк эресен,
Гөрләвекләр йөгерсен,
Җырчы кошлар кайтсын,
Кырда үлән калыксын,
Елга боздан арчылсын,
Зәңгәр күкләр ачылсын.
Кояш йөрсен күк тулып,
Алтын шар кебек булып
Йә инде, яз! Кил инде!

– Менә яз да килеп җитте.Тиздән җылы якка киткән кошларыбыз кайтыр. Без аларны оялар ясап каршы алырбыз. Укучылар сезгә кошлар турында шигырь өйрәнеп килергә иде.Әйдәгез матур итеп сөйләп бирегез әле.

**II. Темага кереш, ныгыту**.

**1.** Хәзер мин сезгә бер шигырь укып китәм, игътибар белән тыңлап торыгыз әле.

Урын калмады буранга,
Кар бетеп бара урамда.
Бүген мин йоклап торганда
Диңгез иде өйалды.
Сыерчыклар килгән икән,
Эшкә керешкәннәр иртән:
Чыпчыклар калдырган чүптән
Чистарталар ояны.

– Бу шигырьдә нәрсә турында әйтелә?

– Бу шигырьнең авторы безнең якташыбыз Г. Сәгыйров. (автор турында кыскача әңгәмә).

– Димәк, без сезнең белән бүген дә кошлар турында сөйләшербез.

**2. Кошлар тавышы тыңланыла.**

**3. Кошлар турында әңгәмә.**

***Укытучы сүзе:*** Кошлар җир йөзендә иң күп таралган тереклек иясе. Хәзер аларның бик күп төре бар.Татарстанда җәй көннәрендә 200дән артык,ә кышын 40 төрдән артык кош очратырга мөмкин.Кошлар очарга җайлашкан. Алар табигатькә зур файда китерәләр. Мәсәлән яз хәбәрен алып килүче кара каргалар авыл хуҗалыгы өчен зур файда китерәләр.Бер кара карга җәенә 8 меңгә якын бөҗәк ашый. Сыерчыкларны без яз җырчысы дип атыйбйз.Чөнки алар бик матур җырлыйлар.Бу кошлар бер көнгә 300-350 бөҗәк ашый. Тагын бер кош турында әйтеп китәсем килә, ул йомыркасын башка кош оясына салучы кош-күке.Аның да хезмәте бик зур. Ул агач яфракларын ашаучы йонлач кортларны ашап,урманны корудан саклый. Күке сәгатенә 100дән артык шундый корт ашый икән. Димәк, күке иң күп корт ашаучы кош. Бер пар песнәк кышына миллионлаган бөҗәкне юк итә.

**4. Кроссворд чишү.**

Ә хәзер, кошлар турында табышмакларга җаваплар табып кроссворд чишик. Дөрес итеп җавапларны таба алсак,кош исемнәре килеп чыгачак.Алар нинди кошлар булыр?

а) Чуар киемле урам малае борчак җыя,кырда куна. Ул нинди кош? (Чыпчык)

б) Гөлдер-гөлдер,гөлдер бу,кызыл тәпи кемдер бу? (Күгәрчен)

в) Кечкенә генә берәү, артында озын терәү. (Саескан)

г) Җәй шакылдый бу чүкеч,<br>Кыш шакылдый бу чүкеч,<br>Ничек чыдый бу чүкеч? (Тукран)

д) Соскы борын – бакылдык,<br>Күп сөйләшә такылдык. (Үрдәк)

е) Агач башында йорты,<br>Эчендә яши җырчы. (Сыерчык)

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | ч | ы | **п** | ч | ы | к |
| к | ү | г | ә | р | ч | **е** | н | | |
| | | | с | а | е | **с** | к | а | н |
| | т | у | к | р | а | **н** | | | |
| | | | ү | р | д | **ә** | к | | |
| с | ы | е | р | ч | ы | **к** | | | |

– Ә хәзер укучылар менә бу шигырь юлларын тыңлап китегез әле,

– Кышын бездә яшиләр,......ләр һәм чыпчыклар. Кроссвордтан шушы кош исемен таба алырсызмы икән?

**Физкультминут. «Очты, очты» уены.**

**5. Гали Хуҗиның «Кошлар кайта» шигырен уку.**

– Бүген без сезнең белән Гали Хуҗиның «Кошлар кайта» шигырен укырбыз.

– Гали Хуҗиев – татар шагыйре. Ул 1912 нче елның 17 нче октябрендә Апас районы Карамасар авылында туа. 1937-1941 нче елларда Казан дәүләт педагогика институтының кичке бүлегендә укый.Үзе теләп сугышка китә һәм фронт газетасында җаваплы сәркатип булып хезмәт итә.

Ул әдәбиятка утызынчы елларда килә. Аның «Шатлык» исемле беренче җыентыгы 1936 нчы елда басыла. Шуннан соң бик күп китаплары басыла. Шагыйрь 1966 нчы елның 13 нче октябрендә вафат була.

– Үрнәк уку (укытучының укуы).

**Сүзлек эше.**

Канәфер – сирень;

Агыйдел – река Белая.

– Укучыларның укулары (хор белән уку, чылбырлап уку, аерым-аерым уку).

– Анализ.

*Шигырьдә язның нинди билгеләре күрсәтелә? Кышын кошларга яшәү җиңелме? Аларны ачлыктан коткару өчен безгә нишләргә кирәк?

**6. Сүзләрдән җөмләләр төзү, аларны дәфтәрләргә язу.**

*сыйлыйк, көнбагыш, белән, балан, миләш, Кошларны.

*авыр,кошларга,көне,Кыш.

*Тиздән,җылы, кошлар, яктан,кайтырлар.

**7. Логик мәсьәлә.**

*Бер-бер артлы казлар оча,

Уртада атлый берсе.

Алдагысына ияреп,

Титаклыйлар дүртесе.
Соңгы казның алдыннан
Дүрт каз киләдер атлап,
Ничә каз чишмә буена
Төшеп бара хисапла.(Бишәү)
*Өч бәбкәсен ияртеп,
Суда йөзә ана каз.
Әй, каңгылдый,кагына
Канат очларын юа.
Нидер исенә төшеп,
Нәниләрен ияртеп,
Ярга чыга ана каз.
Күлдә калды ничә каз? (Берәү дә калмады).
***8. «Буталган хәрефләр» уены.***
Ырлчгака (карлыгач)
Дәркү (үрдәк)
Кчүгәрне(күгәрчен)
Аргутй (тургай)
***9. «Дөрес җавапны тап» уены.***
*Болар кышлаучы кошлар. Монда ялгыш бармы?
1.Кугәрчен. 3.Саескан.
2.Чәүкә***. 4. Сыерчык.***
*Кайсы кош тынычлык символы?
1.Карга. 3.Карлыгач.
2.Песнәк. ***4. Күгәрчен.***
*Кайсы кошны урман табибы диләр?
***1. Тукран.*** 3.Сыерчык.
2.Чәүкә. 4. Песнәк.
*Кайсы кош үзенең балаларын бер дә карамый?
1.Сыерчык. 3.Кара карга.
***2. Күке.*** 4. Песнәк.
*Кайсы кош йөзә белә?

1. Кара карга.  3. Чыпчык.
***2. Үрдәк.*** 4.Күке.

**III. Йомгаклау.**

1. Бәяләү этабы

– Балалар, без бүген нәрсә турында сөйләштек? Нәрсәләр белдек? Ниләр эшләдек? (Укучыларның җаваплары)

– Укучылар, һәр кош үзенең көченнән килгәнчә урман һәм авыл хуҗалыгы өчен бик зур файда китерә, корткычлардан,пычранудан саклый. Матур сайраулары белән күңелебезне күтәрә. Шуңа күрә без дә аларга ярдәм итик, аларны саклыйк. Чәчәкле язны яраткан кебек,канатлы дусларыбызны да яратыйк.

Кошларга таш атма,
Баласын елатма.
Таш атма кошларга, атма син.
Кошлар бит – дусларың,
Буранлы кышларда,
Ярдәм ит, аларны сакла син.!

2. Билгеләр кую. Өй эше бирү.

# III БҮЛЕК.

# РУС БАЛАЛАРЫНА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУ

# ДӘРЕС ТЕМАСЫ: «ТАБЫН ЯНЫНДА» ХИКӘЯСЕНДӘ ТӘРБИЯ ПРОБЛЕМАСЫНЫҢ КУЕЛЫШЫ (5 НЧЕ СЫЙНЫФ)

**С.Г. Юнысова, Бөгелмә**

**Максат:**

– темага караган сүзләрне актив кулланылышка кертү, укылган текстның эчтәлеген үзләштерү, эчтәлеген сөйләргә өйрәтү;

– укучыларның сорау-җавап имитацияле диалогик сөйләм, сәнгатьле уку һәм тәрҗемә, монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү;

– әдәпсезлек – начар гадәт икәнлеген төшендерү, укучыларда әдәплелек, тәрбиялелек, сабырлык, пөхтәлек, игътибарлылык кебек уңай сыйфатлар тәрбияләү.

**Класс:** 5 нче сыйныф.

**Дәрес тибы:** Йомгаклау дәресе.

**Дәрес төре:** Сөйләм күнекмәләрен үстерү дәресе.

**Белем бирү методы:** Үстерелешле укыту методы.

**Предмет эчендә бәйләнеш:** Татар теле, әдәби уку.

**Предметара бәйләнеш:** Рус теле.

**Кулланылган сингапур структуралары:** ХАЙ ФАЙВ, РЕЛЛИ РОБИН, ФИНК-РАЙТ-РАУНД-РОБИН,

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлеше.** (ХАЙ ФАЙВ – тынычлану сигналын куллану)

Укытучы.

– Исәнмесез, укучылар. Хәерле көн. Сыйныфта кем дежур? Бүген ничәнче февраль? Атнаның кайсы көне? Февральнең кышның уртасымы, әллә ахырымы? Февраль кышның ничәнче ае? Бүген көн нинди? (көтелгән җаваплар: *салкын, болытлы, карлы, буранлы, томанлы, җилле, буранлы*) Кар нинди? (*җепшек түгел, коры, ап- ак, юеш түгел*).

**II. Актуальләштерү.** Укучылар, узган дәрестә без «Табын янында» дигән хикәяне өйрәнгән идек. Сез аны өйдә укып килдегез.

ТЕКСТ. Табын янында.

Мин кичә бер гаиләгә кунакка бардым. Табын янына хуҗа малае Саша да утырды. Өстәл өстендә зур савыт белән салат тора. Саша салатны үз янына куйды һәм тиз – тиз ашый башлады. Хуҗабикә безгә аш бирде: башта миңа, аннан соң Сашага. Саша башкаларны көтмәде, ашны ашый да башлады. Ул авызын чапылдатып, сөйләшә – сөйләшә ашады. Кулы белән аштан итне алды һәм өстәлгә куйды. Десертка алма бирделәр. Хуҗа малае иң зур алманы сайлап алды да табын яныннан китте. Саша киткәннән соң, өстәл өсте бик пычрак булып калды: анда ит һәм ипи валчыклары аунап ята иде.

Әйдәгез, өй эшен тикшереп алыйк әле. Өй эше тест формасында тикшерелә.

**Тест.**

1) Мин кичә бер гаиләгә кунакка бардым.

Мин бүген бер гаиләгә кунакка барам.

2) Табын янына хуҗа малае Саша утырмады.

Табын янына хуҗа малае Саша утырды.

3) Өстәл өстендә зур савыт белән салат тора.

Өстәл өстендә зур савыт белән җиләк-җимеш тора.

4) Саша салатны ашамады.

Саша салатны тиз-тиз ашады.

5) Ул әкрен генә, ашыкмыйча ашады.

Ул авызын чапылдатып, сөйләшә-сөйләшә ашады.

6) Хуҗа малае иң зур алманы сайлап алды да табын яныннан китте.

Хуҗа малае иң зур әфлисуннны сайлап алды.

7) Саша киткәннән соң, өстәл өсте бик пычрак булып калды.

Саша өстәл өстен сөртеп китте.

Эшләрне үзара алмашып тикшерү.

Укытучы. Укучылар без бүген сезнең белән «Табын янында» хикәясендә кешеләргә хас сыйфатлар белән танышырбыз. Сашага хас сыйфатларны әйтербез, Сашага үзебезнең киңәшләрне бирербез. Табын янында үзебезне тота беләбезме? Менә шулар турында сөйләшербез.

**III. Фонетик күнегү.**

Тәртипле [тәртиплэ],

Әдәпле [әдәплэ],

Тәрбияле [тәрбийәлэ],

Сабыр [сабыр],

Пөхтә [пөхтә],

Игътибарлы [ихтибарлы].

Башта үзем укыйм, укучылар кабатлыйлар.

Бу сүзләрне хор белән/ аерым уку, рус теленә тәрҗемә итү. **(РЕЛЛИ РОБИН)**

Тәртипле – порядочный

Әдәпле – вежливый

Тәрбияле – воспитанный

Сабыр – терпеливый

Пөхтә – опрятный

Игътибарлы – внимательный

Бу сүзләр белән сүзтезмәләр/ җөмләләр төзү.

Укытучы. Укучылар, әйдәгез әле бу сүзләрнең антонимнарын әйтегез әле. Искә төшерик әле, нәрсә ул антоним? (Укучы. *капма – каршы мәгънәле сүзләр антонимнар дип атала*) (көтелгән җавап: *Тәртипсез, әдәпсез, тәрбиясез, сабырсыз, пычрак, игътибарсыз).*

**IV. Ныгыту.**

Ә хәзер, укучылар, текстны искә төшерү өчен, дәреслекләрегезнең 87 нче битен ачып, 3нче күнегүне укырбыз. (2-3 укучы чылбыр буенча укый)

Укытучы. (укучыларга сораулар бирә).

1. Хикәядә сүз кем турында бара ? (Хикәядә сүз Саша турында бара).

2) Сезгә Саша ошадымы? (Миңа Саша ошамады).

3) Ни өчен? (Чөнки ул ашаганда түгә, пычрата).

4) Без бүгенге дәрестә өйрәнгән сыйфатларның кайсылары Сашага туры килә?

(көтелгән җавап: Саша т*әртипсез, әдәпсез, тәрбиясез, сабырсыз, пычрак, игътибарсыз.).*

5) Ә сез Сашага нинди киңәшләр бирер идегез? (Укучылар сез хәзер төркемнәрдә киңәшеп эшләрсез).

1. Өлкәннәр белән бер табынга утырма.

2. Тиз – тиз ашама.

3. Ашаганда башкаларны көт.

4. Авызыңны чапылдатып ашама.

5. Сөйләшә – сөйләшә ашама.

6. Ашка кул белән тыгылма.

7. Савыттан кулың белән алма.

8. Өстәл өсте чиста булсын.

6) Сез ничек уйлыйсыз, Саша уңай герой булса, аңа нинди сыйфатлар хас булыр иде?(әдәпле, тәрбияле, сабыр, пөхтә, игътибарлы)

7) Сез ашханәдә үзегезне ничек тотасыз? Мондый хаталарны җибәрмисезме?

Укучы җавабы. **(ФИНК-РАЙТ-РАУНД-РОБИН - «Уйла - яз - төркемдә тикшер»)**

1. Өлкәннәр белән бер табынга утырмыйбыз.
*2.* Тиз – тиз ашамыйбыз / Әкрен ашыйбыз.
3. Ашаганда башкаларны көтәбез.
4. Авызны чапылдатып ашамыйбыз.
5. Сөйләшә – сөйләшә ашамыйбыз.
6. Ашка кул белән кермибез.
7. Савыттан кул белән алмыйбыз.
8. Өстәл өсте чиста була.
9. Ашар алдыннан кулларны юабыз.
10. Ашагач, рәхмәт әйтәбез.

Укытучы. Ярый, бик яхшы.

**V. Өй эше бирү.**

Укытучы.Укучылар, көндәлекләрне ачып, өй эшен язып куйыйк әле.

1 нче төркем – эчтәлек буенча диалог төзергә.

2 нче төркем – 87 нче бит, 3 нче күнегүнең эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.

3нче төркем – Сашаны уңай герой итеп күз алдына китереп, эчтәлекне үзгәртеп сөйләргә өйрәнергә.

**VI. Билге кую.** (Билгеләр аңлатып куела).

**VII. Йомгаклау.**

Укытучы. Димәк, без кешеләргә хас нинди сыйфатлар белән таныштык? Сез үзегездә нинди сыйфатларны булдырыр идегез?

Укучы. (көтелгән җавап) Без кешеләрдәге уңай һәм тискәре сыйфатлар белән таныштык. Мин үземдә уңай сыйфатларны булдырыр идем.

# ТЕМА. БУШ ВАКЫТ ҺӘМ ЯРАТКАН ШӨГЫЛЬЛӘР (ТАТАР ТЕЛЕ-ИНГЛИЗ ТЕЛЕ, ИНТЕГРАЛЬ ДӘРЕС) (6 НЧЫ СЫЙНЫФ)

**Р.Б. Камаева, Р.Р. Камаева, Яр Чаллы**

**Максат:**

– тема буенча яжа сүзләр өйрәнү, аларны сөйләмдә ныгыту

– логик фикерләү сәләтен үстерү, дөрес уку һәм язу күнекмәләрен камилләштерү, парлап эшләү күнекмәләрен үстерү

– вакытны дөрес файдаланырга, аралашу культурасына өйрәтү.

**Шәхси УУГ:** Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу; укуның кирәклеген аңлау.

**Регулятив УУГ:** Укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү; дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү; үз эшеңне бәяли белү.

**Танып-белү УУГ:** Өйрәнелгән темалар буенча кечкенә информация бирү; укытучы биргән сорауларга тулы җавап бирә белү.

**Коммуникатив УУГ:** Программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу; әңгәмәдәшең белән аралаша белү күнекмәләрен формалаштыру; үз фикереңне төгәл аңлаешлы әйтә белү.

**Җиһазлау:** Яңа лексиканы аңлату өчен рәсемнәр, биремле карточкалар,

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру**.**

– Исәнмессез, укучылар!

– Исәнмессез, укытучы апа!

– Хәлләрегез ничек?

– Яхшы!

– Утырыгыз.

– Бүген сыйныфта кем дежур?

Бүген мин дежур.Сыйныфта барысы да бар.

– Good morning, boys and girls!

– I'm glad to see you! Sit down, please.

– Who is on duty today?

– Who is absent today?

– What day of the week is it today?

– What date is it today?

– Ok. Thank you. Let's begin our lesson. We shall begin to learn the new topic "We Have a Lot In Common»

**II**. **Фонетик зарядка.**

– Listen to the sound and words and repeat it after me. Open the dictionaries. Write down, please.

It's a pity that Miss Kitty doesn't live in our city.

A black cat sat, one's the man new hat.

This is the cat

This is the rat

This is the dog

This is the frog.

**III. Тел күнегүләре.**

– Бүген атнаның нинди көне?

– Бүген атнаның сишәмбе көне.

– Бүген һава торышы нинди?

– Бүген көн аяз.Урамда җылы.

– Костя спроси у друга, пойдет ли он сегодня в библиотеку. – Син бүген китапханәгә барасыңмы?

– Даша предложи подруге сходить в музей. – Әйдә музейга барабыз.

– Саша поинтересуйся у друга нравится ли ему спорт. – Сиңа спорт ошыймы?

– I want to ask you some questions. You must be quick and attentive. *(Учитель задает вопросы учащимся в быстром темпе)*

– What is your name? *(My name is Kate)*

– How old are you? *(I am eight)*

– What is her name? *(Her name is Ann)*

– How old is she? *(She is nine)*

– Do you like to eat sweets for breakfast? *(No, I don't. I don't like to eat sweets for breakfast)*

– Will you go to the park tomorrow? *(Yes, I shall. I shall go to the park yesterday)*

– Where do you have supper? *(I have supper at home)*

**IV. «Буш вакыт һәм яраткан шөгыльләр» темасына яңа лексиканы өйрәнү.**

*Файдалы, бию, әдәби, табиб, теләк, фән, шөгыль, бурыч, алтын, вакыт* сүзләрен өйрәнү.

Файдалы.

Укытучы (рәсемгә күрсәтеп) Бал корты – файдалы бөҗәк. Русчага тәрҗемә итегез әле. Пчела – полезное насекомое. Файдалы – полезное. Файдалы сүзе белән сүзтезмәләр төзибез. (Файдалы кош, файдалы аш, файдалы үлән һ.б). Сүзтезмәләр белән җөмләләр төзибез (Тукран – файдалы кош).

Ситуатив күнегүләр эшләү.

Спроси у Маши в лесу какие полезные травы растут.

Посоветуй подруге выпить чай с полезными травами.

Убеди друга в том, что овсянка (солы боткасы) полезная каша.

(Шул тәртиптә башка сүзләрнең дә мәгънәләре аңлатыла, сөйләм ныгытыла)

Введение новой лексики по теме «Свободное время».

– I want you to open your books on the page 144, ex. 1. Look at the pictures and say what you prefer to do if you have free time. (*Учитель организует выполнение упр. 1, стр. 144 из учебника. Учитель предлагает детям ответить на вопросы по содержанию картинок*.)

– Do you like to play volleyball?

– Does your mother like to cook?

– Who likes to watch TV in your family?

– Can you swim? Do you go to the swimming pool every week?

– Do you usually go for a walk in the evening?

–Today we shall learn some new words on the topic "Free Time». Look at the blackboard, please. Can you read the words?

*(Учитель привлекает внимание учащихся к словам, заранее написанным на доске с транскрипцией. Перевод данных слов осуществляется с помощью картинок и языковой догадки. Дети читают слова самостоятельно и за учителем, а затем повторяют за диктором слова из упр. 2, с. 144 из учебника).*

*Запись на доске:*

Open air. To be fond of, club, gardening, horseracing, model, plane, travelling, collect, to go by bike, to have something in common, ship, hobby.

**V. Белемнәрне ныгыту.**

**Аудирование.**

Файдалы күнегүләр эшләү, бию белән шөгыльләнү, табиб киңәшләрен үтәү – тәнгә сәламәтлек бирә. Әдәби әсәрләр уку, төрле фәннәр белән кызыксыну – җан азыгы бирә. «Үзенең сәламәтлеген кайгырту – һәркемнең бурычы». Әнием бу кагыйдәләрне кабатларга ярата. Эшсез утырырга ярамый – алтын вакыт тиз үтә.

Текст буенча сорауларга җавап бирү.

Текстта нәрсә турына сүз бара?

Кешенең төп бурычы нәрсә?

Вакытны ничек үткәрергә кирәк?

– It is interesting to find out what your relatives like to do. Let’s read the names of different hobbies in exercise 3, page 145. You will listen to the tape and then tell us about the hobbies of your relatives. *(Учащиеся выполняют упр. 3, стр. 145 из учебника. Сначала дети читают название различных хобби, слушают образец на кассете, а затем составляют высказывания о своих членах семьи.)*

**VI. Физкультминутка.**

– Children, are you tired. Let’s have a rest and do our exercises. Stand up, please. Listen to me and repeat it after me.

Hands up! – Кулларны өскә күтәрергә!

Hands down! – Кулларны төшерергә!

Hands on hips! – Кулларны билгә куярга!

Sit down! – Утырырга!

Stand up! – Басарга!

Hands to the sides! – Кулларны як-якка!

Bend left! – Сулга борылырга!

Band right! – Уңга борылырга!

Stand still! – Төз басарга!

Sit down! – Утырырга!.

**VII. Дөрес уку күнекмәләрен камилләштерү.**

As you see our relatives have different hobbies. We shall read the text and find out what hobbies the British can have. *(Ученики читают рассказы из упр. 4 стр. 145 из учебника шепотом, а затем дают ответы на вопрос из задания перед текстом. Учитель предлагает детям прочитать рассказы вслух и сказать какие из упоминаемых в тексте хобби могут иметь люди из других стран.)*

– So we can say that people all over the world have a lot in common. We can have the same hobbies. We are fond of gardening, dancing, sport, music and so on.

**VIII. Йомгаклау. Рефлексия.**

– Now we know the names of different hobbies. Let's play the game «Snowballs». We shall use the names of different hobbies. The first pupil will think of one word, the next pupil will repeat two words and say one more. The winner is the pupil who will repeat the chain of all the words on the topic "Free time» *(Учитель организует игру «Снежный ком» с использованием слов-названий Хобби и напоминает детям правила игры)*

– Dancing,

– Dancing and gardening,

– Dancing, gardening and reading

«Мин – тәрҗемәче» уены (укучылар ике төркемгә бүленәләр, яңа өйрәнелгән сүзләрне тагын бер тапкыр хәтердә яңарталар)

*Өй эше бирү, билгеләр кую, саубуллашу.*

– That'll do for today. You were active during the lesson. The lesson is over. Goodbye!

# ТЕМА: «КОШЛАР БЕЗНЕҢ ДУСЛАРЫБЫЗ» ТЕМАСЫН НЫГЫТУ (4 НЧЕСЫЙНЫФ)

**Л.М. Сибаева, Яр Чаллы**

**Максат:**

1. Кош исемнәре лексикасын ныгыту, командада эшли белү күнекмәләрен үстерү.

2. Исемнәрдә тартым кушымчаларын дөрес куллану.

3. Бер-береңә ярдәм итү, бердәмлек,оешканлык, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар тәрбияләүне дәвам итү.

**Җиһазлау:** тартым кушымчалары язылган, «Чирик» тексты язылган слайдлар, татар халык биюләре белән диск.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру моменты.**

Дәрескә уңай психологик халәт тудыру.

– Исәнмесез,укучылар!(Исәнмесез,укытучы апа!Хәерле көн!)

– Хәлләрегез,ничек?(Бик яхшы)

– Уңышлар сезгә!(Рәхмәт)

**II. Фонетик зарядка. Аудирование.**

[къ] авазын ишетеп тану: карлыгач, тукран, күке, карга, кыр үрдәге, песнәк, аккош, кошчык ;

[гъ] авазын ишетеп тану: сандугач, песнәгем, күгәрчен, карлыгач.

**III. Белемнәрне актуальләштерү.**

1. «Тәрҗемәче» уены.

Т-Р: кошчык, минем кошчыгым, сандугач, синең сандугачың, песнәк, аның песнәге, ярма, безнең ярмабыз, эремчек, сезнең эремчегегез;

Р-Т: замёрз, вдруг, подумал, просо, птичка, клюв птички, крыло, её крыло;

2.»Артык сүзне тап» уены.

– эремчек, ярма,тары, икмәгебез, каймак;

– карга, сандугач, песнәк, күгәрченең,аккош.

(Икмәгебез, күгәрченең – с окончанием пренадлежности)

– Яхшы,укучылар! Сегодня на уроке мы с вами продолжим работу с окончаниями пренадлежности.

**IV. Белемнәрне гомумиләштерү, системалаштыру.**

1) Структура «СИНГЛ РАУНД РОБИН»

– А сейчас работаем в группе.... номерлы укучы берет листок со стола и сгибает пополам. Потом по линии сгиба отрываем и отдаем партнеру по плечу. Партнеры по плечу оба опять сгибают листок пополам и отрывают. Полученные маленькие листочки отдаем партнерам по лицу. Партнеры по лицу благодарят.

Задание. Каждому ученику я сейчас раздам карточки со словами. Вы должны будете написать в своих листочках эти слова с окончаниями прЬнадлежностей.

1 команда – минем- сандугач, карга, торна, аккош

2 команда – синең- песнәк, үрдәк, каз, карабүрек

3 команда– аның- поши, куян, тиен, керпе

4 команда – тукран, чыпчык, карлыгач, күгәрчен (30 сек.)

– А сейчас прочитаете их партнеру по плечу (15 сек.). Начинает тот, у кого волосы длиннее.Стоп! (15сек., начинает второй партнер)

– Давайте сейчас послушаем вместе.... номерлы укучы җавап бирә.

(һәр командадан бер укучы җавап бирә)

– А теперь каждая команда подумает ответ на вопрос «Почему у вас такие окончания в словах?» Вспоминаем правила. Подумаем (10 сек.)

– Расскажите партнеру по лицу (15сек.-первый) Начинает тот, у кого светлее глаза. Стоп! 15сек. – расскажет второй.

– А сейчас с каждой команды... номерлы укучы җавап бирә.

– Вы согласны? Если да, то показываете большим пальцем вверх, если нет – то вниз.

Нәтиҗә: Молодцы,ребята! Что мы с вами повторяли? (Окончания принадлежности). (Слайдта кушымчаларны чыгару: Минем–М,-ЫМ,-ЕМ; Синең–Ң,-ЫҢ,-ЕҢ; Аның–Ы,-Е,-СЫ,-СЕ; Безнең-ЫБЫЗ,-ЕБЕЗ,-БЫЗ,-БЕЗ; Сезнең-ЫГЫЗ,-ЕГЕЗ,-ГЫЗ,-ГЕЗ; Аларның-ЛАРЫ,-ЛӘРЕ,-НАРЫ,-НӘРЕ).

Үзбәя: А сейчас оцените свое знание по окончаниям принадлежности. Поставьте себе оценку,

Китапларны ачабыз, 2нче күнегүне карыйбыз. Сүзтезмәләр белән җөмләләр төзеп укыйбыз.

Стуктура «МИКС ПЭА ШЭА»

– А сейчас выходим сюда. Танцуем под музыку. Когда музыка прекращается, коснемся этой парты и находим пару. Как находите пару вместе поднимаете руки,

чтобы узнать кто остался без пары. Кто без пары со мной будет работать. В паузах – выполняем задания.

– Итак, танцуем (музыка играет). Стоп!

Задание 1.

– Нинди кошлар җылы якка китәләр? (10сек.). Работаем в паре, сначала первый ученик говорит (15сек.), потом – второй (15 сек.). Начинает тот, кто выше ростом.

– Ә хәзер Рената җавап бирә (берничә укучыдан сорала).

Задание 2. Кайсы кошлар безнең якларда калалар? (Шул тәртиптә эшләнелә).

Үзбәя.

Структура «РЕЛЛИ РОБИН».

– Вспомним текст, который мы с вами прошли.

Я раздаю вам предложения из текста. А вы в команде собираете текст.

– Сейчас по кругу читаем мне по1 предложению.... номерлы укучы башлый.

– Ребята, вы согласны ответом первой команды? Если согласны, показываете (баш бармакларын өскә каратып күрсәтәләр,дөрес булмаса, баш бармак аска карый).

– Кош нигә оча алмый?

– Аның кайсы җире авырта?

Ситуатив күнегү.

а) Как скажешь о том, что зимой птицам очень трудно.

б) Спроси у друга, сделал ли он кормушку.

в) Спроси у друга, кормит ли он птиц

**IV. Рефлексия. Бәяләү. Өй эше бирү.**

– Ребята, домашнее задание на выбор:

1. Дәреслектә: 71 бит. 2нче күнегү (5 җөмлә төзеп язарга).

2. Дәреслектә: 64 бит. 5нче күнегү (Чирик турында сөйләргә).

– Бүген дәрестә без нәрсәләр турында сөйләштек? (кошлар турында).

– Күгәрченем, күгәрченебез, күгәрченең сүзләре нәрсә белән аерыла? (с аффиксами принадлежности).

– А сейчас каждый ученик оценивает себя, берёт карточку со своим именем и прикрепляет под соответсвующей оценкой.

– Җавапларыгыз өчен рәхмәт! Дәрес тәмам. Сау булыгыз!

## ТЕМА: «БАЗАРДА» ТЕКСТЫН УКУ (2НЧЕ СЫЙНЫФ)

**Р.Ә. Юнысова, Яр Чаллы**

**Дәрес тибы:** Яңа белем бирү.

**Сыйныф:** 2 нче сыйныф рус төркеме.

**Максат:**

1. Өйрәнелгән лексик материалны системага салып гомумиләштерү.

2. Укучыларның сәнгатьле уку күнекмәсен камилләштерү, бәйләнешле сөйләм телен, грамоталы язу күнекмәсен, төркемнәрдә бер-берсе белән киңәшләшеп эшләү, нәтиҗә ясау, бәяли белү күнекмәләрен камилләштерү; фикерләү сәләтен үстерү юнәлешендәге эшне дәвам итү.

3. Үзара дустанә мөнәсәбәт, мөстәкыйльлек, игътибарлылык тәрбияләү.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше.** (Кереш). Балаларны сәламләү. Кәефләре белән кызыксыну. Хәерле көн теләү.

Укытучы: Исәнмесез! Хәерле көн! Хәлләрегез ничек?

**II. Төп өлеш.**

Белемнәрне актуальләштерү. Яңа белем үзләштерү өчен кирәк булган, үткән материалны кабатлау, һәр укучының индивидуаль эшчәнлегендәге авырлыкларын ачыклау. Конверттагы яшелчәләрне һәм җиләк җимешләрне алып,

арларның исемен атыйлар. Бу нәрсә: яшелчәме, җимешме икәнен әйтәләр.

Парларда эш. Син нәрсә яратасың? Ни өчен? Укучылар бер-берсеннән сорыйлар. Укытучы берничә парны тыңлый.

Төркемнәрдә эш. Карточкаларда яшелчә һәм җимешләр исеме язылган, ләкин кайбер хәрефләр төшеп калдырылган. Укучылар төшеп калган хәрефләрне куеп язалар. Эталон буенча тикшерәләр, хаталарны төзәтәләр.

**III. Яңа темага кереш**. Проблеманы куеп, яңа белемгә чыгу, теманы аңлату. Дәреснең темасын һәм максатын ачыклау. Алган белемнәргә таянып, текстны аңлап уку.

1.Укытучы: рәсемгә карагыз. Сез яшелчә-җимешләрне кайдан сатып аласыз? Базардан, кибеттән,...

Бу кыз кем белән? Аларга нәрсә кирәк. Монда нәрсәләр саталар?

2. Рәсемгә таянып укучылар таблицага тамгалар куялар. Мин уйлыйм: Көз көне базар бай – «+» тамгасын куя.

| Мин уйлыйм | | Текстта бар |
|---|---|---|
| | Көз көне базар бай. | |
| | Света әнисе белән базарга бара. | |
| | Әни кавын сатып ала (покупает). | |
| | Апа кызыл помидор сата (продает). | |
| | Бабай Светага алма бирә. | |

Партадашы белән фикер алышалар. Җавапларны чагыштыралар.

Текстны уку.

Текстка таянып укучылар таблицага тамгалар куялар. Тамгаларны чагыштырып, текстны ничек аңлауларын беләбез.

**IV. Ял минуты.** Әби борщ пешерә. Әни җиләк-җимеш салаты ясый. Укучылар кирәкле яшелчәләрне алып әби янына, кирәкле җимешләрне алып әни янына җыелалар.

**V. Теманы ныгыту.** Теманы үзләштерүне аңлау, үз эшчәнлегеңә үзбәя һәм сыйныф эшчәнлегенә бәя бирү.

Парларда эш. Текст буенча бер-берсенә сораулар бирәләр.

Ситуатив биремнәр. Укытучы биремне русча әйтә. Балалар парларда сөйләшәләр. Әңгәмәдәшенә рәхмәт әйтеп саубуллашалар.

Дәреслектәге диалогны уку. 51 нче бит 5 нче күнегү. Диалогтагы геройларның исемнәрен үз исемнәренә алыштыралар. Әни урынына башка кешене атап укырга да була.

– Света, син кая барасың?
– Мин базарга барам.
– Базарга кем белән барасың?
– Базарга әни (әти, әби, бабай, апа, абый) белән барам.

Тест биремнәрен үтәү. Дөрес җавапны билгеләргә.

Төркемдә эш.

1) Света әнисе белән базарга бара.
Света әтисе белән базарга бара.
2) Әнисе карбыз ала.
Әнисе кавын ала.
3) Бабай Светага алма бирә.
Бабай Светага чөгендер бирә.

**VI. Дәресне йомгаклау.** Теманы үзләштерүеңне аңлау, үз эшчәнлегеңә үзбәя һәм сыйныф эшчәнлегенә бәя бирү.

*Бәяләү. Өй эше бирү.* Иң яхшы сөйләүче конкурсына әзерләнергә. «Базарда» текстын сөйләргә әзерләнергә.

# ТЕМА: «ЯЗ КИЛӘ» ТЕМАСЫ БУЕНЧА СҮЗЛЕК ДИКТАНТЫ. ПАРЛЫ СҮЗЛӘР, КУШМА СҮЗЛӘР (4 СЫЙНЫФ)

**Л.Х. Канашова, Яр Чаллы**

**Максат:** Кушма сүзләр, парлы сүзләр турында төшенчә бирү һәм шул сүзләрне куллана белү; «Яз килә» темасында актив үзләштерелгән лексик берәмлекләрне дөрес язу күнекмәләрен ныгыту; укучыларны үзара берләштерергә тырышу (партадаш партнер белән берлектә эш); белем дәрәҗәсен арттыру өстендә эш.

**Җиһазлау:** Карточкалар, дәреслек, интерактив такта, рәсемнәр.

## Дәрес барышы

**1. Оештыру этабы**. Укучылар белән исәнләшү, дежур укучы белән әңгәмә.

**2. Дәреснең максатын билгеләү.**

Укытучы: Укучылар, без бүген сезнең белән «Яз килә» темасын тәмамларбыз. Бу тема буенча үзләштерелгән белемнәрегезне сүзлек диктанты аша тикшерербез. Сүзлек диктантын мин тараткан карточкаларда башкарасыз.

**3. Белемнәрне актуальләштерү.**

1) Сүзлек диктанты.

а) Күп нокталар урынына тиешле хәреф куеп язарга:

Оз...н, җ...лы як , кы...ка, сы...рчык, кош ...ясы, я...рак, орл...к, таби...ат...,

ка...ен я...рагы, й...клый, кар ...ри, тамчы т...ма.

б) Бирелгән сүзтезмә белән җөмлә төзергә.

Тамчы тама

Сүзлек эше.

Игътибар белән тактага карыйбыз.

Ташбака – черепаха

Көньяк – юг

Төньяк – север

**4. Яңа тема өстендә эш.**

1. Тактада түбәндәге сүзләр белән табличкалар эленгән:

Хатын-кыз, аккош, савыт-саба, ашханә, кош-корт, кулъяулык, ир-ат, көньяк.

Укытучы: Укучылар, әйтегез әле, бу сүзләр бер берсенә охшаганнармы, әллә юкмы? Сездә нинди фикерләр бар?

Укучы: Язылулары буенча алар төрле; кайберләре сызык аша язылган, ә кайберләре кушылып язылган.

Укытучы: Кайсылары охшаган? Әйдәгез охшаган сүзләрне икенче баганага язып куябыз.

– Шулай итеп, сүзләр ике төркемгә бүленделәр.

1 нче төркем

Хатын-кыз

савыт-саба

кош-корт Парлы сүзләр

ир-ат

2 нче төркем

аккош

ашханә Кушма сүзләр

кулъяулык

көньяк

Укытучы:Ә хәзер шушы төркемнәргә исемнәр биреп карыйк, ничек уйлыйсыз кайсылары «Кушма сүзләр», ә кайсылары «Парлы сүзләр». Исем кушар өчен тәрҗемә итеп карыйк әле, кушма сүзләр нинди ?

Укучы: Кушылып языла сүзеннән ясалган.

Укытучы: Ә парлы сүзләр нинди?

Укучы: Парлы, икәү дигәнне аңлата.

Искәрмә: Рус төркеме булу сәбәпле биремнәрне укучыларга русчага тәрҗемә итү сорала.

(Такта янына бер бала чыгып магнит белән беркетелгән «Кушма сүзләр», «Парлы сүзләр» табличкаларны төркемнәрнең өстенә беркетеп куя).

2. Интерактив тактада сүзләр, шул сүзләрне 1 вариант астында утыручылар кушма сүзләрне генә күчереп язып ала, ә 2 вариант астында утыручылар парлы сүзләрне күчереп язып ала.

Җиләк-җимеш, унбер, бала-чага, ташбака, табак-савыт, аш-су, алма, өчпочмак.

Язып бетерү белән бер-берсенең эшләрен тикшерәләр. Шул вакытта интерактив тактада «ачкыч» бирелә.

| | | |
|---|---|---|
| Җиләк-җимеш | өчпочмак | алма |
| бала-чага | унбер | (бу сүз гади сүз) |
| табак-савыт | ташбака | |
| аш-су | | |

Интерактив тактада сүзләрне аңлатучы рәсемнәр карала. М-н:

Ташбака – черепаха (рәсем)

Савыт-саба – посуда (рәсем) һ.б.

Укытучы: Укучылар, сез бүген дәрестә парлы һәм кушма сүзләр белән танышырсыз. Әйдәгез әле үзегез, күзәтүләрегез ярдәмендә «парлы» һәм «кушма» сүзләр турында кагыйдә төзеп карагыз.

Укучылар үзләре кагыйдә төзиләр:

Укучы: Кушма сүзләр – ул ике тамыр, яисә исем кушылып бергә язылганда. Шулай ук бу сүзләр» ь» һәм «ъ» ярдәмендә дә ясалалар.

Парлы сүзләр – ул ике тамыр, яисә исем сызык аша языла.

Укытучы: Ә хәзер кагыйдәне схема ярдәмендә күрсәтәбез.

Кушма сүзләр = исем( яисә тамыр) + исем

Мәсәлән: өчпочмак

Кушма сүзләр = исем + ь + исем

Мәсәлән: көньяк

Кушма сүзләр = исем + ъ + исем

Мәсәлән: кулъяулык

Парлы сүзләр = исем + « –» + исем

Мәсәлән: бала-чага.

**5. Сәламәтлек мизгеле.**

Җил исә, исә, исә

Яфракларны селкетә

Җил тына, тына,тына

Яфраклар җиркә төшә (укучылар хәрәкәтләр белән күрсәтәләр***).***

**6. Ныгыту.**

Укытучы: Укучылар, алган белемнәрегезне ныгыту өчен күнегүләр башкарабыз.

Бирем: тексттан кушма һәм парлы сузләрне табу (текст тактада, яисә интерактив тактада языла).

Ашханәдә.

Ашханәдә бала-чага бик күп. Бүген пешекче апалар безгә тәмле өчпочмаклар пешергәннәр. Аш-су остасы Резидә апа безне гел тәмле ризыклар белән шатландырып тора. Ашханәдә савыт-саба тавышы тынмый. Җиләк-

җимешләр белән чәй эчүләре дә ничек рәхәт! Күңелле һәм иркен безнең ашханә.

2) Бирем: өстәлләрдәге карточкаларда сүзләр төзергә һәм берсен сайлап алып җөмлә төзергә .

Кул кош

Ак ханә

Аш яулык

таш аяк

тимер бака

бала ат

ир чага

савыт кыз

хатын саба

**7. Йомгаклау.**

Укытучы: Укучылар, дәресебез ахырына якынлашты. Сез бүген дәрестә нинди яңалыклар алдыгыз? Нәрсәләргә өйрәндегез? Нинди нәтиҗәләргә ирештегез?

Укучылар үз теләкләре белән җавап бирәләр.

Укытучы: Әйдәгез, укучылар, хәзер үзебезнең эшчәнлекләребезгә билге куябыз (актив булганнарны билгеләү).

## ТЕМА: ХИКӘЯ ФИГЫЛЬНЕ КАБАТЛАУ (6 НЧЫ СЫЙНЫФ)

**Э.Д. Сафиуллина, Апас районы**

**Максат:** Укучыларның «Хикәя фигыль» темасы буенча алдагы дәресләрдә өйрәнгән белемнәрен: хикәя фигыльнең мәгънәсен, сорауларын, кушымчаларын, заманнарын искә төшерү, башка сүз төркемнәреннән аеру, сөйләмдә дөрес куллана белү күнекмәләре булдыру; укучыларның логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын һәм танып-белүләрен үстерүгә ярдәм итү;аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү, төркемнәрдә һәм парларда эшли белү күнекмәләрен формалаштыру, укучыларда әниләргә карата мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек, игътибарлы мөнәсәбәт кебек асыл сыйфатларны тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Компьютер, проектор, экран, презентация, интерактив такта, карточкалар, татар теле дәреслеге.

**Дәрес тибы:** Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру, ягъни кабатлау-йомгаклау дәресе.

### Дәрес барышы

**1. Оештыру-мотивлаштыру этабы.**

Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.

Укытучы: Хәерле көн, балалар, бер-берегезгә уңышлар телик.

Менә тагын бер яңа көн туды. Бүгенге көн барыбызга да исәнлек-саулык, сөенеч-шатлыклар, ак бәхетләр алып килсен дигән изге теләк-омтылышлар, куанычлар белән дәресебезне башлап җибәрик әле.

**2. Өй эшен тикшерү.**

Укытучы: Әйдәгез, укучылар, өй эшен тикшереп үтик. Әйтегез әле, өй эшенә нәрсә бирелгән иде? (Үтелгән материалны кабатларга.)

**3. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.**

Укытучы: Укучылар, мин сезгә билгеләмәләр әйтәм, алар дөрес булса, сез басасыз, дөрес булмаса, утырасыз.

Хикәя фигыльнең билгеләмәсе (дөрес булса басалар, дөрес булмаса утыралар):

1. Хикәя фигыль эш яки хәлнең сөйләм вакытында, сөйләм вакытына хәтле һәм сөйләм вакытыннан соң үтәлү-үтәлмәвен белдерә.
2. Хикәя фигыль предметны белдерә.

Заман формаларын кабатлау :

1. Хикәя фигыльнең 3 заманы бар.
2. Хикәя фигыльнең 4 заманы бар.

Хикәя фигыльнең барлык-юклык төрен кабатлау. Укучылар барлык төренә туры килгән мисалларны ишеткәч басалар, юклык төрен ишеткәч утыралар: язабыз, укымадың, сөйлиләр, ашамадыгыз, киләләр, бастык, ишетмәгән, кайтмас, барачак, шатлана.

Киләчәк заман хикәя фигыльнең сорауларын кабатлау.

Киләчәк заман хикәя фигыль нишләр? нишләде? нишләячәк? нишли? сорауларына җавап бирә.

Укучылар, молодцы! Өй эшен кабатлап килгәнсез. Ә хәзер эшләгән эшебезгә нәтиҗә ясыйк.

**4. Белемнәрне актуальләштерү.**

Укытучы: Бүгенге дәреснең темасы нинди булыр икән? Алдыбызга нинди максат куярбыз? Бу максатка ирешү өчен дәрестә ничек эшләрбез?

Укытучы: Укучылар, сезнең алда альбом битләре ята, башта аны икегә, аннан тагын икегә бүләбез. Шул бүленгән кисәкнең урта почмагын әз генә бөклибез һәм альбом битен вертикаль рәвештә ачып, каршыбызга куябыз. Әлеге биттәге бөкләнгән урыннарны карандашлар белән кабатлап чыгабыз һәм уртага хикәя фигыль дип язабыз. Беренче баганага хикәя фигыльнең билгеләмәсен, икенче баганага характеристика, өченче баганага мисаллар, дүртенче баганага капма-каршы мисалларны язабыз. Һәр кәгазь битен мөстәкыйль рәвештә тутырабыз. Сезгә барлыгы дүрт минут вакыт бирелә.

| Билгеләмә | Характеристика | Мисаллар | Капма-каршы мисаллар |
|---|---|---|---|

Укытучы: Балалар, әйдәгез, бирелгән төшенчәгә карата сыйныфыбыз моделен төзик. Мин тактага яза барам.

– Беренче өстәлдән 1нче укучы, билгеләмәне укып китегез әле. Рәхмәт.

– Икенче өстәлдән 1нче укучы, сезнең билгеләмәгез нинди? Рәхмәт, калганнар бу билгеләмә белән килешәләрме?

– Өченче өстәл 2нче укучы, хикәя фигыльнең характеристикаларын укып чыгыгыз. Дүртенче өстәлдән 2нче укучы, сезнең характеристикаларны тыңлап карыйк. Кемнәрдә өстәлмәләр бар?

– Бишенче өстәл 3нче укучы, хикәя фигыльгә мисалларны укып китегез әле. Рәхмәт. Кемнәрдә өстәлмәләр бар?

– Беренче өстәлдән 4нче укучы, хикәя фигыльгә капма-каршы мисалларны укыгыз. Рәхмәт. Өстәлмәләр бармы?

– Яхшы, укучылар, сез хикәя фигыльнең үзенчәлекләрен исегездә калдыргансыз.

Ял минуты:

Укытучы: Укучылар, без хәзер барыбыз да басабыз. Музыка яңгырый, сез шул музыкага бии-бии хәрәкәтләнәсез. Музыка туктагач, бер урында катып каласыз. Шуннан соң мин сезгә сорау бирәм, сез, шул сорауның җавабына туры килгән санга карап, берләшеп басарга тиеш. Ләкин бер кеше дә төгәл җавапны кычкырып әйтергә тиеш түгел, үйлыйбыз гына. Башлыйбыз.

1. Татар телендә ничә килеш бар? (6)

2. Мәктәп сүзендә ничә тартык аваз бар? (4)

3. Китап сүзендә ничә сузык аваз бар? (2)

4. Үткән заман хикәя фигыльнең ничә төре бар? (2)

5. Хикәя фигыльнең ничә заманы бар? (3)

6. Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең ничә кушымчасы бар? (4)

7. Фигыльләрнең ничә юнәлеше бар? (5)

– Рәхмәт, укучылар, хәзер барыбыз да урыннарга утырабыз.

**5. Белем һәм осталыкларны яңа ситуациядә куллану.**

Укытучы: Хәзерге заман хикәя фигыльләрне искә төшерәбез.

1. Хәзерге заман хикәя фигыль нәрсәне белдерә? (Сөйләм вакытында үтәлгән яки үтәлмәгән эш-хәлне белдерә).

2. Нинди сорауга җавап бирә (нишли? соравына җавап бирә).

3. Нәрсә белән төрләнә? (зат-сан белән).

4. Барлык һәм юклык төренең кушымчалары нинди?(-а/-ә, -ый/-и; -мый/-ми).

**6. Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру.**

Укытучы: Ә хәзер, укучылар, өстәлдәге кәгазь битләренә без сезнең белән сайланма диктант язарбыз.

Бирем. Хәзерге заман хикәя фигыльләрне генә язарга.

Ана – ул дөньяда иң бөек кеше. Бик күп күренекле шәхесләрне, галимнәрне, укытучыларны ана тудырган. Ана баласын күкрәк сөтен имезеп, төн йокыларын калдырып үстерә. Кичләрен баласына бишек җырлары җырлый, әкиятләр сөйли.

Бала үсә, мәктәпкә йөри башлый. Ана аңа дәресләрен әзерләргә булыша, үз-үзен тотарга, кешеләр белән матур, ягымлы итеп сөйләшергә өйрәтә. Бала үсеп кеше була һәм үз баласын шулай ук тәрбияли, бар көчен баласын үстерүгә бирә. Бер көнне карый, аның әнисе дә баласы кебек үк тәрбиягә мохтаҗ икән бит.

(Үстерә, жырлый, сөйли, үсә, йөри башлый, булыша, өйрәтә, була, тәрбияли, бирә, карый.)

Исем-фамилияләрегезне язып, билге куяр өчен, кәгазь битләрен җыеп алабыз.

**Төркемнәрдә эшләү.**

**Укытучы:** Мин сезгә, укучылар, бер риваять укыйм.

*Әнисе үзенең улы начарлык эшләгән саен, рәшәткәгә бер кадак кага бара. Еллар уза, бала үсеп буйга җитә, армиягә барып кайта. Беркөнне егет кадакларга игътибар итә һәм әнисе янына килә. «Әни, нигә син шулкадәр күп кадак кактың?» – дип сорый.*

*Әнисе: Улым, менә син бер начарлык эшләгән саен, мин бер кадак кага бардым. Күрәсеңме, ничаклы алар?- ди. Улы*

*уйга кала һәм гел яхшылыклар гына эшләргә сүз бирә. Шулай эшли дә. Менә ананың улы да олыгая, әнисе исә картая. Улы әнисе янына беркөнне килә дә: «Әни , кара әле, рәшәткәдә бер кадак та калмады. Мин, яхшылык эшләгән саен берсен ала бардым. Начарлыгыма каршы яхшылык эшләдем»- ди. Ә әнисе болай ди: «Әйе, улым, син күп яхшылыклар эшләдең һәм, шулай итеп, начарлыкларыңны бетердең дә кебек, тик әнә, кара әле рәшәткәләргә, никадәр кадак эзе. Аларның эзе калган бит»,- ди.*

**Төркемнәргә бирем.**

Укытучы: Ни өчен әнисе улына шулай ди? Ул нәрсә әйтергә тели? (Җаваплар тыңлана)

**7. Үзләштерү дәрәҗәсен ачыклау.** Җибәрелгән хаталар буенча фикер алышу һәм төзәтмәләр кертү.

Һәр төркемнән бер укучы астына сызылган фигыльгә, интерактив такта янына чыгып, морфологик анализ ясый.

**8. Өй эше.**

Укытучы: Сезгә 3 вариантта өй эше тәкъдим итәм. Берсен сайлап эшләгез.

1. 77нче биттәге 140нчы күнегү. Күчереп язарга, билгеле һәм билгесез киләчәк заман хикәя фигыльләрнең астына сызарга.
2. Хәзерге заман хикәя фигыльләр кергән 4 җөмлә язарга.
3. «Хикәя фигыльләр» темасына газета ясап килергә.

**9. Рефлексия (дәрескә йомгак ясау).**

Укытучы: Дәресебез ахырына якынлаша. Сезнең өчен дәрестә иң кызыклысы нәрсә булды? Нинди яңалыклар белдегез?

Һәр төркемнән 1-2 укучы бүгенге дәрестә үзенә нинди яңалык ачканын сөйли, нәтиҗә ясый, теләкләрен җиткерә.

Укытучы: Укучылар, һәрвакыт изгелекләр генә эшләргә тырышыгыз. Дусларыгызның шатлык – борчуларын урта-клашып, киң күңелле, игътибарлы, ярдәмчел, кыскасы, чын кеше булып үсегез. Әти-әниләрегез дә сезнең белән горурланыр, сез аларны бәхетле итәрсез. Сезне һәрвакыт яхшы итеп телгә алырлар, башкаларга үрнәк итеп куярлар. Сау булыгыз!

# IV БҮЛЕК.

# ФДББС ТАЛӘПЛӘРЕ НИГЕЗЕНДӘ ЗАМАНЧА ДӘРЕС

## ФДББС БУЕНЧА ЯКЫНЧА ДӘРЕС СТРУКТУРАЛАРЫ

**Яңа тема өйрәтү дәресенең якынча структурасы**

1) Тема, максат, бурычлар билгеләү. Ике тема бирү үзен аклаячак: теоретик материал өйрәнү буенча һәм тәрбияви, үстерүче максатлардан чыгып лексик тема алына. Мәсәлән, сыйфат дәрәҗәләре. Кешедә барысы да матур булырга тиеш.

2) Оештыру моменты (эшчәнлеккә әзерлек).

Максаты: укучыларны төп эшчәнлеккә җәлеп итү. Сыйныфта уңай эмоциональ атмосфера булдыру.

Эш алымнары: укытучының изге теләкләре, бүгенге эш өчен кирәкле сыйфатларны билгеләү, девиз, эпиграф белән таныштыру, үрнәк буенча өй эшен мөстәкыйль тикшерү һ.б. (1, 2 минут).

3) Белемне актуальләштерү.

Максат: бүгенге темага нигез булырлык итеп, үтелгәнне кабатлау, уку чыларга авыр тоелган урыннарны ачыклау (4, 5 минут).

4) Проблемалы ситуация булдыру.

Уку мәсьәләсен кую.

Максат: авырлыкларны ачыклау (Ни өчен шундый сорау килеп туды? Без әле нәрсәне белмибез?), дәрес максатын я теманы төп сорау кебек итеп билгеләү (4, 5 минут).

Уку мәсьәләсен кую буенча проблеманы ачыклауга юнәлтелгән, темага алып килгән әңгәмә үткәрү..

5) Яңа тема өйрәнү.

Максат: мәсьәләне телдән чишү юлларын бергәләп эзләү, анализлау (7, 8 минут).

Эш төрләре: төрле фикерләр тудырган, проблеманы хәл итүгә юнәлтелгән әңгәмә, төркемләп, парлап эшләү.

6) Ныгыту.

Максат: бергәләп, чиратлап яңа белемне кабатлау, терәк сигнал формасында теркәү (4, 5 минут).

Эш төрләре: фронталь эш, парлы эш, продуктив күнегүләр башкару.

7) Үзаллы эш.

Максат: һәр укучыны теманы аңлавына, күнегүләр башкара алуына ышандыру (4, 5 минут).

Эш төрләре: 2, 3 зур булмаган язма эш башкару, укучыларның өлге буенча үзләрен тикшереп барлавы.

Яңы теманы кабатлау, ныгыту.

Укучыларга яңа тема буенча эш тәкъдим ителә (1 күнегү), алга таба шушы ук күнегү алдан үтелгән темалар белән бәйләп ныгытыла (7, 8 минут).

8) Рефлексия (дәрес нәтиҗәсе).

Максат: укучыларның үз уку эшчәнлеген, сәләтләрен дөрес бәяләү, башкаларның эшчәнлеген күрә һәм дөрес анализлый белүе (2, 3 минут).

Сораулар: Нинди максатлар куйган идек? Максатларга ирештекме? Ничек? Нәтиҗәләр нинди? Тагы да нәрсәләр эшләргә тиешсез? Бүгенге белемне тормышта кайда һәм ничек кулланырга мөмкин? Синең бигрәк тә кайсы эшең уңышлы килеп чыкты? Алга таба нәрсә өстендә эшләргә кирәк?

**Белем һәм күнекмәләрне комплекслы куллану дәресенең якынча структурасы (ныгыту дәресе)**

1) Оештыру этабы.

2) Өй эше тикшерү. Укучыларның терәк белемнәрен яңадан барлау һәм төзәтмәләр кертү. Белемнәрне актуальләштерү.

3) Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

4) Беренчел ныгыту:

– таныш ситуациядә (типлаштырылган)

– үзгәртелгән ситуациядә (конструктив)

5) Белемнәрне яңа ситуациядә иҗади куллану һәм эзләп табу (проблемалы биремнәр).

6) Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү.

7) Рефлексия (дәрескә йомгак ясау).

**Белем һәм күнекмәләрне актуальләштерү дәресенең якынча структурасы (кабатлау дәресе)**

1) Оештыру этабы.

2) Өй эше тикшерү. Куелган бурычларны иҗади чишү өчен кирәкле белем һәм күнекмәләрне яңадан барлау һәм төзәтмәләр кертү.

3) Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

4) Белемнәрне актуальләштерү: – контроль дәрескә әзерлек максатыннан; – яңа теманы өйрәнүгә әзерлек максатыннан.

5) Белем һәм осталыкларны яңа ситуациядә куллану.

6) Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру. Үзләштерү дәрәҗәсен ачыклау. Җибәрелгән хаталар буенча фикер алышу һәм төзәтмәләр кертү.

8) Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү.

9) Рефлексия (дәрескә йомгак ясау).

**Белем һәм осталыкларны системалаштыру дәресенең якынча структурасы**

1. Оештыру этабы.

2. Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

3. Белемнәрне актуальләштерү.

4. Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру. Укучыларны гомумиләштерелгән эшчәнлеккә әзерләү. Тиешле дәрәҗәдә яңадан үзләштерү (үзгәртелгән сораулар белән).

5. Белем һәм осталыкларны яңа ситуациядә куллану.

6. Үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, җибәрелгән хаталар буенча фикерләшү һәм аларны төзәтү.

7. Рефлексия (дәрескә нәтиҗә ясау).

Эшчәнлеккә нәтиҗә ясау, өйрәнелгән материалны анализлау.

**Белем һәм осталыкларны тикшерү дәресенең якынча структурасы**

1) Оештыру этабы.

2) Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

3) Белем, осталык һәм күнекмәләрне тикшерү ( биремнәр күләме һәм авырлык дәрәҗәсе буенча программага һәм һәр укучының белем дәрәҗәсенә туры килергә тиеш).

Контроль дәресләрнең формалары:

– язма контроль;
– телдән һәм язма контроль аралаштырып бирелгән булырга мөмкин.

4) Рефлексия (дәрескә нәтиҗә ясау).

**Белем, осталык һәм күнекмәләргә төзәтмәләр кертү дәресенең якынча структурасы**

1) Оештыру этабы.

2) Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

3) Белем, осталык һәм күнекмәләрне диагностикалауның нәтиҗәләре. Укучыларның белем һәм күнекмәләрендәге хаталарны ачыклау, аларны төзәтү юлларын, белем һәм осталыкларын камилләштерү.

Диагностика нәтиҗәләре буенча укытучы коллектив, төркемнәрдә һәм индивидуаль эшләү алымнарын планлаштыра.

4) Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү.

5) Рефлексия (дәрескә йомгак ясау).

**Катнаш дәреснең якынча структурасы**

1) Оештыру этабы.

2) Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

3) Белемнәрне актуальләштерү.

4) Яңа белемнәрне беренчел үзләштерү.

5) Яңа белемнәрне үзләштерүне беренчел тикшерү.

6) Беренчел ныгыту.

7) Үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, җибәрелгән хаталар буенча фикер алышу һәм төзәтүләр кертү.

8) Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча аңлатма бирү.

9) Рефлексия (дәрескә йомгак ясау).

**Заманча дәресне проектлаштыру**

Хәзерге заман таләпләргә җавап бирә торган дәрес нинди булырга тиеш? Аны проектлаштырганда укытучыга нәрсәләргә игътибар итү сорала? Бу бүлектә без шушы сорауларга җаваплар табарга тырышырбыз.

Иң беренче чиратта педагогка шуны истә тоту мөһим – дәрестә башкарылган һәр эшчәнлек максатчан һәм нәтиҗәле

булырга тиеш. Моны аңлап кабул итү өчен безгә көндәлек тормышыбызга игътибар итү сорала. Мисал өчен, нинди генә чараны гына алмыйк, сайламыйк (спектакль яисә концерт карау, тәмле ризыклар белән туклану, китап сатып алу һ.б.) без аның алдан ук нәтиҗәле, көтелгән һәм күңелле булачагына өмет итәбез. Һәрбер чарада ике як урын ала: җырчы – тыңлаучы, артист – тамашачы, пешекче –- тукланучы, укытучы – укучы. Әгәр безгә тамаша яисә чара ошаса, без аннан рухи азык алабыз һәм тагын бу чарага килү теләге белән кайтып китәбез, иптәшләребезгә дә бу тамашаны карарга киңәш итәбез, ә инде тискәре тәэсир калдырса, вакытыбызны заяга уздырдык дигән фикердә калабыз. ФДББС (ФГОС) нәкъ менә укучының белем алу процессында теләктәш катнашучысы булуына басым ясый. Белем алу ул – бурыч түгел, ә куанычлы, күңелле бер чара булырга тиешлеген искәртә.

Педагогка ФДББСка җавап бирә торган дәресне хәзерләгәндә иң беренчел чиратта нәрсәләргә игътибар итү сорала:

• төп максат – укучының шәхси үсешен тәэмин итү;

• укучыларда УУГ формалаштыру;

• укучыларның эзләнү эшчәнлеген дөрес итеп оештыру һәм танып-белү эшчәнлеген үстерү (укучыларның белемнәре мөстәкыйль эзләнү эшчәнлегенең нәтиҗәсе булсын өчен).

Заманча дәресне проектлаштыруның төп принциплары:

1. Белем үзләштерү парадигмасының эчтәлеге үзгәрү (белем үзләштерүдән – эшчәнлеккә).

2. Белем үзләштерүнең эчтәлегеге, формасы, алымнары, методлары һәм технологияләре үзгәрү.

3. Педагогик позицияләрнең урыны үзгәрү (укытучы-укучы иде, хәзер укучы-укытучы).

4. Укучы эшчәнлегендә эчке мотивлар формалашу.

5. Шәхси максатны билгеләү һәм материалның эчтәлегенә шәхси якын килү;

6. Белем алу эшчәнлегенең рефлексив нәтиҗәләре булу.

Шулай итеп, заманча дәреснең әһәмиятле аспектлары:

• дәреснең максатчан һәм мотивлашкан булуы;

• дәреснең максаты төгәл һәм конкрет булуы, куелган максатка көтелгән нәтиҗәләрнең җавап бирүе, ягъни тәнгәл килүе зарури;

• дәреснең нәтиҗәлелеге укучыларның билгеләреннән, материалны үзләштерү дәрәҗәсеннән чыгып түгел, ә укучыларның эшчәнлегеннән чыгып бәяләнергә тиеш. Шул ук вакытта дәрестә «белем» алуның әһәмияте кимеми, киресенчә, булган белемнәрне гамәлдә куллана белүгә игътибар гына арта;

• дәреснең яңа белем бирү максаты – укучыларның үзләре алдына мөстәкыйль максат куюлары һәм аңа бару бурычларын билгеләп эшчәнлек оештырулары;

• заманча дәреснең эшчәнлеккә корылган булуы;

• яңача корылган дәреснең мәгънәсе – ул белем алу процессы вакытында куелган проблеманының укучылар тарафыннан таныпбелү эшчәнлеге аша чишелүе;

• дәрестә никадәр дәрәҗәдә мөстәкыйль эшчәнлеккә күбрәк урын бирелсә, шул кадәр яхшырак (бу очракта укучылар текст өстендә эшләп проблеманы чишәргә өйрәнәләр һәм мәгълүмати компетенцияләргә ия булалар);

• заманча дәрес белем бирү процессында дискуссия, видеотәнкыйть, эшлекле һәм рольле уеннар, ачык сораулар кебек эшлекле методлар һәм алымнарның актив кулланылуның белән аерылып тора.

Укытучы тарафыннан дәресне нәтиҗәле итеп оештыру өчен нәрсәләргә игътибар итү сорала:

– аеруча уңышлы дип табылган дифференцияләшкән һәм шәхси укытуга юнәлдерелгән, кызыксынуны арттыра торган һәм иҗади активлыкны үстерә торган укыту методларын, эффектлы алымнарны сайлау, уйлап табу;

– үзконтрольлекне оештырып эшчәнлекне башкару (дәреснең планын педагогик принциплардан – эзлеклелек, оптимальлек, кешелеклелек, гуманитарлылыктан чыгып коррекцияләү);

– булачак дәреснең план-сценариясен (технологик картасын) төзү.

Дәреснең нәтиҗәле булуының алшартлары:

– кысыксындыру, мобилизацияләү;

– дәреснең беренче минутыннан ук укучыларны актив эшчәнлеккә алып керү;

– дәрес планында каралган гамәлләрне үзчиратында башкару;

– дәрестә эшлекле генә түгел, иҗади, хисэмоцияләргә бай булган, уңай теләктәшлеккә корылган атмосфераны булдыру;

– укучыларның игътибарына бирелгән информациянең никадәр дөрес кабул итүлүен, үзләштерелүен белү өчен этапларда каралган барлык чараларны куллану;

– уку-укыту алымнарының арсеналын төрләндерү;

– дәресне тәмамлаганда өй эшен төгәл формалаштырып бирү һәм киләсе дәрескә «күпер» салу (киләсе дәрестә нинди теманы үтәчәкләрен һәм ул материалның әһәмиятен ачыклап бирү).

Дәрестә укучының игътибарын даими җәлеп итеп тору алымнары:

– проблемалы ситуацияләр булдыру;

– укучыларның белем үзләштерү темпларын үзгәртеп тору (тизләтү яисә әкренәйтү);

– укучыларга көтелмәгән, кызыклы сораулар хәзерләү;

– белем бирү процессында аудио-, видео техник чараларны, күрсәтмәлелекне куллану;

– фронталь, төркем белән эшләү төрләрен актив чиратлаштырып тору;

– дәрестә төрле кызыклы ситуацияләрне мисал итеп китерү;

– уңышлылык халәтен тудыру;

– дәрес эчтәлегенә төрле уеннарны кертеп җибәрү;

– көч сынашу-узышуга корылган биремнәрне бирү;

– укучылар белән ышанычлы әңгәмә-диалог кору.

Алда искәртеп кителгәнчә, белем бирү процессында укучыларның танып белү эшчәнлеген оештыруның алшарты – кысыксындыру, мобилизацияләү һәм балаларны дәреснең беренче минутыннан ук актив эшчәнлеккә алып керү. Заман таләпләре шартларында оештырылган укытуның төп үзенчәлеге дә шунда: ки, укытучы белемнәрне әзер хәлендә бирми, укучылар алдына бурыч куя, аны кызыксындыра, хәл итү өчен аерым чаралар табу теләге уята. Бу бурычны хәл итү юлларын эзләү барышында ул үзендә яңа белемнәр булдыра. Традицион укыту төрендә укытучы турыдан-туры кызыксындыру чараларына басым ясый (укытучы кызык итеп сөйли, күрсәтмә әсбаплар белән кызыксындыра – укучыга кызык, бирелеп тыңлый), яки бу материалның киләчәктә тормышта кирәк булганлыгына аерым басым ясый (дәрес бик кызык түгел, иллюстратив материаллар юк, ләкин бу фән яки аның бер бүлеге югары уку йортына керү имтиханнарына хәзерлектә бик әһәмиятле, шуңа күрә укытучыны тыңларга һәм материалны аңлап калырга кирәк).

Проблемалы укытуның төп төшенчәсе – проблемалы ситуация. Проблемалы ситуация кешегә нәрсә дә булса уйлау яисә нинди дә булса эш башкару өчен белемнәр, анык эш ысуллары җитешмәгәндә, белем һәм җитешмәгән күнекмәләр арасында каршылыклар туганда барлыкка килә. Проблемалы ситуация укучыда барлыкка килгән каршылыклардан, кыен ситуацияләрдән чыгу теләге барлыкка килгәндә генә өйрәтү үзлегенә ия. Проблемалы ситуация тудыруның беренчел бурычы – ул интеллектуаль кызыксындыру. Проблемалы ситуация барлыкка килгән вакытта укучы үзе кызыксынып, кирәкле белем алу юлларын эзли, мөстәкыйль рәвештә тапкан уңыш аңарда канәгатьләнү хисе тудыра.

Әлбәттә, бу хис һәр төрле проблемалы ситуациядә барлыкка килмәскә мөмкин. Бу хәләт барлыкка килсен өчен ике төрле шартны сакларга кирәк. Ситуацияне чишү эшчәнлеге укучыга азмы-күпме кызыклы, көченнән килерлек булырга, ул аны эшли алуын сизәргә, үзендә аны җиңеп чыгарлык белем булуын күз алдына китерерлек булырга тиеш.

Проблемалы ситуацияләр тудыру алымнары:

1. Каршылык тудыручы сораулар бирү (каршылыклы фикер тудыручы факторны булдыру): нинди кызыклы фактлар белән очраштыгыз? Сездә берәр төрле сорау барлыкка килдеме? һ.б.

2. Эшчәнлек вакытында укучылар арасында төрле фикерләр тудыра торган сораулар яисә биремнәр бирү.

3. Укучыларның күзаллауларына тәңгәл килеп бетмәгән практик биремнәрне башкарырга бирү. Сез ничек төшенгән идегез? Нәрсә килеп чыкты? Проблеманы аңлатыгыз.

4. Укучылар башкарып чыга алмый торган практик бирем бирү. Сез бу эшне башкарып чыга аласызмы? Сәбәпләре нәрсәдә? Сезгә нәрсә билгеле түгел?

5. Алдагыларына охшаш булмаган биремнәр бирү: сез бу биремне башкара алдыгызмы? Алдагы биремнән нәрсәсе белән аерылып тора? Нәрсә билгеле түгел? Дәреснең максатын билгеләгез.

6. Алдагы белемнәрнең җитмәүчәнлеген күрсәтә торган биремнәр бирү.

Бу биремне ничек башкарырга җыенасыз? Эшне башкара алдыгызмы? Бу эшне башкару өчен нинди белем-күнекмәләрегезне кулланачаксыз?

Проблемалы ситуацияләрне тудыру өчен киңәшләр:

1) Уку-укыту проблемасы укучыларны үзенең эмоциональлеге, кызыклы булуы, гадәти түгеллеге белән аерылып торырга тиеш.

2) Укытучы укучыларның эмоциональ халәтенә игътибарлы булырга тиеш.

3) Дидактик принциплар саклана (фәннилек, аңлаешлылык, системалылык, укытучының активлыгы).

Проблемалы ситуацияләрнең чишү формалары:

– дискуссия;
– фәнни бәхәс;
– проблемалы лекция;
– проблемалы биремнәр;
– эзләнү-тикшеренү характерындагы биремнәр;
– проблематик текстлар һ.б.

Бу төр эшчәнлекләрне оештырып башкарылган дәресләрдә алынган белемнәр укучының хәтерендә генә бер мәгълүмат буларак кына түгел, ә тормыш итү өчен әһәмиятле булган алшартлар буларак формалашырлар.

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕН МОДЕЛЬЛӘШТЕРҮДӘ ЗАМАНЧА ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР (ЭШ ТӘҖРИБӘСЕННӘН)

Форм.бум. 60х84 $^{1}/_{16}$. Гарнитура Times New Roman.
Усл.печ.л. 13,5

Оригинал-макет подготовлен в редакционно-издательском отделе
Института развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
E-mail: irort2011@gmail.com